PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2020 НОЯБРЬ № 11

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ХЫЯНӘТМЕ, *флиртмы*
ир-атларга ни җитми

ТАПКАН АНАМЫ, *бакканмы*
әни ничәү була

Кукмара сые
БОРАЙ БӘЛЕШЕ

Гөлнара
МӨХӘММӘТХАНОВА:

«Без утырткан урманнарга оныкларыбыз сөенәчәк».

Хәтер – мәңгелек...

Хәтер – мәңгелек...

Бөек Җиңүгә миллионлаган гап-гади кешеләрнең каһарманлыгы бәрабәренә ирешә алдык. Алар арасында безнең татар егетләре, татар кызлары да байтак. Минем бабам, синеке, аныкы... Сугыш афәте кагылмаган, сугыш ишек шакымаган капка, гаилә калды микән? Җиңү таңы безгә шуңа да кадерле... Инде бу хакта бүгенге яшьләребезгә дә аңлатасы, төшендерәсе, күңелләрендә горурлык хисләре уятасы килә. Бу проект – шул хакта. Мондый ядкарьләр, бәлки, сезнең гаиләләрдә дә сакланадыр. Юк икән, аларны шушы сайттан табып алырга мөмкин: https://pamyat-naroda.ru. Бабаларыгызга орден-медальләр ни өчен бирелде икән? Балалар, оныклар белән бергә утырып эзләп карагыз әле. Әлеге тарихи документларны үз күзләре белән күргәч, Җиңү сүзенә алар инде берничек тә битараф калалмас...

Табышларыгызны безнең белән дә уртаклашыгыз. Хатларыгызны көтәбез.



Бабам Салаватов Миңнебай Арыслангали улы Кызыл Армия сафларына 1936 елны Башкортстанның Авыргазы районы военкоматыннан алына. Туган ягына кайтып килергә насыйп булмый аңа, Бөек Ватан сугышы башлана. Бабам Миңнебай Көнбатыш фронтта хезмәт итә, 18 нче запас укчы дивизиясенең башта – взвод, аннары рота командиры була. Роталары белән немецлар чолганышында калалар. 300 кешелек төркем исән-имин бу тозактан котылып, 298 нче укчы полкына кушыла. Бабам бик күп тапкырлар яралана. Аның күпсанлы яралары хакында Бүләкләү битендә дә телгә алына. Безнең өчен кадерле бу ядкарь «Память народа» сайтына да куелган.

Бер һөҗүм вакытында бабамның башына мина кыйпылчыгы килеп эләгә. Җансыз гәүдәсен мәетләр белән бергә вагонга төяргә җыенганда, «Бу бит Миңнебай!» – дип, бер якташы танып ала. Аңсыз булса да, исән булып чыга бабай. Шулай тартып алалар яшь командирны үлем элмәгеннән. Баш миенә аз гына барып җитмәгән ярчык тәнендә гомерлек «сувенир» булып кала. Госпитальдән терелеп чыккач, бабай батальон белән җитәкчелек итеп, Калинин фронтындагы сугышларда катнаша. Шунда күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены һәм башка орден-медальләр белән бүләкләнә.

1946 елны туган авылы Балыклыкүлгә әйләнеп кайта. Колхозда счетовод булып эшли. Әбием белән үрнәк булырлык гаилә коралар, сигез бала үстерәләр. Бабам озак еллар колхоз председателе вазыйфасын да башкара.

Сугыш турында сөйләргә кушсалар: «И балалар, сезгә күрергә язмасын инде сугышның нәрсә икәнен!» – дип әйтә торган була ул. Кешеләрнең тәнендә генә түгел, җанында да тирән яралар калдырган шул сугыш.

Альбина ӘГЪЛӘМОВА

Все графы заполнять полностью

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество САЛАВАТОВ [illegible]
2. Звание Капитан 3. Должность, часть Командир батальона 36 запасного стрелкового полка 18 запасной стрелковой дивизии
Представляется к Правительственной награде медали "ЗА БОЕВЫЕ ЗАСЛУГИ"
4. Год рождения 1915 5. Национальность Татарин 6. Партийность [illegible]
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и отечественной войне (где, когда) Отечественная война Зап. фронте 22.6.41 по [illegible] [illegible] фронт с 5.[illegible].41–8.1.42 и с 10.6–20.10.42г.
8. Имеет ли ранения и контузии в отечественной войне Ранен 3 раза: [illegible]
9. С какого времени в Красной Армии [illegible]
10. Каким РВК призван Аургазинским РВК Баш. АССР
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) Наград не имеет
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи.

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

[illegible]

Командир (начальник) Подполковник (звание) /КОРОЛЕВ/

29 июня 194[illegible] г.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Гөлнара Мөхәммәтханова
Фото: Анна Арахамия

Верстка:
Резеда Галиуллина
Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәр:
Олег Сердюк

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды:
29.10.2020 ел.
Чыгу көне:
5.11.2020 ел.
Заказ А-2868
Тираж 7342

Учредитель:
Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



Мәдияр Хаҗиев эше

Баш мөхәррир сүзе



Кадерле укучыларыбыз!

Журналыбызның ноябрь санын гадәттә әниләргә багышларга тырышабыз. Әниләр бәйрәме... Әни, әнием, әнкәй... Бу көнне дөньядагы иң якын, иң кадерле кешебез янына ашыгабыз, тагын бер кат аңа күңел түрендәге сүзләрне әйтеп калырга тырышабыз... Кемдер иң кадерле кешесе белән инде уйда гына сөйләшә ала... Ничек булса да, Әниләр көне барыбыз өчен дә кадерле бер көн ул.

Белмим, Кәрим Караның бу санда дөнья күрәчәк хикәясе сәбәпчеме, әллә Гөлнур Сафиуллинаның «Минем кебек сине беркем яратмас...» язмасы герое Алсуның кичерешләре микән – уйларым һаман әллә кая алып китә... 90 нчы еллар башы... Без, КДУның ВМК факультеты студентлары, Яшел Үзәндә урнашкан Балалар интернатына барып йөрибез... Ул балалар килүебезне өзелеп көтеп тора, кайчак безгә әни дип тә эндәшеп куялар иде. Текәлеп карап торулары әле дә күз алдымда... Хәзер, еллар узгач, аңлыйм: алар һәр кешегә «әни» дип эндәшергә әзер иде... Һәм... Көннәрдән бер көнне Аны – бу дөньяга китергән кешесен көтеп алып, кочагына ташланырга, хыянәтен гафу итәргә дә әзер булганнардыр...

Күңелемдә менә кайчаннан бирле бер уй, ә бәлки, бер теләк яши: язмыш хатын-кызга әни булу бәхетен бүләк иткән икән, бу бүләкнең кадерен белсәкче...

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА

Безнең тышлыкта

«Агачлар барыбер күзгә күренеп үсә: быел яныннан узып китәсең – әле үлән арасында була, киләсе елга инде үләннән баш калкыта...»



10 Урман ул – тормыш!
Гөлнур Сафиуллина

Заман һәм без




6 «Әйдә, тиз, соңга калабыз!»
Руфия Рәхмәтуллина



20 Кычкыра – димәк, ышана?
Раилә Хәялиева



16 Нәсел тоткасы
Гөлнур Хәсәншина




24 Әлфия Самат бит ул!
Эльмира Закирова

Татар дөньясы



Балтач бакырчылары
Лилия Гәрәева
28

Мәдәни тормыш



34
Үткәннәргә кайту юк
Кәрим Кара



37
Әниләрнең бөеклеген яши-яши аңлыйбыз
Суфия Бәдретдинова

Яшәеш



40
Сара ханым
Роза Мулланурова

«Син бәхеткә лаек!»
Эльмира Шәрифуллина
44



50
«Минем кебек сине беркем яратмас...»
Гөлнур Сафиуллина

Хуҗабикә



60
Борай бәлеше

PRESSA

АКТУАЛЬ ТЕМА

Фото: Анна Арахамия

«ӘЙДӘ, ТИЗ, СОҢГА КАЛАБЫЗ!»



Руфия РӘХМӘТУЛЛИНА

Дүшәмбе – музыка мәктәбе, сишәмбе – бию түгәрәге, чәршәмбе – сәнгать мәктәбе, пәнҗешәмбе – музыка мәктәбе, җомга – сәнгать мәктәбе, якшәмбе – бию. Бу безнең узган елгы расписание. Ни өчен безнең дим, игезәк кызларым белән мин дә «укырга» йөрдем. (Аларны бит алып барырга, көтеп торырга, алып кайтырга кирәк.) Аннан төнге унбергә кадәр, ә кайчакта унике дә тулып киткәнче, өй эшләрен эшлибез. Нәтиҗәдә, балаларның өлгерешләре начарланды. Ял күрмәгәнгә, үземнең дә башым авырта, әйләнә башлады. Хәтта неврологка барып, уколлар алырга туры килде…

Әйе, яңа заманда яңа буын яңача яши. Бала культы турында күптән сөйлиләр. Хәзер менә яңа төшенчә – «интенсив ана булу» («интенсивное материнство») дигәне барлыкка килде. Дөрес, ул турыда 90 нчы елларда ук Америка социологы Шэрон Хейс үзенең хезмәтләрендә язган. Ә бездә исә ачыктан-ачык бу турыда биш-ун ел элек кенә сөйли башладылар. Иң кызыгы, ә бәлки, кызганычы – әлеге күренеш үскәннән-үсә бара. «Интенсив ана булу» терминын Шэрон Хейс болай аңлаткан: «Бала – бәһасез. Аңа бөтен булган вакытыңны, энергияңне бирергә кирәк. Ә безгә кадәр булган буын балаларга тулысынча игътибар бирмәгән...»

...4 яшьлек кызларыбызны логика түгәрәгенә йөртә башлаганда мин бу «ачышны» белми идем, әлбәттә. Ә ни өчен түгәрәк кирәк булдымы? Зуррак балалары булган аналар белән сөйләшкәндә барысы да куркытты:

– Һай, хәзер мәктәп программасы бик катлаулы. Укырга кергәнче бала укый-яза, саный белмәсә, бик авыр булачак...

Шуңа күрә дә алдан хәстәрен күрергә булдым. Җитмәсә, логика түгәрәге яшәгән йортыбыздан ерак түгел иде. Балалар үзләре дә бик теләп йөрде. Бакчадан кайтып, атнасына ике тапкыр түгәрәккә йөрү безнең гадәткә керде. Киләсе елга эш тагын да тыгызланды – логикага бию түгәрәге дә өстәлде. Һәм шуны әйтим – бу фәкать кызларның теләге иде. Шәрык биюенә гашыйк иде алар. Шулай итеп атнаның дүрт киче «тулды». Ә киләсе елда инде логика белән биюгә, гимназиядәге әзерлек курслары да кушылды. Ләкин алар әллә ни кыенлык тудырмады кебек. Ни өчен дигәндә, өйгә кичке җидедән соң кайтылса да, дәрес әзерлисе юк. Бакчага да иртәнге сигезгә түгел, тугызга гына барырга ярый, ягъни балаларның йокылары туя.

Беренче сыйныфка киткәч, режим тагын да тыгызланды: кызлар музыка мәктәбенә керде. Аның өстенә курай түгәрәгенә язылдылар. (Гимназиядә генә булгач, үзләре теләп барды). Өйгә, иң иртә дигәндә, җидедә кайтыла башлады. Ә биюгә барган



«Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү үзәге психологы Гөлфия СӘЛАХЕТДИНОВА: *«Интенсив ана булу» терминын хәзерге заман чире диярга буладыр».*

көнне кичке тугызсыз да өйдә булмыйбыз. Тик ни хикмәт, балалар зарланмады. Кечкенәдән түгәрәккә йөргәч, кызлар бу режимны шулай булырга тиеш кебек кабул итте, ахры. Мин исә аларны кызганам: ярты сәгать вакытлары да калмый. Өйгә кайткач, берсе – фортепиано, икенчесе скрипкада уйный. Аннан курай хоры башлана...

Ә менә икенче сыйныфка күчкәч хәлләр мөшкелләнде. Мәктәпкә әзерлекле булып баргач (укый, яза, куша, ала беләләр иде), беренчедә өй эшләре белән озак утырмадык. Икенче сыйныфта көн саен диярлек мөстәкыйль эшләр башланды. Ә кызларыбызның әзерләнергә вакыты калмый. Иш янына куш дигәндәй, Рәзиләбезнең бик тә иҗат мәктәбенә йөрисе килде, рәсем түгәрәгенә дә язылып кайткан идек. Шуның өстенә әле гимназиядәге түгәрәкләр... Кыскасы, бер буш көн дә калмады, әле якшәмбегә дә җитте. Сентябрь аенда сер бирмәскә тырышсалар да, октябрьдә күренде – кызлар моның кадәр йөкне күтәрә алмый. Мөстәкыйль эш, контроль эшләрдән «өчле»ләр ияреп кайта башлады. Әле «икеле» дә булды. Бигрәк тә математика авыр бирелде. (4 яшеннән логикага йөргән балалар бит!) Өйдә тавыш, елаш... Әтисе аңлата, мин кушылам. Максат «биш»легә укыту түгел, «өчле»сез уку. Барыбыз бергә тырыша торгач, уку программасы җайланды кебек. Аның каравы, мин үзгәрдем – элеккеге кебек тәмле ризыклар әзерләү бетте. Бер пешергән ашны өч көн дә ашыйбыз. Өй җыештыру кебек көндәлек мәшәкатьләр дә икенче планга күчте. Матурлык корбаннар сораган кебек, уку, өстәмә шөгыльләнүләр дә кыйммәткә төште. Көне буе эштә, аннан балалар белән. Нәтиҗәдә, бик еш башым авырта башлады.

Озын сүзнең кыскасы, кызлар быел иҗат мәктәбен ташлады. Мәктәптәге түгәрәкләргә дә йөрмиләр, өлгерә алмыйлар чөнки. Музыка мәктәбе белән бию генә калды. Быел атнага ике көннәре буш, дәресләр беткәч, үзләре генә өйгә кайтып дәрес әзерлиләр, ял итәләр. Алланың рәхмәте, өченче сыйныфта уку җиңелрәк бирелә, «өчле»ләр дә онытылды. Ә иң мөһиме – дәресне тулысынча үзләре әзерли. Хәтта кайбер көнне өй эшләре турында сорап та тормыйм. Аннан бигрәк, үзем тынычландым. Түгәрәккә бармаган көнне тәмле ризыклар пешерергә вакыт кала. Хәзер үзем өчен нәтиҗә ясадым – чамасын белү кирәк!

«Көчләп тагылган образ»

Әнием, утыз елга якын мәктәптә рус теле һәм әдәбияты укыткан мөгаллимә, безнең бүгенге режимны бөтенләй кабул итми. «Абыең да, син дә бер түгәрәккә дә йөрмәдегез, кеше булдыгыз бит әле», – ди. Мин исә килешеп бетмим, кечкенә чагында үзебезне төрле юнәлештә сынап карасак, күбрәк ачылган булыр идек кебек. Мондый очракта әнинең яраткан сүзе: «Ана сөте белән кермәсә, тана сөте белән юк инде...»

Гомумән, өлкән буын кешеләрендә бала тәрбияләүгә мөнәсәбәт бүтәнчә. Алар балаларны яшәү мәгънәсе итеп кабул итмәгән. Күптән түгел Татарстанның атказанган табибәсе, («Сөембикә» журналының күптәнге авторы) Руфинә Фәттахова янында булган идем. Бала тәрбияләү турын-

да сүз чыккач, ул: «Безнең балалар мөстәкыйль булды. Ул чорда хәзерге кебек бала культы юк та иде», – диде. Руфинә ханымның кайнанасы – язучы Нурихан Фәттахның әнисе аңа еш кына бер сүзне әйткән: «Үз ризыгыңны балаңа бирмә, игелексез булыр». Бүген исә аналар балалары өчен ризыгын гына түгел, бар булган вакытын, соңгы көчен сарыф итә. Моның нәтиҗәсе нинди булыр, вакыт күрсәтер...

«Интенсив ана булу» әйбәтме, начармы? Шул хакта «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү үзәге психологы Гөлфия Сәлахетдинова белән сөйләштем.

– Без әлеге яшәү режимына шактый еллар килдек, – диде Гөлфия ханым. – Һәм менә бүген аның чәчәк аткан чоры. Җәмгыять бүген хатын-кызга карата бик таләпчән – ул карьера ясарга, үзен карап йөрергә һәм ул-кызын тәрбияләргә дә тиеш. Тәрбия дигәндә, тәртип ягы гына түгел, малай-кызларның әллә ничә түгәрәккә йөрүе, яхшы укуы да күздә тотыла. Шуның өстенә әле баланың өс-башы да матур, пөхтә булсын. Әлбәттә, бу хатын-кызга эмоциональ һәм физик яктан җиңел бирелми.

«Интенсив ана булу» терминын хәзерге заман чире дияргә буладыр. Журналлар, инстаграм битләрендә без күпчелек очракта уңган, уңышлы яшәү рәвеше алып барган әниләрне күрәбез. Алар моңа ничек, нәрсә бәрабәренә ирешә, анысын белмибез. Шуңа күрә мин аны көчләп тагылган образ дияр идем. Без менә шул затлы, матур картинадагы анага карап, үзебезне чагыштыра башлыйбыз. «Ни өчен мин алай булдыра алмыйм?» – дип тә әйтергә мөмкинбез. Һәм, үзебез дә сизмәстән, картинадагы анага охшарга тырышабыз. Социаль челтәрләрдә күбрәк «яшәгән» саен, әлеге күренеш көчәячәк кенә.

– Ул көчәймәсен өчен нишләргә кирәк?

– Алтын урталык булырга тиеш. Үсеш этабында балага куелган йөкләнешнең чамасын белергә кирәк. Шулай ук баланың мөмкинлекләренә дә карарга кирәк: күпме тарта ала? Барлык балалар да бертөрле булмый бит. Хатын-кыз бөтен гаиләне тартучы, шуның өчен үзен корбан итүче, якыннарын опекада тотучы булырга тиеш түгел. Һәрхәлдә, бу сәламәт мөнәсәбәтләр дип аталмый. Аннан, балага ирек кирәк. Анасы теләгән барлык түгәрәкләр, юнәлешләр дә аның өчен кызыкмы? Күп очракта ата-ана үзе булдыра алмаган, күңелендә калганны баласында күрергә тели. Ә балага бу кирәкме соң? Үз фикере булмыйча, гомер буе ата-анасы кушканча гына яшәгән бала тормышта үз юлын табармы? Ата-ана менә шулар хакында уйланырга тиеш.

Алтын урталыкны табу өчен, иң беренче чиратта, хөрмәт кирәк – балага карата да, анага карата да. Әгәр хатын-кыз социаль челтәрләрдә уңышларын күрсәткән аналар кебек яши алмый икән, борчылмасын. Тормышта бит бүтән кыйммәтләр дә бар: түгәрәккә йөрү яисә матур кием белән генә идеаль әни булып булмый. Бәхет формуласы һәркемнеке төрле. «Бәхетле ата-ана – бәхетле бала» дигән сүзне ишеткәнебез бар бит, бу нәкъ шул очрак.

«Иртәрәк башлаган саен, яхшырак»

Тагын шунысын ассызыклап үтәргә кирәк – авыл җирендә хәзер дә балалар элеккечә түгәрәкләрсез генә үсә. Укырга кергәнче фәлән сүз укысын, куша, ала белсен дигән максат та юк. Аның каравы, мөстәкыйль, үткен, эш сөючәнлекләре белән алдыралар.

Район үзәкләре исә шәһәрләшә бара. Һәр районда бассейннар, боз сарайлары бар. Иҗат үзәкләре дә актив эшли. Тик шулай да район җирендәге аналар үзләрен тынычрак тота кебек. Көн саен баласы белән анда-монда йөгерми.

Кайбыч район үзәгендә яшәүче өч бала анасы Алинә Мотыйгуллина моны менә ничек аңлатты:

– Бездә балаларны бөтен түгәрәкләргә дә йөртү дигән максат юк. Олы улыбыз Искәндәрне бала-



Гөлназ САФИНА, Американың Нью-Джерси штатында яшәүче өч бала анасы.

Россиядә соңгы елларда аналар идеаль булырга тырыша. Балаларга суларга да вакыт калдырмыйлар кебек. Кешедән калышмыйк дип, соңгы акчаларын түләп булса да өстәмә түгәрәкләргә йөртәләр.

Биредә без 2018 елның август аеннан бирле яшибез. Америкада идеаль бала үстерү максаты юк. Малайлар-кызлар ничәлегә укыса да, проблема ясамыйлар. Монда ата-ана баласының яхшы билгеләре, уңышлары белән масаймый. Хәтта мәктәптә укучылар сыйныфташларының нинди билгегә укуын да белми, чөнки укытучы аны бөтен сыйныфка кычкырып әйтми.

Әйе, биредә дә өстәмә түгәрәкләр, спорт секцияләре бар. Гадәттә, балалар аның берсен сайлый. Мисал өчен, олы улыбыз бассейнга йөри. Казанда яшәгәндә дә йөргән иде. Уртанчы балабыз белән тхэквондога йөрдек. Пандемия аркасында әлегә туктаттык. Төпчек улыбыз әле кечкенә, 1 яшь кенә. Монда яшәгән татар кызлары белән еш аралашабыз. Россия белән Америка тормышын чагыштырабыз. Дөресен әйтим, биредә хатын-кызларга җиңелрәк. Маникюр, педикюр ясату, ботокс кадату кебек эшләр белән бик мавыкмыйлар. Хатын-кызларның күбесе табигый матурлыклары белән яши. Америкалылар ресторанга, кафега барганда да киенеп-ясанып утырмыйлар. Спорт костюмыннан кереп ашап чыгу – гадәти хәл.

Балаларга да җиңелрәк дип уйлыйм. Түгәрәкләргә ата-ана кушуы белән йөрмиләр. Теләге булса – бара, юк икән – бармый. Өй эшләре дә Россиядәге белән чагыштырганда бик аз. Алар аны һич авырыксынмыйча, мөстәкыйль рәвештә эшләп куя.

лар бакчасында йөргәндә тәрбиячеләре бассейнга алып бара иде. Шуннан үзенә дә ошап китте. Хәзер дә йөзү секциясенә йөри. Икенче сыйныфтан баянга язылдык. Тагын хоккей түгәрәгенә дә барып караган иде, яратмады. Кыскасы, үзенә нәрсә ошый, шунда бара. Мәҗбүр итү дигән нәрсә юк. Икенче кызыбыз Әминә исә балалар иҗат мәктәбендә шөгыльләнә. Дәрестән соң үзләре баралар. Балаларны түгәрәккә йөртәсе бар дип, эш ташлап чыгып китмибез...

Шәһәр белән район үзәген чагыштырсак, соңгысында балалар бушка шөгыльләнә. Мисал өчен, Казанда бассейнга бер айлык абонемент 3 мең сум тирәсе... Бию түгәрәкләренең дә хакы шул чама... Ләкин сүз башы бит Шүрәле. Балаларны кечкенәдән төрле түгәрәкләргә йөртү кирәкме? Төрле ата-аналарның фикерен белештем. Күбесе: «Заманнан артка калмаска тырышабыз, балаларны төрле җирләргә йөртәбез», – ди. Шәһәрдә үскән коллегам исә: «Әни мәҗбүри музыка мәктәбенә йөртте. Кулга аттестат алдым, тик ул миңа кирәк тә булмады. Үзем җәфа чиккән дә җиткән дип, кызымны махсус бер җиргә дә йөртмәдем», – диде.



«Бала-Сити» үзәге директоры Альбина НАСЫЙРОВА:
«Бала кечкенәдән ачылырга тиеш дип саныйм. Ул яктан бүгенге әниләр булдыра».

«Бала-Сити» үзәге директоры Альбина Насыйрованы күпләребез белә. Ул – нәкъ менә заман таләпләренә туры китереп, беренче булып шәхси бакча ачкан кешеләрнең берсе. «Бала-Сити»да барысы да заманча: сабыйлар кечкенәдән берничә телне өйрәнә, күптөрле түгәрәкләр, заманча тәрбия ысуллары... Ата-анага сабыен өенә кайткач йоклатырга гына кала.

– Мин үзем дә «интенсив ана»лар рәтенә керәм, – диде Альбина Насыйрова. – Бала кечкенәдән ачылырга тиеш дип саныйм. Ул яктан бүгенге әниләр булдыра. Өйдә дә балалары белән бик шөгыльләнәләр яки төрле түгәрәкләргә йөртәләр. Бу шулай булырга тиеш, чөнки моны заман таләп итә. Конкуренция көчле бит. Күбрәк телләр белгән саен, зуррак мөмкинлекләр ачыла.

Һәр бала да сәләтле, дип саный Альбина Насыйрова. Шуны күрергә генә кирәк:

– Математикасы начаррак булып, рәсемне оста ясый икән, димәк, шул юнәлешне үстерергә кирәк. Бәлки, ул баладан киләчәктә бөек рәссам чыгар?! Өстәмә түгәрәкләр, иҗат мәктәпләре – барысы да баланың талантын ачарга ярдәм итә.

...Альбина ханымның фикере белән мин дә килешәм: әйе, балаларның сәләтен үстерергә кирәк. Әби-бабайлар бөтенләй дүрт сыйныф кына укыган, безгә дә шул җитә дип калмаганбыз бит. Кешелек гел үсештә. Бу шулай булырга тиеш, табигый хәл. Тик бүген аналар ярышка чыккан атлар кебегрәк: кем уздыра? Бу очракта миңа психологның фикере ошады: «Бәхет формуласы һәркемнең төрле». Әгәр анага баласын шулай түгәрәкләргә йөртү ошый, сәламәтлеге, акчасы җитә, ә иң мөһиме – бу балага да кызык икән, йөртсен. Тик моңа карап хатын-кызга ана буларак бәя бирелергә тиеш түгел, минемчә. Ана назы, бала күңелен аңлау, күзгә-күз карашып аралашу турында онытмыйк, алары мөһимрәк.

«Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү үзәге психологы Гөлфия Сәлахетдинова «интенсив ана булу»ның ике ягын күрә:

Уңай ягы (+)

- Бала игътибар үзәгендә, үзен яратканнарын тоеп үсә. Ата-ана улының, кызының белемен үстерү өчен барлык мөмкинлекләрне дә тудыра. Шул исәптән, йөрәк парәсенең сәламәтлеген дә кайгырта.
- Бала кая барып сугылырга белмичә, урамда йөрми, чөнки ата-ана тарафыннан тулы контроль бар.

Тискәре ягы (–)

- Бүген без ата-аналар тарафыннан балага карата тулы опеканы күрәбез. Шуңа күрә балаларда мөстәкыйльлек юк.
- Бала бөтен игътибар аңа гына булырга тиеш дип уйлый. Нәтиҗәдә, эгоизм формалаша.
- Бөтен җиргә өлгермәгән хатын-кызларда, мисал өчен, ялгыз аналарда, аз хезмәт хакы алып эшләүче гүзәл затларда төрле комплекслар барлыкка килергә мөмкин. Ул үзе турында «мин булдыксыз», дип уйлый башлый.
- «Интенсив ана булу» хатын-кыздан бик күп мораль һәм физик көч таләп итә. Ә бу сәламәтлеккә зыянлы.

УРМАН УЛ – ТОРМЫШ!



– Нык ул... Нарат шикелле! Үз сүзен өздереп әйтә белә. Җитәкче буларак бик зирәк. Куйган максатына ирешми туктамый... Хезмәттәшләре аның хакында шулай диләр. Республикабызда урманчылык җитәкчеләре арасында хатын-кызлар нибары икәү. Ул – шуларның берсе. «Бөгелмә урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе лесничие Гөлнара Зөфәр кызы МӨХӘММӘТХАНОВА белән сөйләшәбез. Аның әйткән һәр җөмләсе генә түгел, һәр сүзе урманны ярату белән тулы булуын сизми калмассыз. Ярату һәм урман өчен борчылу, ут йоту...



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Ничек урманчы булып китүегезнең берәр тарихы бармы? Кыз бала урман каравылчысы булырга хыялланмагандыр...

– Мин Киров өлкәсенең Сосновка шәһәрендә тудым. Дөресен әйтәм, урманчы дигән һөнәр барын Лубян урман техникумында укый башлагач кына белдем. Пединститутка керә алмыйча кире борылып кайттым. Баллар җитмәде... Әни: «Бер елыңны әрәмгә уздырма инде. Әнә Лубян якында гына... Әзерләнерсең дә, киләсе елга институтка тагын кереп карарсың», – диде. Техникумга кердем, ә кергәч инде тәмамларга кирәк иде. Лубянда бергә укыган курсташларым гына түгел, укытучыларым да бу өлкәдә эшләп калуыма, хәтта инде җитәкче вазыйфасын биләвемә әле дә шакката... Диплом алганчы ук Ютазы егетенә кияүгә чыктым. Ирем белән парлап 1997 елда Бөгелмә урманчылыгына эшкә кайттык. Мин инде бала көтә идем. Мастер итеп куйдылар. Кул астымда өч-дүрт урманчы. Гомер буе урманда эшләгән кешеләр. Ә син, кечкенә генә булса да, аларга җитәкче... Бик таләпчән идем. «Бу усал кыз кайдан килеп чыкты?» – дип зарланалар иде. Яшь идем бит, җитәкче дә булгач, үземне гел хаклы саный идем. Тормыш тәҗрибәсе зуррак булган кешеләр сиңа күбрәк бирә алганны аңлау соңрак килде...

Остазларымның барысы да ир-атлар булды. Бер очрак гел онытылмый. Мәрхүм Ринат Абдуллович кул астында эшләгән чагым. Ун гектар җирдә агач утыртырга куштылар. Зур мәйдан бу! Механикалаштырылган юл белән

утыртсаң да өч көн кирәк, ә кулдан – бер атна. Барсам, урманчы шундый күп халык җыйган. Сабантуй кадәр! Ул елларда яшьләр булмаса да, олылар агач утырту эшенә бик теләп чыга иде. Кирәген аңлап... Кыскасы, бер көн эчендә утыртып бетердек. Урманчылык бинасына кире кайттым. Каршыма Ринат Абдуллович чыкты: «Йә, бүген күпме утырттың инде?» – ди. «Бетердек», – дим. «Техникумда сиңа нәрсә генә өйрәттеләр? Җирнең мәйданын да саный белмисеңме?» – дип, ул мине машинага утыртып кире алып китте. Үз күзләре белән күрмичә ышанмады...

Үзегез дә әйтеп торасыз – урманчы булып барыбер күбрәк ир-атлар эшли. Ни генә булса да, алар сезне үз араларына алдылар, димәк?

– Җитәкче булып китүем дә шуңа – коллективта үз кеше булуыма бәйледер. Алар минем ничек эшли башлавымны, кем булуымны беләләр иде. Бигрәк тә – ютазылар. Ирем берара урман эшен ташлап, нефть өлкәсенә китеп торды. Кире әйләнеп кайткач, аны Бөгелмәгә чакырдылар. 2011 елга кадәр без бергә эшләдек. Аннан ул: «Бер гаиләгә ике урманчы күбрәк», – дип, кабат нефтьчеләр янына китеп барды... Бөгелмәдә инженер булып эшләп йөргән чагым. Җитәкчебез Газизов Госман Шакирович август аенда эштән китте. Ноябрь аенда мине Казанга, министрлыкка әңгәмәгә чакырдылар – урынбасар итеп расларга тиешләр иде. Әмма министр: «Резюмең әйбәт, җитәкче урынына утырасың», – диде. Мине тәкъдим итәргә министрның беренче урынбасары килде, коллективны җыйды:

– Ирләр, аз гына сабыр итегез! Иң күбе бер ай! Аннары сезгә чалбарлы җитәкче алып киләм! – диде.

Сигез ел була менә... Эштә күбрәк күлмәктән йөрим шул, урманга чыгасы булса гына чалбар киям. Гадәттә матуррак киенеп килсәң, гел урманга чыгарга туры килә. Сәбәп табылып кына тора. Күбрәк тәртип бозулар белән бәйле: йә каядыр законсыз агач кисәләр, йә нефтьчеләр нефть агыза... Шуңа күрә киемнең анысын да, монысын да кул астымда тотам.

Яңа елдан яңа бер штат алуга ирештем мин ул елны. Ун ел буе урманны саклау буенча инженер булмаган. Аны иң мөһим инженерларның берсе дип саныйм. Урынбасарым юк иде – ул килде... Барысы да җиңел генә булды дип әйтә алмыйм. 44 мең 133 гектар урман өчен җаваплы без. Биш административ районда урнашкан ул: Ютазыда, Баулыда, Бөгелмәдә, Лениногорскида, Азнакайда. Лубян урман техникумы эшләп торса да, белгечләргә моңарчы кытлык иде. Хәзер хәлләр үзгәрер. Президентыбыз Рөстәм Миңнехановка рәхмәт – республика бюджетыннан урманчыларның хезмәт хакын ике тапкыр күтәрү мөмкинлеген тапты. Урманга безнең күз белән карый ул... Урман хуҗалыклары сакланып калган өчен дә без рәхмәтле аңа. Россиянең башка төбәкләрендә урманнар арендаторлар кулында. Ә алар урманны күбесенчә кисә генә... Мәскәүгә квалификацияне күтәрү курсларына барырга туры килде. Мин анда: «Посадкалар утыртабыз», – дип сөйли башлагач, бөтен халык: «Татарстан башка планетада яши бугай», – дип шаккатты...

Җитәкче булырга тиеш тә түгел идем мин. Әмма бу язмыш бугай.

Республика техника белән дә бик булыша: безгә – урман сакчыларына да бирәләр, урман хуҗалыгына – лесхозга да. Барлык эшебез дә механикалаштырылган, кул хезмәте бик аз хәзер. Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры Равил Әфраим улы Кузюров та киләчәккә карап эшли торган кеше – без аның ярдәмен һәрдаим тоеп торабыз.

Гадәттә, һәр җитәкче нинди дә булса яңалык алып килә...

– Яңалык дип... Техникум тәмамлап кайтып, урман мастеры булып беркадәр эшләгәч, Ютазыда мине теплицаларга җаваплы итеп билгеләгәннәр иде. Җитәкче вазыйфасына керешкәч, мин иң элек һәр урманчыга үзендә кечкенә генә шундый теплица куйдырдым. Ни өченме? Әйтик, каенны питомникта үстереп, урманга күчереп утырткынчы ике-өч ел вакыт кирәк. Ә без хәзер каен орлыгын теплицага апрель аенда чәчәбез һәм шул ук елның сентябрь, октябрь айларында инде аларны турыдан-туры урманга утыртабыз. Безнең эшне шактый җиңеләйтә бу. Әлеге ысулны элек гел кулланганнар, аннан онытканнар. Без аны Татарстанда беренче булып кире кайтардык. Министрлык республиканың барлык урманчылыкларында шундый теплицалар куйдырды хәзер.

Каен агачын күпләп үстерәбез. Бездә урман-дала зонасы – ылыслыларга караганда, каен әйбәтрәк үсә. 2010 елгы корылыкта алар бик нык зыян күрде – 80 проценты инде киләсе елда яфрак ярмады. Самолетта очканда югарыдан күренә – җәен дә кыш көннәре кебек ап-ак булып тора, диделәр. Аннан ул каеннар ауды, череде, әрәм булды. Кисәргә мөмкин булганда рөхсәт юк иде... Менә шул каеннар урынында имәнлекләр үсеп килә хәзер. Кырыгынчы еллар картасын карасак, бездә элек гел имән үскән. Сугыш вакытында, аннан соңгы елларда аларны кисеп бетергәннәр. Үзең утыртсаң, имән барыбер әйбәт үсми ул. Бездә кыраулар яз ахырына кадәр, ә көзләрен иртә төшә: җәй башындагылардан исән калса да, көзге беренче кыраулар куркыныч аңа. Ә табигатьтә бит барысы да уйланылган: имән тишелгән җирдә шунда ук юкә килеп чыга, аннан аларга миләш килеп кушыла – имәнгә инде бернинди суык янамый, ул үзен саклаучылар белән бергә үсә. Өстендә – тун, ә башы яланбаш, дибез. Урман хуҗалыклары исә кишәрлекләргә, гадәттә, бер төрдәге агач кына утырта: имән икән – бары имән генә.

Урманчы үз хезмәтенең нәтиҗәсен тиз генә күрми, агачлар шундый әкрен үсә...

– Әйе, ул утыртканны киләчәк буын – оныклар гына файдалана ала. Икенче яктан, табигатьнең иң тиз яңара торган ресурсы ул урман. Моның өчен аңа нибары 60–100 ел кирәк. Мәңгелек өчен мизгел генә бит бу... Аннан агачлар барыбер күзгә күренеп үсә: быел яныннан узып китәсең – әле үлән арасында гына була, киләсе елга инде үләннән баш калкыта...

Язгы урманны яратам! Яңа бөреләр, яңа яфраклар. Яңа тормыш!

Лениногорск районында «Роснефтекомплект» компаниясе җитәкчесе Рослов Владимир Алексеевич бар. Шәһәрне яшелләндерү буенча ул бик күп эш башкара. Без дә аңарга байтак агач утырттык. Беркөнне ул шалтырата: «Кишәрлек яныннан узып барам… Наратлар, чыршылар миннән биегрәк булып үсте бит инде… Шуларга карыйм да куанам: юкка гына яшәмәдем!» – ди. Мин аны бик аңлыйм…

Урманның уянып кына килгән чагын яратам… Май башы була бу. Безнең өчен яңа ел – эш башланган чак та. Элек урман каравылчысы кышын йоклый, язын эшли башлый, диләр иде. Хәзер ел әйләнәсе эшлибез: Яңа ел бәйрәменә чыршылар сатып туктагач, аз гына тынлык булып ала да аннан отчетлар, документлар белән мәшгульбез. Хәер, закон бозучылар урманда кышын да җитәрлек.

Урманның иң зур дошманы…

– Кешеләр! Урмандагы 99 процент янгыннар кешенең саксызлыгы аркасында килеп чыга. Язын, көзен урманчыны һәр төтен сискәндерә. Янгын безнең өчен фаҗига ул. Май бәйрәмендә яңгыр яуса, шуннан да зур куаныч юк. Яңгыр койса иде, кешеләр урманга керә алмаса иде дип, алдан ук теләп йөрим… Янган җир тиз генә яшәрә алмый. 2010 елны янгын булды. Без генә түгел, бик күпләр янды ул елны… Менә шул урында агач түгел, яшел чирәм дә үскәне юк әле. Йөгерек ут кына булса ярый әле, ул коры үләнне генә яндырып китә, ә төпкә төшсә?! Тагын шул 2010 елны искә төшерәм. Янгынны сүндереп кайтып киттек – каеннар ямь-яшел калды. Өч көннән килсәк – барысы да ауган. Аста торф булган икән, шул янган… Җир астындагы янгын – иң куркынычы. Ул елны Ютазы янындагы янгын кыш буе басылмады – язгы сулар гына җир астына төшеп сүндерде… Янгыннарның күбесенә бүген авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре гаепле. Узган елдан калган салам, печән күче төбенә ут төртеп җибәрәләр. Ә язын аяк астындагы үлән күкерт кебек – ут әллә кайларга үрмәләргә мөмкин. Бер фермерның хәтта яңа тракторы янып китте шулай. Утны үзе төрткән, тик аннары инде туктата алмаган. Ә кырдан ерак түгел урман башланса?! Сезон ябылганчы тәүлек әйләнәсе кулдан телефон төшми инде… Дөрес, 2011 елдан бирле Татарстанда урманнар янганы юк анысы. Безгә бирелгән янгын сүндерү техникасы да яңа килеш торсын иде. Урманнарны сакларга кирәк, алар бездә болай да күп түгел. Авыл хуҗалыгы министрлыгы программалары буенча, республика бюджеты хисабыннан, елга 2 мең гектар җирдә урман утыртыла. Без үзебез ул программа буенча 50 гектарга кадәр утыртабыз. Ә болай һәр ел саен 80–100 гектар дәүләт урман фонды утыртабыз.

Кешенең урманга салган тагын бер зыяны – чүп калдыру. Урманга килеп ял иттең, тәэсирләр алдың, инде артыңнан чүбеңне җый да бит… Ял итү урыннары, чүп ташлау урыннары да әзерлибез… Йөге белән калдыралар, алай гына түгел – китереп аударалар. Гаеплеләр сирәк табыла, күбрәк урман хуҗалыгы хезмәткәрләре үзләре җыештыра.

Законсыз агач кисүләр күп дип әйтә алмыйм менә. Моны рөхсәт белән эшләү җайлырак икәнен халык инде күптән аңлады. Барыбер табабыз. Күп вакыт күршеләр җиткерә… Штрафлар да зур. Кеше агачны рөхсәтсез кисcә, без 5 меңнән күбрәккә штраф салсак, аңа шунда ук җинаять эше дә ачыла. Бер имәнне аударган өчен штраф, мәсәлән, 40 меңнән артык.

Сез эшли башлаган чор белән чагыштырганда, урманчының дәрәҗәсе күпкә үзгәрдеме?

– Кызганыч, күпкә… Без эшкә иртән җидегә киләбез, ә ишек төбендә инде чират җыелган була иде элек. Кырыгышар кеше! Урманда печән чабарга да урманчыдан рөхсәт язуы кирәк иде бит. 2007 елда урман каравылчыларын, гомумән, кыскарттылар. Менә мин элек Ютазыдагы участокта эшләгәндә, анда, җитәкчедән кала, 3 мастер һәм 12 урман каравылчысы бар иде. Ә хәзер лесничий һәм 5 мастер гына эшли. Урман каравылчысы 600–800 гектар мәйданны контрольдә тота: ул шунда – кордонда яши, аның бөтен нәрсә күз уңында, шуңа урманда тәртип иде. Ул урманның хуҗасы иде! Ә бүген бер мастерга 3,5–5 мең гектар урман туры килә. Моның кадәр мәйданны әйләнеп чыгу берничек тә мөмкин түгел!

Россия Президентына урман каравылчысын урманга кире кайтару бик мөһим икәнлеген, ниһаять, аңлаттылар. Дөрес, тагын бер тикшерүче орган оештыру хакында да сүз бара. Дәүләт Думасы ничек хәл итәр… 2021 елда пилот регионнар бу эшне инде башлый – нәрсәдер үзгәртәчәкләр. Татарстан да алар арасында булыр дип уйлыйбыз. Мин үзем урман каравылчыларын кире кайтарырлар дип бик өметләнәм. Гомумән, Россиядә урман хуҗалыгы өлкәсендә зур үзгәрешләр булырга тора. 2006 елда кабул ителгән Урман кодексы урманчылар түгел, ә күбрәк сәнәгатьчеләр өчен икәнен таныдылар инде. Владимир Путин күрсәтмәсе буенча, инде 2022 елда ук илдән бер кубометр агач та читкә чыгарга тиеш түгел. Бездә, Татарстанда, урман кисү белән генә шөгыльләнүче арендаторлар бөтенләй юк диярлек анысы. Урманнарыбыз күбрәк саклау функциясен башкара. Кайбер оешмалар – ут кертүчеләр, нефтьчеләр өчен урманны кисәргә туры килгән очраклар бар, билгеле. (Әмма Урман кодексы буенча, ничә гектар киссәләр, алар шуның кадәр утыртырга да тиеш. Һәм бу бездә һәрвакыт үтәлеп килде.) Тик ничә еллар карап торган агачларыңа балта күтәрү бер дә җиңел түгел. Урман бит ул бала кебек. Агачны кишәрлеккә күчереп утыртуга тәрбияли башлыйсың: беренче биш елда чүп үләннәреннән арындырып торасың, аннан тирә-юнендә үсеп чыккан кирәкмәгән агачлардан аралыйсың. Кисүдән саклыйсың. Алар күз алдында күтәрелә, ныгый… Шундый бер очрак булды. Нефтьчеләргә 10–15 яшьлек наратларны кисәргә кирәк иде. Урманчы баш тартты: «Үзем утыртканны үзем кисә алмыйм. Кулым күтәрелми…» – диде…

Мин – дәүләт урман инспекторы. Икенче төрле әйткәндә – урман «полицае»: тәртип бозучыларны ачыкларга тиеш. Урман хуҗалыгы белән икебез ике юридик оешма. Әмма аларның артыннан гаеп эзләп, ялгышлары өчен җәзага тартып йөрү урман өчен файдага булмаячак. Урман өчен кулга-кул тотынышып эшләвебез хәерлерәк. Һәрхәлдә, бездә шулай. Бөгелмә урман хуҗалыгы директоры Сәгыйд Абдуллин белән һәрвакыт киңәшләшеп эшлибез.

Идеаль урман сезнең өчен нинди урман ул?

– Идеаль урман? Анда агачның төрле төре үсәргә тиеш. Элек урманга керсәң, рәхәт, җиләс була торган иде, ә хәзер андый урыннарга сирәк тап буласың. Климат үзгәргәнгә шулай бу: кышлар җылы, кар елдан-ел аз бит. Урман-дала зонасыннан әкренләп шулай дала зонасына күчеп барабыз бугай... Идеаль урман эчендә күләгә бар. Каядыр чишмә чылтырый, кошлар сайрый... Тынлык. Шунда ук җанга рәхәтлек иңә. Безнең урманнарда җимеш бирә торган агачлар күп – кошлар тырыша. Язын алар чәчәк атканда күзең ял итә... Урман хуҗалыгы җитәкчесе буларак, идеаль урман – сәламәт урман дип тә әйтәм. Узган ел менә яңа корткыч барлыкка килде – «кольчатый коконопряд». Башкортстан ягыннан килгән бу күбәләк башта бакчаларда гына күренә иде, аннан урманга күчте. Күзәтеп торабыз: без дә, урманны саклау үзәге дә. Киләсе елга инде агачларны эшкәртеп чыгарга акча бүленер дип көтәбез. 2015 елда «непарный шелкопряд» белән көрәшкән идек. Хәзер күбрәк кошларга да, хайваннарга да зыяны тими торган чараларны сайлыйбыз. Ул чаралар корткычның алдагы буыннарына тәэсир итә: күбәләк йомыркадан чыга, әмма үзе салган йомырка инде нәсел бирергә сәләтсез була.

Каядыр читкә баргач та урманнар карап йөрисездер, мөгаен?

– Әйе, нәкъ менә урман гына күрәм дә. Узган ел Төркиягә баргач, кич белән йөрергә чыктык. Күзем шунда ук наратларга төште. Биекләр, матурлар! Һәрберсенә ниндидер номер сугылган. Кызыксынып, интернетка кереп киттем. Аларда ылыслы агачлар исәптә икән! Һәрберсе! Номерына карыйсың да, ул агачның кайда үскәнен, яшен беләсең. Тирә-юньне яшелләндерү белән шөгыльләнүче питомниклары күп булуына да игътибар иттем – кырларда ике-өч чакрым саен очрый. Бездә әле бу күренеш башланып кына килә. Питомникны әкрен генә шушы юнәлешкә борырга тырышабыз – агачларның декоратив төрләрен утырта башладык. Халыкта инде ихтыяҗ бар, кызыксыналар. 2015 елда Саба урманчылыгы спонсор ярдәме күрсәтте – безгә 5 мең төп тау нараты үсентесе бирде. Инде үстеләр. Матурлар! Төркиядән нарат күркәләре алып кайткан идем – өчесе үсеп килә менә. Үзебез генә түгел, туганнар да шулай орлык, үсенте ташый безгә. Камчаткадан «кедровый стланик» орлыгы алып кайткан нар иде – тишелделәр. Бер-ике елдан питомникка күчерербез дип торабыз.

Безнең эштә урманны яратсаң гына эшләп була. Ә аны ярату безнең кандадыр инде... Мин үзем урманда ял итә алмыйм: кайда кисәргә кирәк, чистартырга, кайда утыртырга – гел шуны карап йөрим...



Равил КУЗЮРОВ, Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры

Күпләр, урманчы – фәкать ир-ат кына башкара торган һөнәр, дип уйлый. Тик бу алай түгел. Хәзерге вакытта Татарстан Республикасының урман тармагында 2652 кеше эшли, шуларның 793 е – хатын-кыз. Хатын-кызлар җитәкче урыннарда, урманны саклау һәм яклау буенча инженер, урман остасы, бухгалтер, кадрлар буенча белгеч кебек вазыйфаларны билиләр, базислы урман питомникларында һәм җитештерү участокларында эшлиләр. Аларның барысы да үз вазыйфаларын җиренә җиткереп башкара.


Хатын-кызлар үз эшендә җаваплы, башкаручан, төгәл һәм вак-төякләргә дә игътибар итүе белән аерылып тора. Урман хуҗалыгында очраклы кешеләр була алмый, аларның барысы да урманны чын күңелдән ярата һәм үз эшен намус белән үти.



ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да... Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

ВЛКСМның XX съезды делегаты
































Фото: Анна Арахамия

Йолдыз ГАРИПОВА:
«Без хезмәт тәрбиясе белән үскән буын. Әти-әни йөзенә кызыллык китермик, кеше алдында сынатмыйк – тормыш девизым шул булды. Мин аңа бүген дә тугрылык саклыйм».

Ялкынлы комсомол, слетлар, съездлар, социалистик ярышлар, кызыл почмактагы дискотекада таңга кадәр биюләр, планнарны тагын да арттырыбрак үтәргә дип икешәр смена калып эшләүләр – бу аның яшьлеге. Мәктәпне тәмамлап, «Казанрезинотехника» берләшмәсенә эшкә килгәндә яшүсмерлектән чынлап торып чыгып та җитмәгән була әле Йолдыз. Биш авылдаш кыз – бишесе дә шушы берләшмәне сайлый. Юк, башта 55 нче техник училищеда бер ел укып, зур-зур машиналарны буйсындырырга өйрәнәләр әле. Станоклар гөрелтесеннән үз тавышыңны да ишетә алмаслык цехка беренче тапкыр 1985 елда аяк баса ул. Тәүге эш көне әле дә күз алдында:

– Мине машиналарның тормоз системаларында кулланылучы җиңсәләр җитештерүче 4 нче цехка билгеләделәр. Шлангларның тышкы ягын җеп белән үрдерүче алты машина гөрелдәп эшләп тора. Андый тавышны гомеремдә беренче тапкыр ишетүем, баштаракияләшүе бик тә авыр булды, – дип искә ала Йолдыз ханым ул чакларны. – Остазым Гөләндәм апа Идрисова иде. «Бик усал, ничек кенә эшләрсең инде», – дип колагыма пышылдашты цехтагы кызлар. Таләпчән, туры сүзле диләр иде аны. Ә мин аның белән беренче көннән үк бик җиңел эшләп киттем.

Йолдыз Вәлиеваның (хәзер Гарипова) фотосы – «Азат хатын» журналының 1987 елгы апрель саны тышлыгын бизи. Шул елны ВЛКСМның ХХ съездына делегат булып бара ул.

– Тормышымның иң матур, иң истәлекле мизгелләренең берсе булды ул көннәр, – дип хатирәләрен яңарта Йолдыз ханым. – Съездда илебезнең бар төбәкләреннән сайланган делегатлар катнашты. Сыер савучы яшьләр, механизаторлар, терлекчеләр, эшчеләр, төзүчеләр... Без Татарстаннан да күбәү идек. Мәскәүгә кадәр поездда җырлап барганыбыз хәтердә. Башкалага татар халкының милли киемнәреннән аяк бастык. Кызыл Мәйданны, Мәскәү Кремлен, мавзолейны беренче тапкыр шул чакта күрдем. Мин эшләгән берләшмә ул елларда Нефтехимия промышленносте министрлыгына карый иде. «Министрның үзенә бирергә тырыш», – дип, җитәкчебез үтенеч хаты язып тапшырды. Министр Николай Лемаев шул чакта үтенечебезне тыңлаган иде.

1987 елда делегат кыз турында газеталарда да языла. Аны урамнарда таныйлар, «сезнең хакта укыдык», – дип сүз каталар, хатлар язалар, егетләр мәхәббәт аңлата... Әле бүген дә якташлары арасында «Азат хатын»ның син чыккан санын саклыйм», – диючеләр бар икән.


– Эш авыр булса да, без аны сизмәдек. Кайчагында рәттән икешәр смена эшләргә туры килде. Эштән кайтып, тамак ялгап алабыз да, тулай торакның кызыл почмагына дискотекага йөгерәбез. Барыбыз да дус, бер гаилә балалары кебек яшәдек.

Һәркем белән уртак телне тиз тапкан, эштән авырыксынмаган, ярдәмгә атлыгып торган кызны яшьләр үзләренең комсоргы итеп сайлый. Сынатмый Йолдыз, аларның группасы бөтен берләшмәдә иң алдынгылардан санала.

...«Казанрезинотехника» берләшмәсе әле дә эшчәнлеген дәвам итә. Дөрес, атамасы башка хәзер. Йолдыз ханым белән бергә хезмәт куйган, аны хәтерләгән кешеләр анда әле бүген дә эшли. «Аралашкалап торабыз. Ул цехларда минем яшьлегем эзләре. Ә яшьлек онытыламыни!» – ди ул.

Лилия ГӘРӘЕВА

НӘСЕЛ ТОТКАСЫ



Аларны Актүбәдә һәркем белә. Атаклы генерал Чанышев белән бер нәселдән булганга гына түгел. Игелекле гамәлләр, матур эшләр, кемнәргәдер кылган яхшылыкларның гомере озын бит аның... «Кеше дөньяга килсә дә, китсә дә Раил кирәк», – дия торган булган бистә халкы. Юкка әйтмәгәндер. ТАССРның атказанган нефтьчесе, Актүбәнең почетлы гражданины Раил Абдулла улы Чанышев турында сүзем. «Азнакайнефть» (ул эшли башлаган «Актүбәнефть» идарәсе 1996 елда «Азнакайнефть» белән кушыла) нефть һәм газ чыгару идарәсенең эксплуатацион җиһазларны прокат-ремонт цехы начальнигы була ул. Иң зур цехларның берсе! Ул аны үзе төзи. Заманында бирегә эшкә урнашырга халык чират торган. Чанышевлар – «Азнакайнефть» идарәсендә иң зур династияләрнең берсе. Барысының эшләгән елларын бергә кушсаң, 470 ел килеп чыга! Һәм ул гел арта бара. Аларның һәммәсен бер өстәл артында җыярга теләгән идек. Нәрсә турында гына сүз башласак та, ул барыбер мәрхүм Раил агага килеп тоташты.

Гөлнур ХӘСӘНШИНА



Ауфә апа, (җәмәгате):

– Без Раил белән классташлар. Такчура дигән авылда бергә укыдык: ул Күзәйдән килеп йөри иде, мин – Усманнан. Җиденчедән соң кайсыбыз кая таралышты. Еллар узды... Бертуган апамны педучилище тәмамлаганнан соң Күзәйгә эшкә җибәрделәр. Аны фатирга Раилләргә керткәннәр булып чыкты. Шулай итеп, кабат очраштык... 1957 елның апрелендә өйләнештек. Раил Баулыга эшкә китте, аның артыннан инде мин дә. Актүбәгә килеп урнашканда монда бараклар төзи башлаганнар иде инде. Тик анысы да бөтен кешегә юк бит әле. Авылда бер бабайларга фатирга кердек – ишегаллларындагы сарай кебек җирдә тордык. Аннан бергә – бистәгә берәүләргә күчендек. Балалар туды – Римма, Роза, Эльза. Декрет яллары кыска – 56 көннән инде эшкә чыгабыз. Ярый тирә-күрше карчыклар булышты...

Эльза ханым (кызы):

– Әти Актүбәгә килүгә үзе янына туганнарын да чакыра башлый. Бер-бер артлы алар барысы да шушында килеп урнашалар: Нәсимә апа, Рәшит, Ирек абыйлар... Рәшит абыйлар Башкортстандагы йортларын бергә күчереп салдылар, алар белән Маһирә нәнәй дә сыерлары, печәннәре белән бергә күченде. Төп йорт кебек иде ул безнең. Атна саен шунда җыелабыз. Бәрәңге алып бетерсәләр дә бәйрәм иде, мал суйсалар да... Сугымга дигән терлек-туарны күбрәк Рәшит абыйларда тоталар иде. Бөтен Актүбә терлек асрый иде ул чакта. Иртәнге сәгать алтыда эшкә чыгып китәләр, өчтәндүрттән торып исә, чиләк тотып, маллар ашатырга баралар. Һәркемнең сарае читтә иде. Әти белән әни дә бер чиләк бәрәңгене юып, безгә малларга илтергә кушып калдыралар. Юллар әле юк, аяк асты саз, итекне сөйрәп алып булмый. Бу багана арасын гына барам да, ял итәм дип атлыйсың... Башлангыч классларда гына укыган чак әле бу. Безне эшкә өйрәтеп, мөстәкыйль итеп үстерделәр. Үзебезнекеләрне без дә шулай тәрбияләдек. Терлекне гомер буе асрадык. Хәзер дә сыерыбыз бар.

Әти кайчак эштән атналар буе кайтмый. Нефть ятмасының әле көчле чагы: ул ташый, түгелә – гел аварияләр... Сагынганмындыр инде, әнигә: «Әти турында сөйлә әле», – дигәнемне хәтерлим.

Әни дә, әти дә хезмәт юлларын гади эшче булып башлаганнар. Әни скважинада оператор иде. Эшкә вахта алып китә: өсте яртылаш бөркәүле машина. Буранда да, яңгырда да, җилдә дә... Кияргә киеме, юешләнгәнне киптерергә урыны юк бит әле аның. Әни әле дә сөйли: бер скважинаны караганда янына пошилар килеп чыга. Ә язын алар шактый куркыныч. Әни скважина мәйданчыгына көчкә менеп өлгерә. Дүрт-биш сәгать шунда – ачы җилдә, салкында басып торырга туры килә аңа. Соңыннан ул бик каты авырый, көчкә исән кала.

Ә әти... Ул гел эш дип янды! Кешеләр турында уйлады! Туксанынчы елларда, эш урынында кыскартулар башлангач, «Оста куллар» дигән ферма төзеп куйды. Кош-корт үрчетте, соңрак ак төлке асрады. Кемгәдер эштән китәргә туры килсә, аларны шунда ук «Оста куллар»га алды һәм, беренче мөмкинлек булу белән, цехка кире кайтарды.

Әти 45 ел гомерен «Татнефть»ка багышлады, әни – 40, мин 30 елымны... Геолог булдым. Уфа нефть институтында Нәсимә апаның улы Рамил белән бер чорда укыдык. Диплом алгач мине «Җәлилнефть»кә җибәргәннәр иде, биш елдан Актүбәгә кайттым. Соңгы елларда идарә аппаратына күчерделәр: 14 ир-ат арасында 2 хатын-кыз эшләдек. Әтинең сеңлесе Нәсимә апаның да 28 ел гомере нефть өлкәсе белән бәйле булды. Аның ире Әсгать абый иртәрәк китте, ул да гел шушы өлкәдә эшләде. Әтинең энесе Ирек абый да нефтьче иде – гади эшчедән мастер дәрәҗәсенә күтәрелде. Аның хатыны Мауа апа идарәгә караган балалар бакчасында табиб булып эшләде. Бик ярдәмчел иде... Сафуан Шәйхидаровичның да хезмәт стажын безнекенә кушарга мөмкиндер – күптән гаиләбезнең бер әгъзасы. Сөенечебез бар әле – аңа яңа гына «Татарстанның атказанган нефтьчесе» дигән мактаулы исем бирделәр. Горизонталь скважиналарны төзү һәм бораулау белән шөгыльләнүче «Азнакаевский горизонт» компаниясендә дә безнекеләр шактый: минем ике улым Айдар белән Эльдар, Рәшит абыйның улы Илгиз, Розаның улы Рөстәм...

Сафуан Бәдриев («Азнакаевский горизонт» компаниясенең генераль директоры, кияүләре)

– Актүбә бистәсенә 1956 елда нигез салына. Нефть ятмалары ачылгач, бөтен Советлар Союзыннан бирегә халык агыла башлый: Белоруссиядән, Украинадан, Азәрбайҗаннан... Үземнең әти-әниләрем аз гына алдарак – 1954 елда күчеп килмәләр. Алар – бораулаучылар, ә бораулаучылар нефтьчеләрдән һәрвакыт алданрак йөри. Белемле кешеләр күп килә ул вакытта, Актүбә бу яктан аерылып тора дип хәзер дә әйтәләр. Нефть ятмаларын үзләштерү белән бергә, бистәнең инфраструктурасы да төзелә – балалар бакчалары, мәктәпләр, сырхауханәләр, юллар... Бистә күз алдыбызда күтәрелде. Һәркем тормышын бараклан башлаган монда. Шуңа күрә барыбызның да әти-әниләренең тарихы – бер. Безнеке дә... Күбебез алар юлыннан китте бит. Бу гаиләдә дә шулай ул.

Чанышевларга килеп кушылуыма инде 40 елдан артык. Күптән үз кеше... Арада иң өлкәне мин хәзер. Раил Абдуллович турында да бик озак сөйли алам. Андыйлар сирәк! Сез аңа бирелгән бүләкләрне генә карагыз – алар үзләре үк күп нәрсә хакында сөйли! Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Халыклар дуслыгы ордены, Бөтенроссия халык казанышлары күргәзмәсенең көмеш медале... «ТАССРның атказанган рационализаторы». Эш кешесе иде! Аның кебекләргә «эш пәрие», диләр. Ул, мөгаен, һәрвакыт бик күпкә алга карап яшәгәндер. Йортлар төзүен әйтәм әле. Аның кебек цех начальниклары күп иде, тик берсе дә бу эшкә тотынмады бит. Үзем дә бүген җитәкче кеше, әмма бер поддон кирпеч өчен дә халык чират торганда, аның кирпечне машина-машина ничек алып кайта алуын барыбер аңлый алмыйм. Ничекләр итеп сөйләште икән ул?



■ Эльза ханым: «Әнигә тиздән 90 яшь тула. 10 яшеннән колхозда эшләгән, тыл ветераны санала. Яшәүдән арыганы юк әле аның. Бүгенгә кадәр ипине үзе сала. Безне дә шуңа өйрәтте, кибет ипиен ашый алмыйбыз, хәтта санаторийга ялга барганда да үз ипиебез белән барабыз».

Барысы артыннан гел үзе йөрде: акчасын да тапты, төзелеш материалларын да. Ул елларда бит! Өстәвенә, төп эшеннән кала. Шуңа күрә аның цехында беркайчан торак мәсьәләсе тормады. Әйе, үзеннән бигрәк кешеләр турында уйлады ул…

Раил Абдуллович һәр көнне иртәнге өчтә-дүрттә үк инде аяк өстендә була иде. Гомер буе терлек тоттылар бит – иртән малларны карап китә. Эштән кайткач, печән чабарга бара. Ул бөтен нәрсәгә өлгерә иде! Минем Уфада укып йөргән чак, диплом якларга әзерләнәм. Өч йөз чакрымдагы Уфага барып: «Киявемнең хәлләре ничек анда?» – дип сорашкан. Мин әле дипломны якламаган, ә ул инде билгесен белә иде. Хатынымның да әле студент чагы – аның да өлгерешен белешеп чыккан. Нәсимә апаның улы Рамил дә Уфада укыды – аның хәлен белешергә дә барды. Ул, чынлап та, гаилә, нәсел башлыгы иде. Чын ир-ат! Һәр гаиләдә нинди дә булса проблема гел чыгып тора бит: туганнарның барысы да киңәш сорап аңа килде. Мин үзем дә аны гел сагынып искә алам. Нәселнең татулыгы аңардан да килә.

Үзеннән югарырак торган җитәкчеләргә дә турысын әйтә ала иде Раил Абдуллович. Ул елларда «Актүбәнефть» идарәсен Раувел Ишкаев җитәкләде. Икесе дә зур шәхесләр иде: эшне бергә башлаганнар, элемтәләре дә нык. Икесе дә белемле, принципиаль, үз сүзләрен өздереп әйтә белә. Җыелышларда бүген дә: «Ишкаевлар, Чанышевлар җитми!» – диючеләр очрый…

Эльза ханым:

– Күпме кешене йортлы итүен белгәч, бер журналист әтидән: «Ә үзегезгә йорт салып кердегезме?» – дип сораган иде. Салмады! Ике гаилә өчен төзелгән коттеджның бер ягындагы фатирны безгә, икенче ягын әтинең цехында эшләүче бер эшчегә бирделәр. Хәзер дә әни белән шунда яшәп ятабыз.

Нәсимә апа (бертуган сеңлесе):

– Без өч бертуган үстек. Раил абый – иң олысы. Актүбәдә эшкә урнашуга ул безне дә үзе янына чакырды. Мин ул чакта Уфада эшли идем. Хезмәт хакы кечкенә, фатир юк. Тәвәккәлләдем. Беренче мәлләрдә абыйларда тордым, аннан тулай торакта урын булды. 1959 елдан бирле яшим Актүбәдә. Шушында кияүгә чыктым, балаларым туды. Оператор булып эшләдем. 28 ел бер урында… Безнең бөтен балалар «Оста кул»да эшләп үсте. Аннан – балаларның балалары. Берсендә күрәм, абыйның ике оныгы Айдар белән Эльдар, җиңнәрен сызганып куеп, ферманың сеткаларын буяп яталар. Эльза гел әйтә: «Эшкә безне әти өйрәтте, яхшылыкка – әни», – ди.

Венер Чанышев («Азнакайнефть» идарәсенең өлкән инженеры):

– Безнекеләрнең барысы да югары белемле, һәм күбесе Уфада укыды, ә мин Мәскәү нефть институтын сайладым. Кем булырга дигән сорау безнең алда тормады. Раил абый үзе белән эшкә еш алып бара иде: барысын да күрсәтә, аңлата… Каникулларда эшкә урнаштыра. Аның цехында эшләүнең перспективалы икәнен, дәрәҗә икәнен белеп үстек. Актүбәдә 18 ләп йорт төзеде ул. Бу цехка урнашасың икән, димәк, фатирлы буласың дигән сүз. Һәм бер генә тапкыр да түгел…

Институтны 1993 елда тәмамладым. Базар мөнәсәбәтләре тормышка кереп килгән чор. Раил абый: «Безгә урнашасың, монда эшли башлыйсың», – диде. Оператор булып урнаштым. Кайсыбызны гына алсак та, һәммәбез шушы юлны узды – иң түбәннән башлады… Башта оператор, аннан цех начальнигы урынбасары, цех начальнигы, бүлек начальнигы булдым, инде менә идарәнең өлкән инженеры… Мин дә инде бу өлкәдә 27 ел. Ветераннар белән аралашканда, алар: «Элек физик эш күп иде, бүгенге комфортлы эш шартлары безгә эләкмәде», – диләр. Әйе, кул хезмәте 90 процентка бетерелде. Әмма нефтьне табу күпкә авырлашты: акыл, баш белән эшләү сорала хәзер. Безнекеләр, әйткәнемчә, барысы да югары белемле. Бер генә дә түгел… Шуңа һәркайсы нининдидер вазыйфа били. Киңәшләшеп, сөйләшеп эшлибез. Бәйрәмнәрдә бергә җыелган чакларда да күп вакыт сүз, үзебез дә сизмәстән, эшкә күчә. Дөрес, безнең арада башка һөнәр ияләре дә байтак.

Римма ханым (кызы):

– Әти һәрвакыт безнең барыбызны бергә җыярга тырышты. Өлкәннәр кунакка килә икән, яшьләр дә килергә тиеш иде. Махсус безнең өчен аерым өстәл куйдырта иде. «Үзегез генә дә очрашыгыз, аралашыгыз, бер-берегезгә таяныч булыгыз», – дия иде. Без бүген дә шул гадәтне дәвам итәргә тырышабыз. Ускәндә, әйткәнебезчә, күбрәк Рәшит абыйларда җыелыша идек.

Без бала-чагалар да шунда үсте. Нәнәй тирәсендә. Җиңгәбез Зоя апа да ачык йөзле иде. Кунакчыл! Мунчасын да яга, токмачын да баса... Зоя апа бик матур җырлый иде. «Кыңгырау», – дия иде аңа әти. Барыбыз бергә җыелып әтинең туган якларына кайтканда, Актүбәдән Күзәйгә кадәр җырлап кайта иде Зоя апа. Туган нигезендә кеше калмаганга – Чанышевларның ил буйлап таралуына йөрәге бик әрни иде әтинең...

Эльвира ханым (энесе Рәшитнең кызы):

– Безнең дуслыкка, татулыкка бистәдәгеләр сокланып та, көнләшеп тә карый. Туганнан туган дигән сүз юк – бертуганнар кебек без. Шатлыкта да, кайгыда да – бербөтен. Әти-әниләр шулай тәрбияләде. Без энем белән башта менә әнине җирләдек, аннан сигез айдан әтине... Иң авыр чакта туганнарым таяныч булды... Янгын кебек зур афәтне кичерергә туры килде. Бөтен туганнар дәррәү күтәрелеп булышты ул чакта.

Ә Раил Абдуллович – Раил абый турында бик күп сөйләп була. Бу өлкәгә мин дә аның киңәше, аның ярдәме белән килдем. 17 ел дозиметрист булып эшләдем – нефть объектларындагы нурланышны тикшердем. Ул һөнәр хәзер безнең өлкәдә бетерелде. Мине установка операторы итеп күчерделәр. Ике ел инде резервуарлар арасында эшлим. Нәсимә апа: «Резервуарларны ике сәгать саен рулетка белән үлчи, проба ала идек», – дип сөйли. Без аларны хәзер күбрәк компьютер аша күзәтәбез, әмма резервуарларга мин дә менәм: компьютер күрсәткәннең дөресме-юкмы икәнен гел тикшереп торабыз. Яңгырда да, карда да, челләдә дә... Эш шартлары күпкә җиңеләйсә дә, һәр чорның үз авырлыклары инде аның. Зарланганыбыз юк: бу юлны үзебез теләп сайладык. Әти-әниләр безгә үрнәк булды.

Эльза ханым:

– Әни бик зирәк, акыллы хатын булды безнең. Әти гомере буе эш дип янды. Тынгысыз иде: бөтен нәрсәне йөрәгенә якын алды – производстводагы проблемаларны да, Россия икътисадындагы үзгәрешләрне дә. Һәркайсын уңай якка үзгәртергә тырышты – бөтен нәрсәдә камиллеккә омтылды. Һәм ул күңеле, җаны белән кайдадыр ял итәргә, үзенә көч алырга да тиеш иде бит. Өйдә, билгеле. Кайчак кәефсез дә кайта иде. Әмма әни аны көйли белде. Түзә белде. Алай гына түгел – кирәк юнәлешкә бора белде: туры сүзен әйтте. Ә әтидән хәтта Ишкаев үзе өркә иде бит...

Элек Актүбәдә өч сыер көтүе иде, бүген бөтен бистәгә өч сыер калды. Шуның берсе – бездә. Әни һаман сыерга урак белән үзе печән алып кайта. Сөтен, эремчеген, каймагын бөтен балаларына өләшә: Ижевскига, Казанга җибәрә. Әни укырга бик ярата – китапханәгә йөри. Өстәлендә Туфан Миңнуллин томнары тора әнә. Төнлә укый да, күңеленә бик кереп калган урыннарны иртән миңа сөйли. Тормыштан артта калганы юк – кесә телефоны белән дә сөйләшә.

Ауфә апа:

– Балаларың кеше булганны күрү зур бәхет икән ул... Раил дә шуның өчен тырышты. Бүген кызларымның мине зурлавы, туганнарның шулай якын итүе гомеремнең соңгы елларында шулкадәр кадерле. «Зур нәнәй!» – дип килеп керәләр, яңалыкларын сөйлиләр, шатлыклары белән бүлешәләр. Эльзаның оныклары аннан: «Син дә, картайгач, зур нәнәй кебек әйбәт булырсыңмы?» – дип сорыйлар икән... Мин дә Раил әйткән сүзләрне еш кабатлыйм аларга: «Бер-берегезне ташламагыз!» – дим. Иң зур теләгем шул – гел бергә булсыннар!



«Татнефть»тә Чанышевлар кебек хезмәт династияләре байтак. Язмышларын бу төбәкнең төп байлыгы – кара алтын белән бәйләүчеләр, үз артларыннан балаларын, туганнарын ияртүчеләр, нефть сәнәгатенең (димәк, туган төбәкләренең дә) патриотлары алар.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

КЫЧКЫРА – ДИМӘК, ЫШАНА?

– Хәлләрең ничек, кызым (улым)?
– Нормально!..
– Берәр күңелсез хәл бармы әллә?
– Бәйләнмә!
Бу җаваптан соң шапылдап бүлмә ишеге ябыла. Ишекнең теге ягында – хисләрен тулысынча контрольдә тота алмаган яшүсмер, ә бу ягында...
Бу ягында, гадәттә, тормыш ике төрле сценарий буенча дәвам итә. Беренчесендә – буй җитеп килгән баласын олылар белән сөйләшә белмәүдә, рәхимсезлектә гаепләүче әни ачу дулкынында кайный. Икенчесендә – «Бәйләнмә!» сүзеннән «минем үзем генә буласым килә, әлегә миңа кагылмагыз», дигән мәгънә күреп, баласының тынычланганын сабыр гына көтеп йөрүче әни ситуация белән идарә итәргә тырыша...





Раилә ХӘЯЛИЕВА

Әнигә кайчак баланың көйсезләнүенә тимер калкан булырга туры килә.

Негатив хисләр табигатьтән килә

Балаларның ярсуы, елавы, тавыш күтәрүе теләсә кайсы әти-әнине чыгырдан чыгара, әлбәттә. Сәбәбен аңларга тырышканчы, «Елама, алайса...» дип, кечкенә баланы шантажлап елаудан туктату күпкә җиңелрәк сыман. Ә зуррак үскәннәре белән гаепләү хисе аша идарә итү уңайлы. Хәтта мәктәпләрдә укытучылар тарафыннан да бу ысул шактый яратып кулланыла дип ишеткән бар...

Битләре алмадай алсуланып торган, сөеп туймаслык бала – кай арада негатив белән тула, әти-әни, җәмгыять өчен тискәре образ рәвеше ала соң? Тагын да мөһимрәк сорау: бик күп мөмкинлекләр булган заманда, балага шуның кадәр канәгатьсезлек хисе каян килә икән?

– Баладагы негатив күренешнең беренче сәбәбе – физик яктан ару, – дип аңлата балалар һәм әти-әниләр белән эшләүче психолог Галия Гыймадиева. – Кечкенә балаларга гына игътибар итегез: ул арыган, аның ашыйсы, йоклыйсы килә. Шуңа елый, көйсезләнә. Мәктәп укучысының да көне буе дәресләрдә утырып, контроль эшне тапшырганнан соң өйгә кәефсезләнеп кайтуы – гадәти хәл. Авыр эш көненнән соң (әле берәрсе белән эләгешеп алырга да туры килсә!) үзебезнең дә кичен берәү белән дә иркенләп сөйләшеп торасы килми бит. Андый кичләр шактый кәефсез уза... Димәк, мондый халәт өлкәннәргә дә кагыла дигән сүз. Ә балаларга үзләренең реакцияләре, аралашулары белән идарә итү тагын да катлаулырак. Шуңа күрә баланы көйсезлектә гаепләгәнче, аның физик яктан хәлсезләнүен аңларга, күрергә тырышыгыз әле.

Бала күңелендәге авыр уйларның, тискәре табигатенең икенче мөһим сәбәбе – аның үсеш дәвере. Холкы бозыла торган вакыт, ягъни кризис чоры.

Мисал өчен, 3 яше тулгач, шәхес буларак җитлегү, үзен мөстәкыйль кеше дип таныту чоры башлана. Безнең күзгә көйсез булып күренгән бала каршылыклар аша үзен өйрәнергә тырышып ята икән бит! Әти-әниләр баланы мөмкин кадәр кечерәк вакытта үзенең фикерен әнисенекеннән бүлеп карарга өйрәтсә, киләчәктә балага кризислар аша узу җиңелрәк булачак. «Бу – синең фикер, ә мин менә болай уйлыйм». Шул рәвешле бала тормышта компромисс табып буласына төшенеп үсә. Ә менә чыннан да иң катлаулысы – яшүсмерлек чоры кризислары. Баш миендә нейроннар үзгәрү сәбәпле, бала үзен бөтенләй башка төрле, без иялләшмәгәнчә тота башлый. Инде гормоннар да уйный башлагач, хәл тагын да катлаулана. Балага үзен, ни теләгәнен аңлау ничек авыр икәнен күз алдыгызга китерсәгез иде бу чорда! Әле тагын син мондый, тегенди, дип, әти-әни дә өстәп торса...

Өченче сәбәп – ул да булса әти-әниләр. Әйе! Килешәсезме, юкмы, әмма һәр бала әни кешенең дөньяны кабул итү калыбын үзенә өлге итеп ала. Әти-әнинең дөньяга карашы, фикере, үзен гаиләдә, җәмгыятьтә тотышы нык тәэсир итә аңа. Әнидән дөнья начар, кешеләр куркыныч дигән юллама (посыл) алганда, бала өчен тирәлек шактый ышанычсызга әйләнә. Яшәү – матур, килеп туган проблемаларны бергәләп хәл итеп була дигән фикерне сеңдереп үскән балага, әлбәттә, күпкә җиңелрәк!

Әниләр белеп торсын иде, психологиядә шундый аксиома бар: «Булдыра алганда балалар үзләрен һәрвакыт әйбәт тота». Бала үзен тискәре яктан күрсәтә икән, димәк, җитди сәбәпләре бар.

Табигать белән бәхәсләшеп булмый, әлбәттә. Әмма өченче сәбәп белән килешү һәр әни өчен дә авырraktыр. Бу урында тормыштан бер мисал сөйләп китим әле. Дустымның кызы быел беренче класска укырга керде. Җаваплы әни буларак, бу процесска алдан ук әзерләнде ул. Баладан бертуктаусыз яхшы билге, идеаль тәртип таләп итмәү, үзен мәктәптә куелган билгеләрдән чыгып кына бәяләмәү турында алдан ук фикерләр туплады, китаплар укыды. Уку елы башлангач, бер-ике атнадан өй эше бирә башлаганнар. «Кызым белән өй эшен әзерләргә утырган саен, һәр ялгыш сызык, пөхтәсезлек өчен тавыш күтәрә идем. «Ничек инде син?.. Кыз башың белән?» Папкага салынмыйча, сумка төбендә калып таушалган дәфтәр өчен ничек ярсыдым! Тормышыбызга мәктәп темасы килеп керүгә, миндә үзеннән-үзе «отличница синдромы» калкып чыгуын аңладым беркөнне. Мине шулай тәрбияләгәннәр, мин дә менә шулай тәрбиялим... Киштә тулы акыллы китаплар түгел, әни тарафыннан салынган караш барысын да хәл итә икән шул. Менә шуның аркасында уку елын яңа башлаган бала белән конфликтка керә яздык», – дип көрсенеп сөйләде ул. Ә хәзер сез дә үзегезне анализлап карагыз әле. Беркемне дә гаепләмичә, яме!

Негатив белән бүлешергә ничек өйрәтергә?

Баланың өйгә негатив алып кайтуы – нормаль күренеш. Димәк, өйдә ул үзен ышанычлы хис итә. Аны аңлаячакларына, гаепләмәячәкләренә, әни белән бергәләп проблемалардан чыгу юлы табасына да чын күңелдән ышана ул. Кайбер балалар, әнигә сөйләсәм аңа авыр була дип, дәшми кала. Димәк, кайчандыр ул сөйләгән әйберләрдән соң сыгылып төшкәнегезне күргән, үзен гаепле хис иткән дигән сүз. Яшүсмер вакытта кемдер ярсучан булса, кайбер балалар үз эчләренә бикләнә. Дәшмәгән бала – уңайлы бала, әлбәттә, әмма аның үз-үзен тотышында шикләнергә урын бар дигән сүз бу. Күңелендә тулып

Фото: Анна Арахамия

Баланың көйсезләнүен үзебезгә комплимент итеп кабул итик.

йөргән хисләрне кая «түгә», кем белән бүлешә, һәм нишләп әле әни яки әти кеше сердәш була алмый аңа?!

Әниләр хәтерлидер: бакчадан яки дәү әни белән дәү әтидә кунак булып кайтканнан соң, бала өйдә көйсезләнә, елый башлый. Нишләп башкалар янында әйбәт, минем янда гына көйсезләнә, дип аптырый яки үз-үзен гаепли мондый чакта әни кеше. Ә чынлыкта – сезнең бик әйбәт әни икәнлекне күрсәтә торган мисал бу. Кайдандыр кайтып өйдә елавы – ышанычка адым, бала әнисенең аңа ярдәм итә аласына, көндәлеге хисләрен тәртипкә салырга булышасына ышанганда гына үзенең хисләрен ничек бар шулай күрсәтә ала. Бала көйсезлеге безгә комплимент булып чыга.

Без балаларны кечкенә яшьтән санарга, төсләр танырга өйрәтәбез. Шулар белән бергә көндәлеге эмоцияләрне дә танып белергә өйрәнергә тиеш әле без. Көйсезләнгәне өчен оялтырга, башкалар каршында уңайсыз хәлгә куярга тырышырга түгел, аның күңелендә хәзер нинди хисләр кайнаганын сүз белән аңлатып бирергә кирәк кечкенә балага. Яки игътибарын башкага юнәлтергә, ертырга кәгазь бирергә, әнигә сугарга ярамаганын аңлатырга... Бала шулай кечкенәдән үз хисләре белән идарә итәргә өйрәнсен иде, – ди Галия Гыймадиева.

Әйе, еш кына яшүсмерләр әтиәнигә тавыш күтәрә. Мондый вакытта үзләренең нәрсәнедер дөрес эшләмәгәнен дә аңлый алар, әмма туктап кала алмыйлар. Зирәк әниләр – баланың негативын сабыр гына тыңлый, ә аннан соң, дөньялар тынычлангач, утырып сөйләшә, киңәшләрен бирә. Иң мөһиме – эчке чикләр бозылмасын, әнигә кул күтәрү, аны кимсетү сүзләре яңгырамасын. Болары инде кечкенә чактан ук салынган тәрбия баскычлары. Кычкырышып, күпмедер вакыт узгач, бергәләп бу ситуациянең ник алай килеп чыкканы турында сөйләшү, бала каршында гаебеңне таный белү дә бик мөһим.

– Проблеманы хәл иткәндә әтиәниләр еш кына балага каршы юлны сайлый. Баланы сүз тыңламаучы дошман итеп күрә башлый. Ул шундый, ул мондый, дип, аның тискәре сыйфатларына гына игътибарны юнәлтәләр икән, бу күренешне бала белән әни арасында сугыш башланды дип юрарга була.

Бала белән әни кеше баррикаданың төрле ягында булырга тиеш түгел, бу ысул эшләми яки күңелсез вакыйгалар китереп чыгарырга мөмкин, – дип, үз тәҗрибәсе белән бүлешә психолог.

Язмамны әзерләгәндә, Татарстанның ике районында яшүсмер кызларның үз-үзенә кул салганлыгы турында хәбәр укырга туры килде. Куркыныч күренеш. Кызларның берсен коткарып калып булмаган... Алар ул көнне әниләре белән уртак фикергә килә алмаган, күрәсең. Үзләренең барлыгын менә шундый юл белән исбатларга тырышканнар. Яшүсмерләр белән килешеп кенә була. Диктатура – корал түгел.

– Балаларының тәртибеннән зарланган әниләр – үзләрен аңлап бетермәгән әниләр, – ди Галия Гыймадиева. – Үзегезнең нинди әни икәнлегегезне ачыклар өчен кечкенә генә күнегү тәкъдим итәм. Бер кичне балагыз янына утырыгыз да, аңа сездә ошамаган биш сыйфатны әйтүен, аларны ничек уңай якка үзгәртеп булуын сорагыз. Әмма бала әйткәннәрне тыныч кабул итә алырлык булсагыз гына бу күнегүне эшләгез! Барыбызның да бит яратуларын, аңлауларын, хуплауларын тоясы килә. Балалар да – нәкъ шундый. Ишетегез, әниләр!

Әни – кеше күңелендәге иң изге образ. Әниләр барысына да өлгерә, сиздерми генә ярдәм итеп җибәрә, кирәк икән, сине барлык проблемаларың белән кочып алучы кояшка да әверелә. Ярату ул – әле яныңдагы кешеңә тискәре булырга да рөхсәт итү, аны ничек бар шулай кабул итү. Әниләр шулай итә дә. Чөнки баласына караганда, ул күбрәкне аңлый, күбрәкне белә... Әни – балага иң якын кеше ул!

Заман тотрыксыз. Хисләр, үзара мөнәсәбәтләр турында әйтеп торасы юк. Инде буй җиткән көйсез балага да аны ничек бар шулай кабул итә торган әни кирәк. Ә балалар... Балалар мөмкинлек булганда һәрвакыт яхшы булырга тырыша!

ПСИХОЛОГ ФИКЕРЕ



Галия ГЫЙМАДИЕВА,
психолог

– Кайвакыт бала белән дөрес аралашмаган әниләр үзләрен үзгәртергә тырыша башлый. Элек бер-берсенә тавыш күтәреп, ачуланышканнан соң ишек ябып чыгып китәргә яраткан әни кеше баласына сабыр булып калырга, аны аңларга тырыша. Әгәр мондый вакытта балагызның үз-үзен тотышы тагын начарлана икән, гаҗәпләнмәгез һәм артка чигенмәгез! Баланың сезне шулай тикшерүе ул. Хәзер ышансам, авыррак хәлгә калсам мине кабул итәрме диюе. Менә шул сынауны узсагыз гына бала белән мөнәсәбәтләр көйләнер!

Бу темага караган китаплар:
- Людмила Петрановская, «Тайная опора».
- Юлия Гиппенрейтер, «Общаться с ребенком. Как?»
- Карен Прайор, «Не рычите на собаку!»



19 ДЕКАБРЬ
17.00
«КАЗАН ЭКСПО» ХКҮ
И. ШАКИРОВ ИС. КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

XXI
ТАТАРЖЫРЫ.РФ
ТАТАР ҖЫРЫ

260-72-72
ВСЕ БИЛЕТЫ KASSIR.RU
ТАССР 1920-2020

ГЕНЕРАЛЬ ПАРТНЕР

ДАИМИ ПАРТНЕР

ПАРТНЕРЛАР



ОЕШТЫРУЧЫЛАР




6+

PRESSA



ӘЛФИЯ САМАТ БИТ УЛ!



Эльмира
ЗАКИРОВА

Үҗәт, үткер каләмле, принципиаль журналист, диләр аның турында. Кирәк икән, бөтен районны дер селкетә, җитәкчеләр уттан курыккандай курка үзеннән, дигәннәрен дә ишеткән булды. Карап торуга, тыйнак, басынкы гына Әлфия бит инде югыйсә. Без аның белән якташлар, яшьтәшләр, коллегалар. Мәктәп елларында ук аның Актаныш районында чыга торган «Игенче даны» газетасында әледән-әле мәкаләләре күренә. Һәм ахырда таныш исем кабатлана: «Әлфия Саматова, Иске Кормаш мәктәбе укучысы». Ә бераздан инде, университетның журналистика бүлеген тәмамлап, Әлфиябез Минзәлә совхоз-техникумында да укырга өлгерә (менә ни өчен авыл хуҗалыгы темасында йөзә генә ул!) һәм район газетасының алыштыргысыз журналисты булып китә! Алай гынамы! Ул елларда районнарда җитәкчеләрнең иң курка торган кешесе райком секретаре дип сөйләсәләр, Актаныш исә андый кеше район башкарма комитеты рәисе икән. Бер җыелышта ул үзе сөйләгән: «Безнең районда ике генә кешедән куркалар. Берсе – мин, ягъни Баязит Шәймәрданович, икенчесе – Әлфия Саматова!» Һәм бу сүзләр анекдотка әйләнгән!
«Татарстан яшьләре»ндә эшләгән еллары – үзе бер чор! Башка профессияләрнең эчке кухнясын өйрәнүне төп максат итеп куеп, иминият компаниясендә эшләп каравы (бер елда Венгриягә генә дә җиде-сигез мәртәбә барып кайта!), Ан-2 самолетында штурвал артына утырып, Актаныштан Казанга очулары (очучы очышны автопилотка көйләсә ни! Штурвал бит барыбер Әлфия кулында була!), «Татарстан» поезды машинисты янында Казаннан Мәскәүгә барулары... Әлфия Саматны инде бөтен республика укый, аның белән хәтта министрлар исәпләшә! Ә журналистика факультеты студентлары журналист Саматова иҗаты буенча курс эшләре яза, диплом яклый!

Соңгы вакытта ул калын-калын китаплар чыгара – документаль проза жанрында эшли. Кирпеч авырлыгы басмалары инде тугызау хәзер! Китап геройлары – фермерлар, хуҗалык җитәкчеләре, авыл хуҗалыгы белгечләре, аерым шәхесләр... Авыллар тарихы, нәсел тарихы, шәҗәрәләр... Укучыны беркемгә дә охшамаган һәм шул ук вакытта үзендә милли холкыбызның иң калку сыйфатларын туплаган гаҗәеп шәхесләр дөньясына алып керә. Бер тында укыла торган китаплар!

Әлфиянең холкын ача торган гамәлләре дә байтак. Ул – машина йөртә. Ул – умартачылыкка өйрәнә, мәдрәсәдә укый. Ул – ике тапкыр хаҗга барып кайта. Ул – авыруларга, мохтаҗларга ярдәм итә. Ул... әллә ниләр эшли! Үзе белән күптән шулар хакында сөйләшәсем килеп йөри идем. Тик Әлфияне тотам димә икән: әле архивларда, әле Чүпрәленең Үбиендә («Татарның үз Үбие» дигән китабы чыкты бит яңа!), әле Березникида (ярты Березники – безнең авыллар гына, ди! Ә Әлфиянең туган авылы турында китап язасы бар!), әле геройлары белән очрашырга дип Мәскәүгә чыгып киткән, әле Кормашыннан килә алмый ята. Шалтыраткач та: «Мин авылда әле. Менә 45 төп агач утырттым. Иртәгә Казанга киләм, Аллаһ боерса», – дип, тагын да ныграк ымсындырып куя. Шулкадәр агач нигә икән?

Һәм, ниһаять, Әлфиянең «Зөбәрҗәт шәһәр»дәге (Изумрудный город микрорайонын шулай әйтәсе килә) фатирында сөйләшеп утырабыз.

Әлфия Самат исемен әйтүгә, җитәкчеләр утлы табага баскандай була, дигәннәрен ишеткәнем бар. Синең хакта легендалар йөри. Ничек шулай кыю итеп яза башладың?

– Университетта читтән торып укуга күчкәч, башта Яхшый, Куҗәкә, Теләкәй мәктәпләрендә укыттым, пионервожатый булып эшләдем. Ә үземнең редакциядә эшлисем килә! Апаска, Сарманга чакырулары турында әнигә әйткән идем, коты очты! Ничек итсә итеп, Низамовка чыккан бу. Хәләф абый авылдашы бит! Ә ул райкомның идеология секретаре иде. Шулай итеп, район газетасының хатлар бүлеге корреспонденты булдым. Урнашуыма бер ел үтмәде, мин инде шактый «тешле» мәкаләләр яза башладым. Чөнки эти: «Кызым, син гел мактап кына язма. Андый язучылар күп булыр ул. Дөреслекне язып, гаделлекне күрсәтергә тырыш», – дип, күңелемә үтәрлек итеп әйтә иде. Шулай бер мәлне бер авылдан хат килеп төште. Колхозы алдынгы, рәисе шәп кеше, җитмәсә. «Кайбер савымчылар ялгаштa ята, икешәр көн сыерлар савылмый, бер тәртип юк монда...» – дип язганнар. Шул хат буенча чыгып киттем. Барып тикшердем – бар да дөрес инде, кайттым да яздым. Укып чыккач, редактор кызарынды-бүртенде: «Юк, бирмибез! – ди. – Моны чыгарсак, үтерәләр! Икебезне дә эштән куалар!» – дип, мине чигендермәкче була.

Ә син?

– Ә мин редакторга әйтеп тормадым, мәкаләне алдым да, райком секретаре Низамовка кереп киттем. Укып чыкты. Ул да агарынып китте: «Курыкмыйсыңмы, Әлфия?» – ди. «Юк, монда бөтенесе дә дөрес!» – дип чатнап торам. «Первый» нәрсә әйтер икән?» – ди Низамов. Тәвәккәл дә булганмын инде! «Үзе барсын да карасын ышанмаса!» – дип торам бит әле. Ә исбатлардай бер дәлилем дә юк. Диктофоннар бармыни ул чакта?!

Шуннан?..

– Райкомнан чыктым да, Низамов бирергә кушты, дим. Редакторыбыз өчен бу хәбәр гел көтелмәгән яңалык булды. «Ничек инде?! Чынлап әйттеме?» – дип һушын җыялмый торды берара. Бирдек мәкаләне. Шуннан... «Ни булыр?» дип көтә башладык. Ике көннән парторгтан ике куш бит хат килеп төшмәсенме?! Минем бер сүзем дә дөрес түгел икән бит! Их, диктофон юклыклар!.. Икенче көнне портфель кадәр магнитола күтәреп, тагын шул авылга чыгып киттем. Савымчы апаларның берсенә бардым. Иртәнге сәгать иде. Апам тагын салмыш... «Ирем үлгәч кереп киттем дә, апай, ташлый алмыйм», – ди. Башка кайберәүләр турында да чынбарлыкны сөйләп бирде. Ә мин яздырып бардым. Беренче тапкыр чыккан тәнкыйть язмам иде бу. Районда Әлфия Саматова дигән исем дә шул чакта барлыкка килгәндер, мөгаен. Авылларга чыгып китәсемне еш кына берәүгә дә әйтеп тормый идем. Минем килү хәбәрем алдан барып җитсә, «смирно» басып көтеп торалар үземне. Колхоз рәисе, партоешма секретаре, авыл советы рәисе... Һәм мине теләсә кая җибәрмәскә тырышалар иде! Шуңа күрә таң тишегеннән торам да иртәнге савымга фермаларга чыгып китәм. Анда йөреп чыккач, редакциягә кайтып язам да, эшкә килүенә минем чираттагы «бомба» редактор өстәлендә яткан була. Ә ул: «Син җендерсең! Кай арадаяздың моны? Кайчан җитештең?» – дип аптырый. «Бүген бардым, бүген яздым, менә тапшырдым!» – дим. (*Көлешәбез.*)

Бөтенесен куркытып бетергәнсең икән!

– (*Көлә.*) Бер зоотехник апа бар иде. «Мин дөньяда ике генә әйбердән куркам: берсе – бакадан, икенчесе – синнән!» – дия иде! Булды инде хәлләр!..

Хәтерлим әле... Син менә шундый гаугалы очракларны чишәргә батырчылык итә торган журналист булып «Татарстан яшьләре»нә эшкә килдең...

– Хәлим абый Гайнуллин редактор чак. Анда Исмәгыйль Шәрәфиев, Рина Зарипова, Фәүзия Бәйрәмова, Хәмзә Бәдретдинов, Флүрә Низамова, утлы язмалары белән танылган Миңназыйм Сәфәровлар... Актанышка килеп, минем белән аралашып киткән Фәүзия апа да, Хәмзә дә, каләме бар, дип кайтып сөйләгәннәр. Кайберәүләр исә, район газетасыныкылар барысы да бертөрле яза, ашыкмагыз әле алырга, ди икән. Саллы гына мәкалә яздыртып карадылар, ошаттылар. Эшләп киттем. Ләкин бер ел елaдым! Мин бит – шәһәрне яратмаган өчен, университетка укырга кергәч тә, читтән торып укуга күчеп, авылга кайтып киткән кеше. Күрде инде башларым! Киемнәремне дә урлаттым, тараканлы тулай торакларда да изаландым... Әллә ничә мәртәбә чемоданнарымны төйнәдем кайтып китәргә. Ә Актаныштан һаман: «Кайт, сине анда беркем белмәячәк, син монда «королева» бит!» – дип чакыралар... Үҗәтлек көчле! «Юк инде, артка юл юк!» – дидем дә, түздем. Берничә елдан

«Татарстан яшьләре»ндә мин Әлфия Саматка әйләндем! Исмәгыйль Шәрәфиев, үзе дә сизмәстән, мәкаләләремне кире борылмаслык итеп язарга өйрәтте. «Мин яратам сезне...» китабымда да шул елларда яратып язган геройларым. Һәм, әлбәттә, «Сөембикә»нең элекке редакторы Фирая Бәдретдиновага мин бик рәхмәтле. Китапларымның редакторы буларак, ул миңа ярдәм итү генә түгел, язу осталыгын камилләштерүдә (ә камиллекнең чиге юк!) искиткеч тирән серләрен чиште.

Диктофон дигәннән... Бөтен хыял диктофонлы булу иде бит минем. Казанга килеп эшли, тәнкыйть мәкаләләре яза башлагач, исбатлар өчен «доказательная база» кирәк иде. Диктофон өчен генә булса да берәр чит илгә барсаң икән дип хыялландым. ВЛКСМ өлкә комитетында дус кызым эшли. Бервакыт «Спутник» юлламасы белән Сирия–Иорданиягә барырга ниятләдек. Иртәгә китәбез дигән көнне дустым шалтырата, сине исемлектән төшереп калдырганнар, ди. Чемоданнар тутырылган, чираттагы ял алынган... Группа җитәкчесе авыл яшьләре бүлеге мөдире иде... Нигә исемлектән төшеп калуымны шундук аңладым: тәнкыйтьләп язган идем бит аны. Шуңа мине сызып ташлаган! И еладым инде! Икенче көнне комсомол өлкә комитетының беренче секретаре Дамир Шәяхмәтовка бөтенесен сөйләп бирдем. Шаккатты! Һәм ул миңа Кубага барырга путевка табып бирде.

Тәки Кубадан алып кайттың инде диктофонны!

– Юк шул... Диктофоннар бар, ә минем акча җитми. Кесә чыгымнарына 30 доллар белән генә чыгаралар иде. Аның каравы, анда татар кешеләрен – Казаннан киткән төзүчеләрне эзләп таптым. Кайткач, алар турында материал да яздым. Ул вакытта Казанда Кубадан килгән студентлар укый иде. Адреслары буенча ике Куба кызының әти-әниләренә бардым, сәламнәр тапшырдым. Кайткач, яздым, әлбәттә. Барган җирләремдә һәрвакыт эзләнеп йөрим шулай. Журналистика дип, тәмам хыялланган кеше инде мин.

Берчак иртән эшкә килеп, лифт көтеп торам. Балкып, син дә килеп бастың. «Лондоннан кайттым! Ирек Мөхәммәдев белән очраштым!» – дисең...

– Ә-ә, ул командировкам турында әйтәсеңмени?.. Башыннан ук сөйлим әле. 1996 ел иде. Ул чакта беренче вице-премьер Равил Моратов җитәкчелегендәге 20 кешелек хөкүмәт делегациясе составында Англиягә барган идем. «Вечерняя Казань» газетасыннан Юрий Алаев бар иде тагын. Англия, Швейцария, Франция, Америкага эшлекле сәфәр көтә иде безне. Ләкин журналистларга виза әзерләп өлгертә алмаганнар: Алаев белән Лондонда калдык, делегация АКШка очты. Бер атнадан алар кабат Лондонга кайтырга тиешләр. Ә безне Казанга озаттылар, чөнки Лондонда бер атна яшәвебез кайтып кире килүебездән кыйммәткәрәк чыга икән. Ирек Мөхәммәдев белән шул баруда очраштым мин. Телефон номерын абыйсы Наилдән алып киткән идем. Шалтыратып, үзебезчә: «Исәнмесез, Ирек», – дим. Туган телендә, татарча эндәшсеннәр әле! «Исәнмесез, исәнмесез», дип шатланып җавап бирергә ашыкты. Ә репетицияләрдән соң без урнашкан отельгә ул үзе килде. Дөнья балеты йолдызы, Лондондагы «Ковент-Гарден» королева балеты биючесе белән рәхәтләнеп сөйләштек. Кайту белән мәкаләне яздым да «Татарстан яшьләре»нең Ирек Мөхәммәдев чыккан санын бер атнадан Лондонга алып киттем...

Язмаларыңны укыйм да, геройларыңны шулкадәр яратып язасың син, Әлфия! «Мин яратам сезне...» дигән китабыңны рәхәтләнеп укыдым.

– «Язачак геройларыгызга гашыйк булмасагыз, әйбәт язма өмет итмәгез. Яратып язылган материал гына укылышлы була», – дигән иде Хәлим абый Гайнуллин. Яратмасаң, хәтта тискәре образны да язып булмый әле. Бу урында безнең халык арасындагы таныш бер гыйбарә искә төшә: «Ишектән кертмәсәләр, тәрәзәдән керәм бит».

Тәрәзәдән кертмәсәләр – форточкаданмы? (*Көлеп җибәрәбез.*)

– Әйе, андый очраклар күп булды инде! 1988 елның ноябрь ахырында редакциягә Мамадыштан хат килеп төште. Озак эшләгән бер колхоз рәисен эшеннән җибәреп, икенче бер яшь белгечне куйганнар. Районда зур ЧП китереп чыгарды бу, давыл купкан кебек булды. Райкомның беренче секретаре Фатыйх Сибагатуллин иде ул чакта. Яшь рәисне яклар өчен мине чакырып китерделәр. Башта шул авылга бардым, тикшердем, яздым. Аннан соң гына Мамадышка Фатыйх Сәүбәнович янына киттем. Давыл-өермә нәкъ шушында иде ул! Дулады гына беренче секретарь! Нишләп минем рөхсәттән башка йөрисең безнең районда, ди! Пыр туздырды инде! Эндәшми утырдым да, кайткач, үзем теләгәнчә итеп яздым барыбер! Материал чыкты. Бөтенесе аһ-ваһ килә! Сибагатуллин газетаны судка бирәчәк дип чабышалар. Әмма без көткән давыл чыкмый калды! Сибагатуллин килмәде, судка да бирмәде, вакланып, абруен төшермәде, акыллы кеше булып чыкты! Озак та үтмәде, Фатыйх Сибагатуллинны Казанга авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры итеп китерделәр. Фермерлар җыелышында кабат күрештек үзе белән. Тәнәфестә мине күреп алгач, уенын-чынын кушып: «Әлфия, син миннән курыкма. Синең өчен ишекләрем һәрвакыт ачык булыр, ишекне тибеп керерсең!» – диде. Эчендә ниләр кайнагандыр, белмим, әмма ишекләрен тибеп кермәсәм дә, ул сүзендә торды, туры телефонына кадәр бирде, теләсә кайчан, шалтыратып та тормыйча, килә идем. Бүгенгәчә хөрмәтем зур аңа. Чын ир кеше икән дип уйладым!

«Мамадыш хакимияте-2» дигән язмаң да бик шау-шулы булып истә калган...

– Әйе, Мамадышка тагын бардым әле. Нәкъ биш елдан. Хакимият башлыгы турында шактый гына гаепләүләр язылган хат килгән иде. Халык белән мөгамәләсе дә начар, законсыз рәвештә кешеләрне эштән җибәрә икән... Күп инде кыек яклары. Тикшереп, бик усал итеп язып чыктым. Шуннан соң бер атна эчендә район башлыгын эшеннән азат итү турында Президент фәрманы чыкты. Минтимер Шәймиев үзе килде Мамадышка. Мин дә катнаштым анда. Гадәти булмаган эштән алу чарасы иде бу. Аннары Минтимер Шәриповичтан интервью алдым. Җитәкчеләргә чама хисен югалтырга ярамаганын кат-кат искәртте ул шунда.



« Тулысынча укыгыз

Син гел юлда, Әлфия. Һәм ул юлның күпчелеге Казан–Актаныш арасында бугай. Авылга кайту дигән төшенчәгә ниләр сыя?

– Авыл ул – туган җир, беркатлы ихлас авылдашларым, без үскән өй, бакчабыз, умарталар, әтинең кабере... Аена икешәр тапкыр кайтып йөрим 350 чакрымлы Кормашка. Менә соңгы кайтуымда да бакча артына 45 төп агач утыртып килдем. Юкәләр! Чыршы, нарат, өрәңге дә бар. Язын шул тирәгә зәп-зәңгәр фацелия чәчкән идем, бал кортлары өчен менә дигән баллы чәчәклек булды ул. Әле тагын бабкайдан ук калып килә торган 50 сутыйлап җиребез бар. Күршедәге ихата да – безнең туганнарныкы, алар исән түгел инде – карамасаң, ташландыкка әйләнә дип, анысында да чүп үстермәскә тырышабыз. Без өч кыз – мин, Дилара, Роза – бәләкәйдән гел эшләп үстек. Әниебез Вәфия Чирмешәндә авыл хуҗалыгы мәктәбендә агрономлыкка укып кайткан, гомере буе колхозның яшелчә бакчасы мөдире булды. Үзе үстерде, үзе сатып җибәрде. Бөтен тирә-як районнарны кәбестә белән тәэмин итте. Эш безгә дә эләкте, билгеле. Химикатлар белән түгел, биологик юл белән кәбестәне корткычлардан саклап кала идек. Чүп утау, чөгендер эшкәртү, бәрәңге утырту-алулар... Эшсез тормасыннар диптер инде: әти белән әни тик торганнан утынны бер яктан икенче якка булса да күчерттерәләр иде. (Көлә.) Мин хәзер дә авылдагы эшне колхоз эше дип атыйм. Кайтып керү белән үк кырмыска урынына бетмәс-төкәнмәс эшкә чумасың. Әле ярый Роза сеңлем Чаллыда гына, аңа төшә эшнең күбесе. Ә әни – һаман командир, агроном.

Тормышым детектив роман кебек, дигән идең... Бәлки, ул романны яза башларга да вакыт җиткәндер? Язучы буларак та кабул иттеләр үзеңне.

– Халык кызык инде ул. «Син язучымы? Атказанган исемең бармы? Нишләп юк?» – дип сорашалар. «Юк, мин язучы түгел, журналист. Мине өч тапкыр «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исемгә тәкъдим итеп тә, документларымның Минтимер Шәриповичка барып җитәргә бер баскыч кала, «не заслуживает», дип кире борылганлыгын аңлатып торыйммы инде?
И-и, сөйләсәң, маҗаралар күп ул миндә. Чыннан да, детектив әсәр язарлык... (*Уйланып кала.*) Минем өйгә кадәр янап, куркытып килүчеләрне, кара аны, башыңа җитәбез, дип, төнлә яки иртәнге 5-6 ларда шалтыратулар, эндәшмичә торулар, шантаж ясауларны искә төшерсәңме?!.

Һәр материалым артында папка-папка исбатларлык документларым туплана иде. Дөнья бит, ни булмас дип җыеп барырга өйрәнелде. Ләкин бер язмам да судка ук барып җитмәде. Гаризаларын гел кире алалар иде.
Син роман дисең, минем әле абыстайлар турында, аннары үземнең авыл турында да язасым бар... Абыстайлар турында язарга сеңлем Дилараның кызы Регина булышыр. Ул да минем һөнәрне сайлады бит. Планнар зурдан әле...

Сезнең нәселдә бар, ахры, язуга сәләт...

– Журналист Рина Зарипова, шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова – безнең нәсел балалары, кайсыдыр буындагы бабайларыбыз уртак. Бабкай, исемнәрен генә теркәп, сигез буынны язып калдырган. Уфа архивыннан шуларны эзләп табып, шәҗәрәмне ясадым.

...Икенче көнне Әлфия Яшел Үзән районы хакимияте башлыгы Михаил Павлович Афанасьев белән очрашырга тиеш иде. «Афанасьевка таянырга була, ул иҗат кешесенә карата аеруча игътибарлы, булдыра торган җитәкче», – ди ул. Әңгәмәбез юлда дәвам итте. Күз тимәсен, Әлфия оста йөртә машинаны. 22 ел руль артында икән. Хәер, гомере буе машина йөрткән Хәнәфи абый кызы булсын да! Күбрәк Әлфия сөйли. Турысын әйтергә яратуы, шуның аркасында җәнҗаллы ситуацияләргә юлыгуы, гаделлек өчен көрәшүе, бәхетсезлеккә дучар булганнарга ярдәм итүләре турында...

Син, Әлфия, бүген дә кулдан килгәнчә кешеләргә булышырга тырышасың. Узган ел авариягә очраган яшь кыз бала – Актаныш районының Ахун авылы кызы Гөлгенә Сафинага ярдәм оештыруың турында кемнәр генә белми!

– Игелекле кешеләр барыбер күп икән! Хәтта чит илләрдән дә булыштылар. Көн саен, намаз саен, беркемгә дә Гөлгенә хәленә калырга язмасын иде, дип дога кылам. Ә болай көндәлек мәшәкатьләр, сынаулар-авырлыклар моның белән чагыштырганда – тузан бөртегенең миллионнан бер өлеше! Атнага бер тапкыр җомга сәдакабызны – 10 сумны, 100 сумны – Гөлгенәгә күчереп барсак, егылып үлмибез бит, әлхәмдүлилләһ! Телефонымда 19 группа бар. Һәркайсында йөзләгән контакт. Күбесе кабатланмый. Туганнар, дуслар, классташлар, мөслимәләр, абыстайлар, авылдашлар, артистлар, китапларым буенча аерым группалар, район башлыклары, министрлар. Һәркайсы акчалата ярдәм күрсәтте Гөлгенәгә. Соңгы бер ай эчендә 3 миллион сумнан артыграк җыйналган, тагын миллион ярымлап кирәк әле. Менә шулар өчен тырышып йөрибез. Аны төп оештыручы мин түгел инде, мин үземнең элемтәләрем белән «ияреп йөрүче генә».

«Сез шул Әлфия Саматмыни инде?» – диләр. Яшьрәкләр дә әниләре сөйләве буенча белә булып чыкты. Арада язмаларымны укыганнары да бар.

Ул болай да килешле яулыгын төзәтеп, рәтләп куя. Шактый еллар Әлфияне кыска чәчтән күреп күнеккәнгә, яулыктан йөри башлавы белән дә кызыксынам.

– Бәләкәй чакта әбкәй белән бабкай урталарына яткырырлар иде дә, конфет-прәннек белән кызыктырып, догалар ятлатырлар иде. Кечкенәдән өйрәнгәннәр хәтердә сакланган. Биш вакыт намазга басканга да байтак еллар.. Беренче тапкыр хаҗга барып кайткач инде яулыкны салалмадым. Салсам, үземне уңайсыз хис итүемне аңладым. Менә шуннан бирле мин яулыктан. Халык башта сәерсенеп кабул иткән иде, хәзер инде ияләштеләр.

...Яшел Үзәнгә керүгә мәчет янында туктыйбыз. Өйлә намазына чакырып азан тавышы яңгырый. Әлфия якты уйлары, игелек кылырга әзерләнгән изге ниятләре, башкаларга ярдәм кулы сузганнарга мең рәхмәтләре белән Аллаһ йортына ашыга. Изге догаларың кабул булсын, Әлфия!

PRESSA

БАЛТАЧ БАКЫРЧЫЛАРЫ



Кияү йортына яшь киленнең бирнәсе белән килгән ул. Беренче көненнән үк урыны җылыда – мич алдында булган. Ислам динендәге татарларның тормышын аннан башка күз алдына да китерә алмыйсың. Хәер, ник татарларның гына, корсагы юан, муены нечкә, борыны озын бу савытны башка халыклар да кулланган. Аны ясаучы осталар исә һәр авылда булган. Алар бүген дә бар, ләкин бик санаулы. Алтын яфраклар коелган юлдан Балтачка шул сирәк осталарны эзләп барышыбыз.



Лилия ГӘРӘЕВА









– Бәлки, мин бу эш белән беркайчан кызыксынмас та идем, бер кеше җиздән ясалган комган белән ләгән табып бирүемне үтенде, – түгәрәк чүкеч белән комганның капкачын чүкегән җиреннән туктап, оста көлемсерәп куя. – Теләсә нинди акча түләр идем, ди... Эзләмәгән җир калмады...

– Табып бирә алдыгызмы соң? – түземсезләнеп, бүлдергәнемне сизми дә калам.

– Кайдан табасың бүген андыйны? Антиквариат кибетләрендә булса гына. Ләкин аңа өр-яңасы кирәк иде шул. Үземә ясарга калды...

Әллә шаяртта, әллә чынын әйтә?.. Моңарчы бер комган да ясап карамаган кеше шулай беренче тотынудан башкарып чыкты микәнни?..

– Остазым әйбәт иде. Габделфәрт абый... мәрхүм инде. Мин комган эзләп йөргәндә, шуларны ясаучы кеше күрше авылда – Балтачта гына яшәп яткан. Җәлил хәзрәт Фазлыев улымның өй туена комган алып килмәсә, Габделфәрт абый турында белмәс тә идем. Икенче көнне үк янына бардым. «Җиз комган кирәк иде, эшләп буламы?» – дим. «Ник булмасын, материалын гына тап!» – дигәч, Казаннан табагы белән җиз алып кайттым. Аның өчен өч төрле калынлыктагы калай кирәк икән. «Мин өйрәнә аламмы соң?» – дим. «Өйрәтер идем дә, минем бит барлык эш кораллары да сул кулга көйләнгән», – ди бабай. Аны шулай якын күреп, бабай дип атый идем. 82 яшь иде аңа. Иң гаҗәпләндергәне: ул шул яшендә дә күзлексез эшләде! Мин үзем дә сулагай. Шуны әйткәч, «әйдә, алайса утыр!» дип, шул көнне үк «дәрес»кә керештек. Эштән кайтышлый гына сугылган чагым иде, өстә ак чалбар белән ак күлмәк... Бер көн сызымын сыздырды, бер көн калаен кистерде... Кайчылары – үзе ясаган авыр кайчылар... Аның барысы да үзе ясаган борынгы кораллар иде. Кулларга сөялләр чыгып бетте... «Кулың туры икән, булдырасың», – дигәч, тагын да үсенебрәк киттем. Өченче көнне калайдан җөен бөктек, дүртенче көнне ябыштырдык...

Комганны төрле халык төрлечә кулланган. Татарларда ул исә гомер-гомергә чисталык символы саналган.

Балтач районының Кече Лыза авылында гомер итүче Илдар Солтанов белеменә күрә урманчы, Лубян урман-техника көллиятен тәмамлаган, озак еллар урманчылыкта эшләгән. «Сурнар урманчылыгында тракторчыдан башлаган идем, лесничийга кадәр үстем», – ди ул. Шушы һөнәре аны – Арча районы Яңа Кырлай авылында туып-үскән егетне Балтачка алып килгән дә инде. Хатыны Гөлйөзем апа исә Мари Иленнән үк. Урман эше аңа да ят түгел диюем, урманга терәлеп торган авылда буй җиткезгән кыз.

Кече Лыза үзе дә өстенә урман аварга торган матур, төз авыл. Юлларны төзекләндерү, мәктәп салу кебек игелекле эшләрнең башында күбесенчә Илдар Мөхәммәтхан улы йөргән.

– Мин монда гомерлек депутат, – дип шаярта ул. – урманчылыктан киткәч, Янгын куркынычсызлыгы хезмәтендә эшләдем. Комганнар ясау белән кызыксынуым әнә шул вакытлардан. Кечкенәдән бер гадәтем бар: нәрсәдер күрсәм, моны ясый аламмы, дигән уй туа. Мәктәптә укыганда аэрочаналар ясау белән мавыктым. Тимер эшенә маһирлык канымда, күрәсең. Ләкин комган ясый белгәнгә карап, үз һөнәремне таптым дип әйтә алмыйм, түземлек сорый торган эш бу. Мин исә эшнең тиз барганын яратам. Аннары, комганга ихтыяҗ да юк бит, кибеттә пластиктан ясалганы шалкан бәясе торганда мең сумга, ике меңгә кем комган сатып алсын?! Мин аларны сатар өчен дә түгел, күбрәк бүләк итәр өчен ясыйм. Хәзер кешене кибеттән алган әйбер белән шаккаттыра алмыйсың, ә менә җиздән ясалган комган бүләк итсәң, борынгы күмер самавары күтәреп барсаң! Ул әле күпләрнең хыялы да булып чыга.

– Комган ясау катлаулы эшме? Иң авыры кайсы этабы? – дим, кызыксынып.

– Иң авыры – комганны ясап бетергәннән соң, суы ага торган булса. Менә шунда ачулар чыга инде. Эшләгәндә су салып тикшереп карый алмыйсың аны. Һәр эшнең четерекле яклары бар инде. Комган нык булырга, суны агызмаска тиеш. Минем өчен иң авыр җире – комганның төбен ябыштыру. Өч детальне – корпусын, төбен һәм аскы балдагын бергә ябыштырырга кирәк бит, – Илдар абый шүрлектә тезелешеп торган комганнарның берсен алып, төбен әйләндереп күрсәтә. – Монысы бакыр комган, аның төбенә балдак куярга кирәкми, ә менә цинклы ак калайга тәпи ясамый булмый, чөнки җиргә тиеп торса, күгәрергә мөмкин.

– Ни өчен татар комганын борынгылар шушы рәвешле ясады икән? – дип сорашам остадан. Гасырлар үтсә дә, формасы үзгәрешсез калганга ишарәләп.

– Моны бик башлы кеше уйлап чыгарган, – оста кулына штангенциркуль ала. – Күрәсеңме, комган 45 градуска янтайса да, бер тамчы суы түгелми. Чиләкне болай янтайтсаң, ярты суы агып бетәр иде инде. Монда һәр деталь уйланылган: муенының нечкә, борынының озын булуы суны сак тоту өчен. Алдагы элмәгеннән өзәңгегә элеп куярга җайлы булган, юлда барганда эчендәге суы түгелмәгән. Тоткасы да үз урынында. Капкачына таянып, өлкән кешегә җирдән күтәрелүе уңай.

Оста, сүздән бүленеп, эшен дәвам итә. Без килгәнче кисеп куйган комганны җөйләр өчен читләрен бөгә ул. Шактый четерекле һәм кулның егәрен ала торган хезмәткә охшаган. Тимергә салган калаена чүкеч белән суккан саен остаха-

Фото: Анна Арахамия

Элек комганнар күбрәк бакыр һәм җиздән эшләнеп, аларны ясаучы осталарны бакырчылар дип йөрткәннәр.

нәдәге өсталләргә кадәр тыпырдап куя. Әле ул җөйне соңыннан кургаш белән ябыштырасы бар.

– Казанның Чехов базарында берәү бик матур комганнар сатып тора иде. Күгәрми торган калайдан – «нержавейка»дан ясалганнар, ялтыраплар тора, аңа карап кырынып була. Бабай андый материалдан ясамый иде. «Ябыштыра белмим», – ди иде. Аны ябыштыру өчен махсус осталык кирәк. Белештем: дядя Саша дигән кеше ясый икән бу комганнарны. Эзләп таптым, сораштым, өйрәндем. Казаннан кайткач «диплом эше»мә утырдым. – Илдар оста арадагы иң ялтыравыклы ак комганга күрсәтә. – Менә шушысы ул. Анысын беркемгә дә бирмим, истәлеккә саклыйм. Бер атна ясадым. Ясап бетергәч, күтәреп, бабай янына киттем. «Нержавейкадан бит бу! – дип тел шартлатты остазым. – Ничек ябыштырдың?» Ә болай, эшләр өчен, җиз белән бакыр кулай, алар йомшак металл. Бер ялтыратып та җибәрсәңме! Ничә комган ясадыммы? Утызлап булгандыр. Кайчак ремонтларга алып киләләр. Күргәзмәләргә баргалыйбыз. Халык кызыксына үзе, күпләр өчен бу комганнар балачак төсе. Элек комгансыз бер көн яшәп булмаган бит ул. Кул юсаң да, бит юсаң да, гел комган белән табак кирәк булган.

Илдар останың остаханәсе кечкенә генә музейны хәтерләтә. Комганнар артына төрледән-төрле самаварлар да тезелгән. Зурлары, кечкенәләре, аклары, сарылары...

– Боларын да сез ясыйсызмы? – дим, тәмам гаҗәпләнеп.

– Төзәтәм. Самавыр ясарга ук осталык җитеп бетми әлегә. Менә бер электр самавырын күмерненә көйләдем әле. – Ишек катындагы мичкә кадәр зур самавырга ишарәли оста. Ай-һай, биш чиләк су сыя да сыя моңа. – «Общепит»ныкы булгандыр, борыны урынына кран куеп, су кисмәге итеп кулланганнар. Әнә борынын ясадым инде, эчен ясап бетерәсе, аннары ялтыратып чистартасы калды. Бу эшкә керешүемә чегәннәр гаепле, – дип шаярта оста. – Туксанынчы елларда металл җыю белән шөгыльләнә башладым. Ул вакытта чегәннәр нинди генә самавырлар алып килеп тапшырмый иде. «Бераздан бу самавырларның берсе дә калмас, сакла син аларны, рәтли белсәң, кабат эшкә ярардайлары бар», – дигән иде олы яшьтәге бер чегән. Киңәше дөрес булып чыкты. Саклап тотсаң, самавыр берничә буынга җитәрлек.

– Аларның кайсылары яхшырак соң? Җизләреме, ак самавырлармы? Кемдер, мөһерле самавыр әйбәт була, ди.

– Иң яхшы самавырлар – Баташев фабрикасында ясалганнары. Аларны хәтта Мәскәүдән үк кайтып җыйдылар. Хәзер бездә ул самавырлар калмагандыр да инде. Медаль төшкән самавырны яхшы дип уйлыйлар, ул останың клеймәсе генә, самавырның яхшы булуын белдерми. Хәзер борыны югалган самавырларны күп алып киләләр. Борыны югалдымы – самавыр самавыр түгел дигән сүз.

Илдар абыйның хәзинәсендә әле сиксәнләп самавыр останың кулы тигәнне көтә. Ат кыңгырауларыннан иң бай күргәзмә дә оештыра алыр иде ул. «Олы улыбызның металл җыю нокталары бар. Шуларны көн дә бер әйләнеп, карап чыгам», – ди ул.

Өч баланың икесе – улы белән кызлары шушында – Балтач районында төпләнеп калган. Кече уллары гына Казанда.

Гадәтемчә, комган, самавыр ясау эше белән кызыксынучылар, өйрәнергә теләүчеләр бармы, дип кызыксынам.

– Әлегә күренми, – ди оста. – Ләкин теләге булган кешегә бер авырлыгы да юк. Тарала башлаган комганны аласың да, шуңа карап өйрәнәсең.

Аның бу сүзләрен Балтач районы Норма авылында яшәүче Илшат Бадихов та раслый. Ул да калайдан төрле эшләнмәләр остасы буларак танылып килә.

– Мәчеттәге иске, су тотмый торган комганнарны реставрацияләүдән башлаган идем, – ди ул үзе бу һөнәре турында. – Аннары кызыма күргәзмәгә алып бару өчен берне ясап бирдем...

Ул да Илдар оста сүзләрен кабатлый:

– Хәзер бит комган ясап сата алмыйсың, кибеттәгесе арзанрак. Үз кирәгеңә дип ясасаң гына...

Нормадагы останың төп шөгыле – мәчет манарасына айлар ясау. Ләкин анысы инде аның башка тема.



■ Илшат Бадихов комганнар ясау белән әле күптән түгел генә шөгыльләнә башлаган.

ЯШӘП КЕНӘ КАРЫЙМ...



Марат
КӘБИРОВ,
язучы

МИН ШУЛАЙ УЙЛЫЙМ

Хәзер яшьләр үзгәрәк. Әйтик, егет белән кыз гашыйк булалар да никахсыз-нисез, хәтта әти-әниләренә дә әйтеп тормастан, бергә яши башлыйлар. Ир белән хатын булып. Кайберләре бераздан уртак гаилә кора, кайберләре тагын берәрсе белән яшәп карый. Гомер буе шулай яшәп карап йөрергә ризалары да табыла.

Миңа бераз сәеррәк инде бу. 20 яшьтә булсам ничегрәк фикер йөртер идем икән? Әйтә алмыйм. Без яшьлектә беркатлырак булдык микән, андый уйлар башка кереп чыкмады: беркем белән дә яшәп караган да, үлеп караган да булмады. Бәлки, шулай яхшырактыр да. Безнең чорда «сафлык» дигән төшенчә бар иде әле. Һәм аны сакларга тырышалар иде. Кызлар гына түгел, егетләр дә. Үз аягы белән ит комбинатына кереп барган сарык шикеллерәк кызларны да ялгыш адым ясаудан кисәтү, вакытында тыеп һәм тыелдырып кала белү бар иде. Чөнки нәфсесенә хуҗа булалмаган егетләр турында: «Алдаган кызны... Харап иткән», – дип әйтәләр һәм бу «көчләгән» дигән сүзгә бәрабәр ишетелә иде. Ә «кулланышта булган» кызларның бәясе бермә-бер түбән йөри, аларга инде җитди мөнәсәбәт югала. Кемнең кеше калдыгы белән гомер итәсе килсен.

Шуңа күрә бергә яшәп карау гадәте юк иде. Бер башлагансың икән, яшәп бетерергә туры килә. Хәтта туйны яки никахны кичектергән очракта да, «яшәп карыйбыз да, характерлар туры килмәсә, аерылышабыз» дип түгел, ә «гомерлеккә бергә» дип тотыныш иде.

Бу – үткәннәрне идеаллаштыру түгел, әлбәттә. Һәр дәвернең үз сволочы була, адашканнары, алдашканнары була. Ә нигездә хәлләр шулайрак иде.

Бүген аз гына бүтәнчәрәк. Сафлык, намус, гаделлек дигән төшенчәләр бик арзан бәяләнгән дәвер. Намус белән яшәүче саф күңелле гадел кешеләр бу заманга кирәкми, алар бик беркатлы яки булдыксыз булып тоела. Бүреләр заманы димим. Аларда табигый гаделлек бар. Бүре тиресе ябынган сарыклар заманы. Теше дә үтми, көче дә юк – ә нәрсәдер умырырга кирәк, юкса, бүре икәнеңә ышанмыйлар. Вәт тырыша теге бөтен мөмкинлеген кулланып...

Бүген бөтен нәрсә матди байлык, акча галиҗәнаплары белән бәяләнә. Һәм ул беркайчан да җитми, затлы киенеп, татлы ашап яшәсәк тә, үзебезне вакыт-вакыт бик хәерче итеп тоябыз. Һәм тагын да күбрәк акча ясау юлларын эзлибез. Моның өчен бөтен көчебезне, мөмкинлегебезне, бөтен нәрсәбезне кулланабыз. Якыннарыбызны кулланабыз. Безне кулланалар. Без – кулланучылар җәмгыяте. Һәм бу җәмгыятьтә «кулланышта булмаган» кеше юк.

Русларда «потребительское отношение» дигән сүз бар. Бездә дә шундый мөнәсәбәт. «Әй, менә моны йөртеп карыйм әле, ошамаса алыштырырмын». Без көненә әллә ничәшәр тапкыр шул сүзне кабатлыйбыз. Кием алганда да, телефон, компьютер, машина, фатир һәм башкаларны алганда да. Шундый караш. Сәнгатькә, әдәбиятка, кешеләргә. Шул мөнәсәбәт мәхәббәткә дә күчә. «Моның белән яшәп карыйм әле...» Бу хәтта мәхәббәт тә, бергә яшәү дә түгел, ә бер-береңне кулланып карау. Ошамый икән – алыштырасың. Һәм монда «кеше калдыгы» дигән төшенчә юк. Кемдер синнән калганны куллана, син – кемнәндер калганны. «Кулланышта булмаган» яр юк монда. Булган очракта да алар аз һәм хәлиткеч көч түгел.

Монысы да гаҗәп. Акыллылар меңгә бер генә туа, мең юләргә бер акыллы туры килә, диләр. Ләкин дөнья шул меңнән бер шәхес акылы белән түгел, ә мең ахмак тавышы белән сайланган юлдан бара. Дөнья белән тавышлар идарә итә.

Монда инде берни эшләп булмый. Безгә охшамаган, бүтәнчә яшәп карарга теләгән яшьләргә бәхет кенә теләргә кала. Һәм без бәхет телибез. Ләкин безнең теләк вак мәсьәлә, әһәмиятсез. Иң мөһиме – алар үзләре бәхетле булырга теләсен. Һәм бәхетле булсын. Булып кына карамасын...

Илсөяр Иксанова шигырьләре укучыларыбызга һәрчак тансык: йөрәкнең әллә кайсы кылларына кагылып, җаннарны актарып ташлый. Бары хатын-кыз күңелендә генә була торган үтә нечкә-нәзберек халәтне башкаларга да күчерә. Игътибарыгызга шагыйрәнең өр-яңа шигырьләрен тәкъдим итәбез.



Илсөяр ИКСАНОВА

ҖӘЙ КАЛГАН АЛАНДА...

Бибимәмдүдә

Бар күңелләрдән җылы,
йомшак синең кабрең ташы, –
Шунда тамсын күз яшемнең
иң ачы вә татлысы!
Габдулла Тукай

Язмышыңа шагыйрь яше аша
Карыймын да...
Сыза бәгырем.
Үзең дә бит үксезлектә үскән,
Тоймый үскән ана кадерен.

Иң мөкатдәс йөрәк тойгыларың
Сеңеп калсын диеп җанына,
«Якут-гәүһәрем» дип Габдулланы
Сөйгәнсең дә сабый чагында...

Ятимлеген биргән язмыш янә,
Таң сапламы гомер юлында,
Толлыгын да биргән
Һәм сынаган
Аерып алып газиз улыңнан.

«Күз яшең дә кипми» фанилыктан
Бакыйлыкка күчкән мәлеңдә,
Җан-Габдуллам диеп,
Җан кылларың
Өзелгәндер, Бибимәмдүдә.

«Ни сәбәптер инде, и Ходая»,
Аз булган шул җыяр тәгамең.
Бу җиһанга Шагыйрь бүләк итү –
Ходай язган бөек гамәлең!

Гамәл дәфтәреңне төрдергәндә
Таң йолдызын Күкләр кабызган.
Һәм...
Шагыйрьнең
Халык бәгырьләрен
Эретерлек яшен тамызган.

***

«Дәүләтсез илнең күрке булмас!»
Казаны булыр, Бүрке булмас.

Бирдек шул Казанны баш белән, –
Ханбикә, ай, кыйгач каш белән.

Бүрексез яшәве кыен ла! –
Кем соң без бу дөнья туенда?

Дәүләтсез милләтнең саны юк,
Дәрьялар кичәргә салы юк.

Татар гел үзенчә сал сала.
Беркетми салган сал таркала...

Дәүләтсез халыкның хакы юк.
Йөге зур, канатлы аты юк.

***

Оялары кабат бушап калды,
Сыерчыклар күчте урманга.
Күңелемне ямансулык сарды, –
Салды мине моңсу уйларга.

Искә төште ятим калган йортлар,
Авыр булып куйды йөрәккә.
Кошлар кебек канат ныгыткан да
Балалары очкан еракка.

Олылары киткән үз юлыннан...
Аямый шул вакыт беркемне.
Шаулап торган йортның капкасына
Йозак сала килеп бер көнне.

Сыерчыклар китте.
Буш ояга
Карап торам җаным сызлатып.
Дәррәү күтәрелде чыпчык күче,
Тирәнрәк уйлар кузгатып:

Сыерчыклар киткәч, чыпчыкларга
И хөррият икән,
Иркенлек!
Бушап калган оя тирәсендә
Куыш бүлешәләр ду килеп...

Сандугач

Сайрап та карый сандугач
Таңнарда-иртәләрдә.
Яраткандыр аны Ходай
Җаннарны иркәләргә!
Чут-чут итеп кагыла ул
Кылларына күңелнең.

Сандугач җанга кагылгач,
Мин җыр булып түгелдем.

Сыерчык

Сыерчык килгән!
Күңелдә
Сабыйлык дертләп куя:
Кайтканнар! –
Эзләп тапканнар,
Буш түгел безнең оя!

Балачактагы шикелле
Ятып аунамасак та,
Язын сыерчыклар күргәч,
Күңел мәтәлчек ата.

Истә сыерчык бураны, –
Бар дөнья карга тулган.
Ышанабыз,
Кайта кошлар
Каф таулары артыннан.

Хәзер нинди таулар кичеп,
Килсә дә кай яклардан,
Сыерчыклар кайта кебек
Безнең балачаклардан.

***

Рәнҗеттең!
Тәүге кат түгел,
Мөгаен,
соңгы кабат.
Мәтәлде күңелем кошы,
Салынып төште канат.

Рәнҗеттең...
Рәнҗешми генә
Аңлашыйк дигән идем.
Хисләрнең якты сагышлы
Күлмәген кигән идем.

Рәнҗеттең.
Уртак елларның
Хәтерен яраладың.
Аңлапмы,
аңламыйчамы,
Үзеңнән араладың.

Җәй калган аланда

Хозурланып йөрим көз иркендә, –
Урман. Тынлык. Уйный яфрак.
Гомеремнең алтын фасылына
Кереп барам.
Бераз ятрак...

Бераз гына...
Ятрак бу халәт.
Көн авышкан. Офык аллана.
Сары капкан урман уртасында
Килеп чыктым яшел аланга.

Яшел алан.
Үтеп киткән җәйнең
Бер кисәге калган көзләргә.
Могҗизамы?
Күз алдында кинәт
Фасылларның төсе үзгәрә.

Ап-ак ромашкалар әйтерсең лә
Сизми калган җәйнең үтүен.
Зәңгәр күзле кыңгыраулар көтә
Күбәләкләр кунып китүен.

Күбәләкләр кунмас, –
Тылсым булмас.
Дәрләп яна урман.
Көз инде.
Ә җәй посып калган бу аланда.
...Мин таныдым анда үземне.

Сәбәп кирәкми...

Халисә Мөдәррисовага

Беләктә – көмеш беләзек,
Көн дә кимим,
Киям сирәк.
Көязләнеп йөрер өчен,
Янәсе, бер сәбәп кирәк.

Бу беләзек – миңа бүләк.
Тик дустымны
Күрәм сирәк.
Очрашулар өчен безгә
Ниндидер зур сәбәп кирәк.
Сәбәп кирәк күрешергә,
Сәбәп кирәк көлешергә.
Вакыт җитми бер сәбәпсез
Хәтта хәл белешергә.

Беләзегем кидем бүген.
Сәбәбе бар – дустым килгән.
Бүген аның бәйрәм киче.
Күңелем тулды әллә нидән...

Көмеш кебек сыза гомер, –
Кирәк түгел аңа сәбәп.
...Җандаш тойгы
Бер сәбәпсез
Күңелләрне тора бәйләп!

Ымсыну

Яңа ел алды.
Алгысый күңел.
Күңелне үртәп ап-ак кар ява.
Җан һаман сабый, –
Могҗиза көтә, –
Чәчәк атар күк серле абага.

Яңа ел таңы.
Сызыла күңел.
Тәрәзәләргә кыш бизәк сара.
Челтәрләп үргән боз бизәкләрдә
Чәчәк атмаган ап-ак абага.

Аһ, бу август!

Әле август,
Бары август,
Нибары август кына...
Ренат Харис

Август кына?..
Август инде!
Көзгә якынлашкан саен
Арта бара җәй кадере!

Август кына?
Август инде...
Моңсу хатирәләр булып
Үзәннәргә таман инде!

Август кына?
Август инде!..
Бу җәйләрне туктатуның
Юкмы икән бер-бер име?!.

Август кына?..
Аһ, август шул!

Саралан көзе

Шагыйрь каләменнән тамган көзнең
Яктылыгы җитте безгә дә.
Шул илаһи Болдиноны уйлап,
Гашыйк идек алтын көзләргә.

Сараланның сары көзләренә
Карадыкмы бераз өстән без? –
Алтын көзләр башка буладыр шул, –
Хыял дөньясында үскәнбез.

Еракларда янган серле көзне
Барып күргәч кызым, сорадым:
«Бик матурмы?..»
«Матур.
Тик Пушкинның
Сараланда юк шул булганы!»

Онегинлы язлар артта калды,
Көзгә кереп киләм үзем дә.
Бөтерелә гомер яфраклары
Сараланның алтын көзендә.





Кәрим КАРА

ҮТКӘННӘРГӘ КАЙТУ ЮК

(хикәя)

«Жизнь с чистого листа…» Мөршидәнең наушникларында җырчы Дима Маликовның ягымлы тавышы яңгырый иде. Менә хәзерге минутта нәкъ Мөршидәнең күңел халәтенә туры килә бу сүзләр. Әйе, барысын яңабаштан башлап карарга, үткәннәрне сызып ташларга, җуеп бетерергә, онытырга. Әнә шундый ныклы карарга килеп, Казан автобусына утырды ул. Мәңгелеккә Чаллы белән хушлашты.

Зур тизлектә асфальт буйлап җилдергән автобусның тәрәзәсеннән табигатьне күзәтеп барганда, Мөршидә үткәннәрне искә төшереп уртларын чәйнәде. Авылдан бәхет эзләп шәһәргә килгән иде ул. Нәрсә килешмәгәндер, гел киресе генә килеп торды аңа. Үзенең җүләрлеге аркасында инде барысы да. Йә, нәрсәгә кирәк иде инде аңа юл буендагы кафега эшкә урнашу? Бергә килгән иптәш кызлары, әнә, тегүчелеккә өйрәнчек булып керделәр: укыдылар да, эшләделәр дә. Ә Мөршидә укып чиләнмәде, акчаны да ахирәтләреннән күбрәк ала иде.


Күңелле булды эш урыны, әйтерең бармы? Ул тирәдә яшәгән кешеләр шул бердәнбер кафега кызык эзләп киләләр иде. Кичләрен музыка яңгырап тора, эчемлекләр елга булып ага, шунда биеп маташкан булалар әле. Әлбәттә, ир-атлар, юк кына сәбәптән дә бәйләнешеп, кафе алдында канга батып сугыша, җитмәсә, кафе эчендә урындык-өстәлләрне әйләндереп каплый торган иде. Атнасына бер булса да хокук сакчылары килми калмый.

Шул ук вакытта төшемле иде официант эше. Кыска итәк, ачык изүле кофта кигән, бизәнгән-төзәнгән кызга төшереп алган ир-ат ашардай булып карый, ничек тә кагылып калырга җай эзләп торалар. Әмма юмарт та түлиләр иде. Шактый акча эләгеп кайта иде Мөршидәнең фатирына.

Бетмәс-төкәнмәс бәйрәмнәр кайнаган кафеда электән эшләгән хезмәткәрләр үзләренең кәефләрен күтәреп алырга да остарганнар иде. Бер түгәрәккә оешып, шәраб бүлешеп йоткалау гадәткә керде. Мөршидәне дә тарттылар мондый «күңелле» эшкә. Ул башта карышып та караган иде, соңыннан үзенә дә ошап китте мондый күңел ачулар.

Илгиз нигә кирәк иде соң аңа? Беткәнмени адәм рәтле егетләр? Юньлерәкләре кичләрен кафеларда хәмер чөмереп йөрми шул. Илгиз гел күз алдында булды Мөршидәнең. Шәһәр егете, киенүләре дә икенче. Кыздан күзләрен аерып ала алмады, акчаны да юмарт чәчте. Ул чакта кран машинасында эшли иде Илгиз, акчаны да әйбәт кенә ала иде. Бер дигән егет икәнлегенә ышандырды Мөршидәне.

Аннан соң Мөршидәне фатирга керткән әби дә бик холыксыз булып чыкты. Юк кына әйбергә дә бәйләнеп, җанын җәфалый иде кызның. Ашарга пешерергә тотынса, артыннан калмый өйрәтеп йөри, идән юганын килештерми, хәтта пычакны тартмага салмый өстәлдә онытып кал-



Рәсем: Наталья Васильева

дырса, зур тавыш куптара иде. Бигрәк тә эштән кайтуларын минутлап күзәтә иде карчык. Чак кына да соңга калырга ярамады Мөршидәгә. Яшь кешегә дүрт стена арасында бикләнеп утырулары җиңелме?

Ә Илгизнең дәү әнисеннән калган бүлмәсе бар иде. Җимерелергә җиткән ике катлы агач өйнең икенче катындагы кечкенә бүлмә иде ул. Карават белән өстәл куйсаң, атлап йөрергә урын калмый. Барыбер шәһәр фатиры бит, суы агып тора, ваннасы бар, утын якмыйсың. Ишек ачып чыксаң асфальтка аяк басасың, тирә-якта кибетләр, каршыда атобус тукталышы. Шәһәр инде ни әйтсәң дә.

Ярты еллап эшләгәч, шул Илгизнең тасма теленә ышанып, шәһәр фатирына кызыгып, кияүгә чыкты да куйды Мөршидә. Гаиләле булды кызый, күп нәрсәләр өмет итте. Әмма Чаллыдагы гомере шул кысан кош оясында үтте. Илгиз эчкечелеккә бирелгәннән-бирелә барды. Эшеннән кудылар егетне, шуннан батырып эшләгәне булмады гаилә хуҗасының. Кайдадыр кереп өч ай эшләсә, ярты ел эшсез йөрде. Ике арадагы мәхәббәт тә сүрелде. Илгизенә ачуланып, Мөршидә үзе дә чәркәгә үрелә башлады.

Бердәнбер көнне айнып киткәндәй булды хатын. Нәрсә эшләп ята ул монда? Алда аны ни көтә? Болай дәвам итсә, тормышның төмам төбенә төшеп, сукбайга әйләнәчәк бит ул. Төннәр буе йоклый алмый ятып, үткәннәрне хәтерендә яңартты Мөршидә, үкенеп, кайнар күз яшьләрен түкте. Һәм ныклы карарга килде: барысын өр-яңадан башларга кирәк аңа! Әле яше үтмәгән, уты чыгып тора, саулыгы бар, ирләр карамаслык хатын түгел. Үз бәхете өчен көрәшәчәк әле ул. Аңа тәгаенләнгән урын да бардыр бу кояш астында!

Казанга якынайган саен, уйлары яктыра барды, йөрәге ышанычлырак типте. Тормышын рәткә салыр өчен ул бар ихтыярын туплап көрәшергә тиеш.

Миллионнар яшәгән зур шәһәрдә урнашып китүләре җиңел булмады. Эш урыны эзләп йөргәндә вокзалда да кунгалады, очраклы танышларының ишек төбендә дә баш терәде, юк кына акчаларын кырып-себереп түләп, хостел дигәннәрендә дә кунып йөрде.

Эзләгән табар, диләр, югары көчләр дә ярдәм иткәндер: уңыш елмайды Мөршидәгә. Зур гына кунакханәдә администратор булып урнашты ул. Яңа эшенә шатланып бетә алмады. Тирә-ягы – чиста-пөхтә, тыныч, аралашкан кешеләре – тәртипле, зыялы. Эше дә артык мәшәкатьле тоелмады. Аның яшәр урыны юклыгын белгәч, шунда кастелянша булып эшләгән казакъ кызы Җаңыл бер фатирда яшәргә тәкъдим итте. Икесенә бүлеп түләгәч, артык кыйммәт чыкмый икән.

Шулай итеп, Мөршидә өчен яңа тормыш башланды. Эшеннән бик тә канәгать иде ул. Бергә яшәгән ахирәте дә – үзара Женя дип йөрттеләр аны – бик тә яхшы булып чыкты. Ике ахирәтнең уйлары беректе, гел икәүләшеп тагылышып йөрделәр, кибетләргә дә, киноларга да бергә бардылар, ашарга да бергә әзерләделәр.

Бер авызы пешкәч, ир-ат турында уена да кереп караганы юк иде Мөршидәнең. Шул кунакханәдә эшләгән куркынычсызлык оешмасы хезмәткәре, Ринат исемле яшь кенә егет күз салды бит аңа. Баштарак Мөршидә җитди кабул итмәде, көлеп кенә карады. Туганы кебек кенә күрә иде ул егетне.

– Син бит миннән ике яшькә яшьрәк, бала гына әле. Бераз үсеп кил яныма, наныем, – дип үртәде тегенә.



Ә егет тәмам сагыз кебек булды, гел каравыллап кына йөрде Мөршидәне. Килгән саен күчтәнәчләр ташый, һәр сүзенә ярарга тырышып кына тора.

– Килсен, әйдә, сүз әйтмә. Бигрәк тәмле булды әле бу юлы китергән алмалары, – дип көлешә Мөршидәнең бергә эшләгән хезмәттәшләре.

Уен гына итеп кабул итсә дә, бу үҗәт егет көннән-көн ошый бара иде Мөршидәгә. Холкы тыныч, аһ итеп тора, авызына хәмер капканы бер тапкыр сизелгәне юк. Мөршидәнең йөрәгендә ярату дигән кайнар хисләр юк иде юклыкка. Әмма ир-ат яхшы гамәлләре белән яулый бит ул хатын-кыз йөрәген...

Көз җиткәч, ахирәте Җаңыл Казакъстанына китәргә җыена башлады. Мөршидә нык ияләшкән иде инде ахирәтенә, һич тә аерылышасы килмәде.

– Анда кайтып ни эшлисең? Монда өйрәнгән идең бит инде, – дип, бүлмәдәшен үгетләп та карады. Нишләмәк кирәк, туган ягын бик сагынган иде шул казакъ кызы.

– Анда минем якыннарым күп гуй. Апаларым, абыйларым, дусларым. Әллә сөйләшкән егетем дә көтә булыр, – дип сагышланды Җаңыл.

– Бик өйрәнгән идем сиңа, – ямансулады Мөршидә.

– Әйдә минем белән, – диде Җаңыл уенын-чынын бергә кушып. – Анда сиңа да урын табылыр. Казакълар татар кызларын ярата ул. Кияүгә бирермен, туй ясарбыз.

Ләкин Мөршидәнең уенда икенче төрле хыяллар иде. Менә Җаңыл китеп, фатир бушаса, Ринатка ризалыгын бирергә җыена иде ул. Ышанычлы егет, кайчан да булса яңа гаилә корырга кирәктер бит инде Мөршидәгә дә...

Әмма барысы чәлпәрәмә килде. Кичке якта алар фатирының ишеген кактылар. Кызлар, ашарга әзерләп, өстәл артына утырганнар гына иде.

– Кем анда? – дип белешә бикне ачарга якынлашкан Мөршидә.

– Участковый Гадельшин. Сабирова Мөршидә монда яшиме? – дигән тавыш ишетелде ишек артында. Шул сүзләрне ишеткәч, Мөршидә тәмам коелып төште. Участковыйны керткәннән соң, аш бүлмәсе белән ике арадагы ишекне ныклап ябып куйды. Бу хәбәр Җаңыл колагына тиеш түгел шикелле.

– Мин булам Мөршидә Сабирова. Йә, шуннан? – диде ул тонык тавыш белән. Үзе стенага сөялергә ашыкты. Буыннарының хәле киткән иде аның.

– Сез, гражданка Сабирова, розыскка бирелгән. Әниегез Мәймүнә Галәветдинова эзләтә сезне. Сарман районыннан. Бүгенге көндә ул нык чирләп хастаханәдә ята. Аның карамагында булган ике балагыз – Гөлия белән Иршат – вакытлыча Балалар йортына урнаштырылган. Иртәгәдән туган нигезегезгә кайтыгыз, әниегезнең хәлен белешегез. Балалар йортыннан сабыйларыгызны барып алыгыз. Менә, кулыгызга уведомление тоттырам. Кул куеп алыгыз. Кушканнарны төгәл үтәгез, сак астында озатырлык булмасын. Әгәр сорауларыгыз булмаса, мин киттем. Хушыгыз...

Әлеге лейтенант чыгып китте. Киндердәй агарган Мөршидә, кузгалырлык та көч тапмыйча, озак сөялеп торды әле акшарланган стенага. Җаңыл чыгып кына сөйрәп диярлек алып керде аны, көчләп ашарга утыртты.

– Кем йөри иде соң анда? – дип кызыксынды ахирәте сүз арасында.

– Газ тикшереп йөриләр. Нәрсәдер сөйләде дә кул куйдырып чыгып китте, – дип алдашты Мөршидә. Тамчы ризык каба алмады ул авызына, гел чәй чөмерде. Шуннан аруына сылтап, ятарга ашыкты. Башын юрганы белән томалады да стенага таба борылып, хокук сакчысы сөйләгәннәрне хәтерендә яңартты.

Алай икән... Әнисе, мескенкәй, аяктан егылганмы шулай? Өелеп килгән авырлыкларны йөрәге күтәрмәгәндер. Яше дә бара бит, сәламәтлеге дә чамалы инде. Өстәвенә, өч чүмеч дигәндәй, Мөршидә анасына ике баласын да тагып чыгып киткән иде бит әле. «Кайтып алам!» – дип антлар эчкән булды ул вакытта. Ул балаларга баш булу өчен күпме көч-куәт кирәк! Тамакларын кайгырт, өс-башларына җиткер, чирләсәләр – яннарында төннәр үткәр. Бер минут та калдыра алмыйсың аларны, икесе дә чак аякланган бозау кебек. Берәр төрле хөкүмәт акчасы да килми бит ичмаса үзләренә. Мөршидә кәгазьләр артыннан йөреп вакыт үткәрмәде. Әнисенең бер пенсиясенә ничек җан асраганнардыр...

Хәзер барысын ташлап, Мөршидә үткәнгә кайтырга тиешме? Әнисе үлеп-нитеп китсә, балаларын кочаклап ул утырып кала җимерелеп беткән өйдә. Авыл җирендә эш табармын димә инде син. Ул балаларны аякка бастырганчы, адәм иткәнче, җиде тәмуг кичәргә кирәк булачак әле Мөршидәгә. Ә үзе өчен кайчан яшәргә? Хатын-кызның гомере кыска, ун-унбиш елдан кемгә кирәге кала аның? Гомер бер генә, аны кире кайтарып булмый. Нишләргә соң аңа, нишләргә?..

Телен канатканчы тешләп ятты Мөршидә, күз яшьләре мендәрен чылатып бетерде. Җаңыл утны сүндереп ятуга, бүлмә караңгылык эченә чумды. Мөршидәнең башында берсеннән-берсе хәсрәтлерәк уйлар чуалды.

Таңга таба билгеле бер фикергә килде ул. Юк! Җир шары урталай ярылса да, кайтмый ул үткәннәргә. Аның да хакы бардыр өлешенә тиешле кечкенә генә булса да бәхеткә! Әнисе, мескен, вафат булыр инде, бер уч туфрак та сала алмас каберенә... Нишлисең, барыбызга да бер үләсе. Авылдашлар күмәр әле хөрмәтләп. Әни назын татымыйча, балалары тома ятим булып ничек үсәр?.. Андыйларны да хөкүмәт карый хәзер, тәрбиясен бирә. Бер дигән булып үсеп китәрләр. Ә Мөршидә яңа гаилә корыр әле, тагын балалар алып кайтыр, яхшы ана булып игелекле балалар тәрбияләр вакыты җиткәч. Ләкин үткәннәргә кайту юк. Алда көтә аны бәхет кошы.

Иртән Мөршидә ахирәте Җаңылга аның белән Казакъстанга китәргә риза булуын әйтте. Баштарак Җаңылның йөзендә гаҗәпләнү билгеләре чагылып калса да, шатланып кабул итте ул бүлмәдәшенең карарын.

Төштән соң ике ахирәт, чемоданнарын күтәреп, «Казан–Ташкент» поездына кереп утырды. Тәрәзә аша Мөршидә моңсу гына туган яклары белән хушлашты. Ә колакчынында Маликовның чиста биттән яңа тормыш башлау турындагы җыры яңгырый иде...

ӘНИЛӘРНЕҢ БӨЕКЛЕГӘН ЯШИ-ЯШИ АҢЛЫЙБЫЗ

Алда – иң җылы бәйрәм – Әниләр көне. Минем өчен ул аеруча якын. Һәркем өчен дөньяда иң кадерле, иң газиз кеше бит ул әни.

Әнием Миңлебәнат белән миңа алтмыш елдан артык яшәргә насыйп булды. Яшьли ятим калган әнием, тормышта нинди генә кыенлыклар, авырлыклар күрсә дә, озын гомерле булды. Хезмәт аны тәрбияләде, «стахановчы» биеклегенә күтәрде. Кадерле әнием бакыйлыкка 98 яшен тутырып күчте. Күңелләребездә ул әле дә иң кайгыртучан, иң яратучан, иң якты әни булып саклана.

Зур дәүләт бүләкләрен алучыларны тантана вакытында күзәткәндә, аларның рәхмәт сүзләренә игътибар итәм. Олы сәхнәләрдән, беренче нәүбәттә, сабыр, акыллы, мәрхәмәтле әниләренә эчкерсез хисләрен белдерүчеләр сирәк шулай да.

Шуннан башыма бер фикер килде: биек үрләргә күтәрелгән зур шәхесләрнең үз әниләре турында нинди хатирәләре бар икән? Һәм менә шул уй китап булып тормышка ашырылды. «Әнкәм йорты – алтын бишек» дип атала ул китап. Анда – төрле милләт кешеләренең хатирәләре, сагынычлы истәлекләр. Менә берничәсе генә...

Композитор Фасил Әхмәтов истәлегеннән: «Сугыш башланганда әни дүрт бала белән калды. Әти – сугышта. Яшь әни авырлыкларның барысын да күрә. Үзе утын кисә, үзе яра, печән чаба, мал карый, бакча утырта... Озын караңгы кичләрдә әни безгә үзе яраткан «Сак-Сок» бәетен еш җырлый иде... Ял көннәрендә әти кулына гармун ала, әни халык көйләрен җырлый. Без, балалар, аңа кушылабыз».

Галим Марсель Әхмәтҗанов күңел капкаларын сак кына ача: «Шулай бер көнне әнием мине кибеткә икмәк алырга җибәрде. Анда азык-төлек әйберләре белән бергә китаплар да сатыла иде. Шүрлектә яраткан китабым «Робинзон Крузо»ны күргәч, икмәккә дигән акчага шул китапны алып кайттым. Әни ачуланмады, елмаеп кына куйды...»

Композитор Резеда Ахиярова әнисенә мәдхия җырлый: «Минем өчен әни – дөньяда бер ул! Ул бервакытта да ялгышмады, аның алдан күрә белү сәләте бар иде. Әнием минем музыкага талантым барын алдан ук тоймаган булса, Резеда Ахиярова дигән композитор булмас та иде. Минем өчен әни үз халкыма хезмәт итү үрнәге булды. Ул 200 ләп фәнни хезмәтнең авторы. Араларында әлифба-букварьлар, дәреслекләр, монографияләр, методик ярдәмлекләр бар.

Татарстанның халык язучысы, драматург, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллин хатирәләрен шулай ук дулкынланып укыйсың. «Кайчандыр әни миңа бары тик әни генә иде. Иң элек мине ашатырга тиешле әни, аннан соңрак матур итеп киендерергә мәҗбүр әни, аннан мин теләсә нишләп йөрсәм дә, кисәтеп, миңа сүз әйтергә хакы юк әни. Әни һәрвакыт миңа тиешле булды... Балалар, күрәсең, әти-әниләренә мөнәсәбәттә эгоист булалардыр. Ихтимал, монда без белеп, аңлап җиткермәгән ниндидер рәхимсез закончалык та бардыр. Ни генә булмасын, без исән әниләребезнең кадерен белеп бетермибез – монысы аяныч факт...

Әниләр бары тик тиеш кенә. Дөрес, гомеребезнең башлангыч өлешендә, чыннан да, алар безгә тиештер. Дөньяга китергән икән, ул үз баласын дөньяда, кешеләр арасында йөрерлек, яшәрлек итеп тәрбияләргә бурычлы. Аннан соң инде – ике аякка нык басып йөри башлагач – бары тик без генә тиешледер.

...Башкаларны хөкем итәргә алынмыйм, әни белән икебез арасындагы мөнәсәбәтләр турында уйланганда, әни үзенә тиешлесен артыгы белән үтәде, мин аңа мәңгелек бурычлы булып калдым дип саныйм.

...Газета-журналларда хикәяләрем күренә башлагач, әни шуларны урам буйлап күрсәтеп йөргән. Бервакыт кибеттә мактанып торганда: «Әй, мондыйны мин дә язам», – дигән берсе, әни пыр тузган, теге кеше кибеттән чыгып качарга мәҗбүр булган.

...Мин авылга кайтканда, әни һәрвакыт: «Әйбәт кәчтүн-чалбар, эшләпә киеп кайт, – дип кабат-кабат тукый иде. Акчаны үзем белән алып кайтмаска., почта белән җибәрергә куша иде. Нигә икәнен соңрак белдем. Ул акчаны почтага барып алганчы, әни, укый белмәгәнгә салынып, кибеттә акча язуын кешеләргә укыта икән. «Тагын җибәрәм дип әйткән әле Туфан», – дип сөйләнә икән, җитмәсә. Белмим, күпме тапкыр җибәргәнмендер (һәрхәлдә, күп түгел) әниләргә акча, әмма авыл халкының хәтерендә миннән акча явып кына торган кебек булып калган. Барысы да әни аркасында. Безне яхшы итеп күрергә һәм күрсәтергә теләве бик көчле иде аның.

Ул әдәби, фәнни китаплар укып, философик категорияләр белән фикер йөртми иде. Философиясе бик гади иде аның. «Ил алдында хур булма, кеше көлдермә, яманатың дөньяга чыкмасын» – аның безне тәрбияләүдәге төп принциплары шул булды».

Горурланып әйтә алам: татар халкының яраткан язучысы Туфан абый Миңнуллин – әниемнең якташы да әле! Әнием дә, Олы Кариле авылы кешесе буларак, горур булды, телдәге халыкчанлыгы, йомры сөйләме белән бүтән шәһәр хатыннарыннан аерылып тора иде. Сүзне сөйләгәндә ул еш кына мәкальләр һәм әйтемнәр кулланды.

Бу китабымда һәр әнинең рухи бөеклеген күрсәтәсем: «Җиргә матурлыкны, илгә батырлыкны сез бирәсез, газиз әниләр!» – дип әйтәсем килде.

Суфия БӘДРЕТДИНОВА,
К. Насыйри исемендәге премия лауреаты.
Казан шәһәре.


Халисә Миңнуллина ире Габдулла һәм улы Туфан белән.


Марсель Әхмәтҗановның әнисе Хәлимә Сәхибҗанова-Мифтахова.


Авторның әнисе Бәнат (Миңлебәнат).


Резеда Ахиярованың әнисе Мәрьям ханым.


Фасил Әхмәтовның әнисе Бибисара Әхмәтова ире, балалары белән.

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Авылыбызның иң матур урынын «Кави мулла нигезе» дип йөртәләр. Заманында Нәфисә абыстай һәм Габделкави Кавиевлар балаларны укырга-язарга өйрәткән. Бик укымышлы, фидакарь булган алар. Каюм Насыйри белән аралашып, аңа туган як тарихын язарга булышканнар. Аларның мәгърифәтчелек эшен уллары Сәлим (1880–1942) дәвам итә. Ул Казан мәдрәсәсендә белем алып, авылда указлы мулла була. 24 яшендә кулына Коръән тотып, Мәккәдә хаҗ кыла. Сәяхәт иткән җирләрен картага төшереп бара. Аның бу картасы нәсел дәвамчыларында әле дә саклана. Хаҗ кылып кайткач, Сәлим Кавиев Яшел Үзән районы, Шырдан авылыннан Шәмсетдин кызы Закирәгә өйләнә. Матур тормыш итә алар. 1906 елда олы балалары Хәмит, аннан Мөршидә, Тәлгать, Суфия, Рәфкать, Әнвәр, Сәлимә, Шамил дөньяга килә. 1908 елда туган Мәҗит геология фәннәре докторы була. Татарстанда геология-нефть разведкасы җитәкчесе булып эшли. Бу гаиләдән дүрт кеше Бөек Ватан сугышында катнаша. Олысы Хәмит – фронтовик язучы. Ул Казанда педагогика техникумын, Көнчыгыш педагогика институтының биология бүлеген, аспирантура тәмамлый. Хәмит Кави география, геология фәннәрен өйрәнеп, илебезнең төрле почмакларына сәяхәт кыла. Күргәннәре турында фәнни-популяр очерклар, мәкаләләр язып, китап итеп чыгара. «Кавказ таулары аша җәяү», «Идел буенда йөрү юллары», «Кузбасска сәяхәт», «Кильдин атавы» исемле китапларын ул чорда яратып укыйлар. 1939 елда Хәмит Кавига Мәскәүдә Тышкы сәүдә халык комиссары имзасы белән исемле сәгать бирелгән.

Бөек Ватан сугышында ул танк командиры була, Идел буеннан Көнчыгыш чикләргә кадәр сугышчан юл уза. Ни кызганыч, кулына мылтык һәм каләм алып җиңүне якынайтырга тырышкан авылдашыбыз танкта янып үлә. Дусларын (аларның Актаныштан булуы билгеле) коткарып, аларны люктан чыгарырга өлгерә. Хәмит абыйлары кебек үк Тәлгать, Суфия, Рәфкать тә Бөек Ватан сугышында үзләрен аямыйча җиңү өчен көрәшәләр. Казан медицина институтында укучы студент кыз Суфия үзе теләп фронтка китә. Ленинград фронтының 2 нче Удар армиясендә меңнәрчә яралыларны коткарып кала яшь кыз. Гатчина Кызыл Байрак орденлы дивизиясенең 884 нче укчы полкның хәрби табибы Суфия Кавиева «тормыш юлы» сугышында батырлык күрсәтә, ул Германиягә кадәр барып җитә. 24 яшьлек кыз Кызыл Йолдыз ордены һәм күпсанлы медальләр белән бүләкләнә.


Фото: хәрби табибә Суфия Кавиева, Германия, 1945 ел.

Равилә МӨБАРӘКШИНА.
Чуаштан, Әлмәт.

Үткәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен бел, ди безнең халык. Бөек Ватан сугышы чоры турында әсәрләр күп укыйм, кинолар яратып карыйм. Мәктәптә укыган чорда иншаларны бик яратып яза идем, ләкин сугыш чорында яшәгән, бу авырлыкны үз җилкәсендә татыган кешеләр белән сөйләшү, аларны тыңлау башка шул.

Хатирәләрне яңарту өчен мин әниемнең ике туган апасы М. янына еш килем. 91 яшь тулса да, матурлыгын югалтмаган, үткәннәрне

бүгенгедәй хәтерли ул. Бала чакларын, сугыш чорларын искә алып сөйләшеп утырырга да ярата апабыз. Сугыш башланганда бары тик 3 нче класс укучысы гына була ул.

«Хәтердә мәңгегә уелып калган ул көннәр, – ди апам. – Сугыш балачагыбызны гына түгел, ә иң якын кешеләребезне тартып алды.

Бу авырлыкны күргән көннәр еракта калса да, хатирәләр онытылмый».

Сугыш чорының күңелсез көннәре минем әти-әниемә дә барып тоташа.

Әнием Урал тауларына урнашкан шәһәрләрнең берсендә дөньяга килә. М. апам истәлекләре буенча, бабам монда яшәп, шахтада күмер чыгарган. 1941 елда ул сугышка китә. Әниемә – 1 яшь, ә энесе әле әнинең карынында гына кала... Апамның, бу балаларны ничек үстерермен, дип ачыргаланып елаганы хәзер дә күз алларымнан китми, дип искә ала М. апам. Сугыштан бабамның бер генә хаты килә. Шул елны хәбәрсез югалды дигән сагышлы хәбәр ала аның гаиләсе. Шуннан алар Уралны ташлап, Татарстанның Балык Бистәсе районына кайтып урнашалар. М. апам әниемне бик ярата.

Ул дәү әниемә балаларын үстерергә бик нык булыша. Яшьли тол калган дәү әниемнең ачы кайгысын бар күңеле белән аңлагандыр. Ул чорда толлар күп була шул...

Әтиемә дә беркайчан да әтисен күрергә, әти диеп дәшәргә, ир бала буларак киңәшләр сорарга насыйп булмый. Ятимлек – мәңге төзәлмәслек йөрәк ярасы. Сугыштан соңгы авырлыклар, ачлык, өстәвенә, ятимлек ифрат дәрәҗәдә авыр була.

«Өшегән бәрәңге ашап үстек без. Чүп үләне – алабутага аз гына он салып, әни көлчә пешерә иде. Их, аның тәмлелеге!» – дип, бик еш искә ала иде әтием.

Инде Бөек Ватан сугышы тәмамланганга 75 ел булды. Авыр хәсрәтләр калдырган сугышны онытмасак иде! Әби-бабаларыбыз күргән авырлыкларны, сугыш, тыл ветераннарын, яу кырында ятып калганнарны хәтерләргә без бурычлы!

Рузилә МИЯССӘРОВА.
Саба районы, Икшермә авылы.

Ульяновск өлкәсендә яшәүче күренекле татарларыбызның берсе Флорис әфәнде Галимьянов үзенең иҗаты, шигъри сүзе белән һәрдаим милләттәшләребезнең күңелен җылытып тора.

Аның исеме «Сембер–Ульяновск төбәге татарлары» энциклопедиясенә дә кергән. 2020 елдан ул Россиянең иҗат эшлеклеләре берләшмәсе әгъзасы. Халыклар дуслыгы йортында, Татар мәдәнияте үзәгендә, китапханәләрдә үткәрелгән милли чараларда актив катнаша. Үзешчән сәнгатьтә, әдәбиятта ирешкән уңышлары өчен «Өмет» газетасы редакциясенең һәм Бөтендөнья татар конгрессының Рәхмәт хатлары белән бүләкләнгән.



Флорис Галимьянов – тумышы белән Башкортстан якларыннан. Мәктәптән соң техник училище тәмамлап, хезмәт юлын Чиләбе өлкәсенең Сатка шәһәрендә башлап җибәрә. Дүрт ел дәвамында Тын океан флотының атом су көймәләрендә электриклар командасы старшинасы сыйфатында диңгез-океаннарда йөзә. «Хәрби-диңгез флоты отличнигы», «Германияне җиңүгә – 20 ел» медале белән бүләкләнә.

Армиядән соң Чиләбе мәдәният институтында белем ала. Мәдәният училищесында – укытучы, мәдәният сараенда бүлек мөдире һәм директор булып эшли.

Мәктәптә укыганда ук шигырьләр яза башлый. Беренче шигырьләре 12 яшендә район газетасында басыла. Аннары алар Уфада нәшер ителүче «Кызыл таң» татар газетасында урын ала.

Бу газета белән иҗади дуслыгы бүген дә уңышлы дәвам итә. Чиләбедә ул Муса Җәлил исемендәге әдәби түгәрәккә (җитәкчеләре – Салисә Гәрәева белән Рамазан Шаһалиев була) йөри. Шигырьләре әледән-әле Уфа, Казан, Чиләбедә нәшер ителүче газета-журналларда басыла.

1985 елда язмыш Флорис Галимьяновны Ульяновскига алып килә. Сембернең «Чулпан» ансамбле конферансьесы булып, концертлар белән Ульяновск өлкәсен, күрше Татарстанны йөреп чыга. Самара өлкәсе дә читтә калмый. Менә утыз ел инде ул үзешчән сәнгатьне, туган телебезне саклап калу өчен белемен дә, тәҗрибәсен дә кызганмый.

Шәһәребездәге заводларның берсендә партгруппорг, цехком рәисе булып эшли. Хәзер лаеклы ялда инде, «Хезмәт ветераны» дигән мактаулы исем иясе.

Шигырьләре «Өмет» газетасының беренче саныннан бүгенге көнгә кадәр басылып килә. Аның иҗат җимешләре китапларда, әдәби җыентыкларда дөнья күрә.

Флорис Сабирьян улы бу көздә 70 яшен тутырды. Ул тормышта да, шигъриятe кебек үк басынкы, кешелекле. Авторның булмышы, күрәсең, лирик героеның табигате белән туры килгәндер: горур, ихлас. Ялган даннарга исе китми аның...

Рузия ХӘЛИМОВА.
Ульяновск шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA

САРА ХАНЫМ



Туган-тумача, тирә-күрше генәме, бөтен авыл үз итеп, яратып Сара ханым дия иде аны. Ханым диярдәй хөрмәтле хатыннар җитәрлек – авыл советы рәисе Мәгърифә апа, табибә Кафия апа, укытучылар бар. Әмма аны – гади авыл апасын гына «ханым» дип зурлыйлар! Гаҗәп кебек. Сер ачкычы әллә ни ерак та яшерелмәгән.

Җыр-моңга мөкиббән идек без. Казан радиосыннан һәр якшәмбене яңгырый торган ял концертларын көтеп алабыз, гаилә белән җыелып җыр тыңларга үлеп яратабыз. Җәен булсын, көзен – ял көне дию юк, иртә таңнан торабыз да, Рәзилә сеңел белән икәүләп ике тазда кер уарга тотынабыз. Аннан идән-сәкене ышкып юып чыгарабыз. Ике көянтә керне тау астындагы Газзә чишмәсенә алып төшеп, улак тулып аккан салкын суда кат-кат чайкыйбыз. Керләрне бауга элеп керүгә... Өй май булган, шундый рәхәт, җылы, кояш нуры тулган. Мичтә бәлеш, йә бәрәңге тәкәсе яки шаңгә пешә. Баш әйләнерлек тәмле ис таралган – әнкәй табаларны мичтән чыгара. Табынга могҗизаи ямь өстәп радиодан җыр агыла. Сара апа Садыйкова белән әңгәмә дә яңгыраса... Алып баручы сүз саен «Сара ханым» дип композиторга мөрәҗәгать итә. Безгә шул җитә кала: әнкәйнең дә исеме Сара бит, димәк... Бала-чаганың җиңел кулыннан «Сара ханым» исеме гомерлеккә ябышып калдымы аңа, бүтәннәр әйттеме, белмим, әмма беркем гаҗәпләнмәде моңа. Нәсел тамырлары ханнарга барып тоташса да гаҗәп түгел. Ипле, итагатьле, зирәк, акыллы, кешеләргә фәкать яхшылык тели торган изге күңелле Ана иде ул. Тумыштан ук затлы-нәзакәтле, зәвыклы булып яратылган сөйкемле зат, тавышы йомшак-ягымлы, җыр кебек – үзе моңлы, назлы, сөйләгән һәр сүзе мәгънәле. «Һаваларда очкан кошлар кебек...» – иң яраткан җыры иде. «Ярсый-ярсый канат кагынып, туган җирем, кайттым мин талпынып, якыннарым, сезне сагынып...» Йосыф-Зөләйха кыйсса-

сын, Сак-Сок бәетен, мөнәҗәтләр укуын тын да алмый тыңлыйбыз. Мин Тукай, Такташ, Әнгам Атнабаев шигырьләрен яттан укыйм. Дөрес, андый ямьле, рәхәт кичләр сирәк бәхет, әнкәй гомере буе саулыкка туймады...

Ул михнәтле елларны искә алу да авыр. Ир-егетләр фронтта кан койды, бала-чага, картлар, хатын-кызлар тылда көнне төнгә ялгап авыр хезмәттә изелде. Җиткән кызларны окоп казырга, торф чыгарырга, шахталарда күмер ватарга кудылар. Габдулла кызы Сараны да Канаш якларына окоп казырга «вербовать» итәләр. Зәмһәрир суыкта юка өс-баштан, туң җирне ломнар белән ватавата, ачлы-туклы эшли татар кызлары. Барысы да фронт өчен, җиңү өчен! Адым саен ачы сынау сагалый, итеген урлата, чабата-оек теткәләнеп, бияләйләр тишелеп-ертылып бетә. Тиф якадан алгач, тәвәккәлләп, юлга кузгала. Качып кайтканмы, моңардан барыбер рәт чыкмас дип, китәргә рөхсәт биргәнме берәрсе, әнкәй күңелсез тәэссоратлар белән бүлешүне сөйми иде. Туган апа сөйләгәннәрдән генә күзаллый алам. Чит җирдә ятып калу куркыткандыр, ни булса шул дип, бер тиен акчасыз, ризыксыз, чирле килеш юлга кузгала. Идел бозын ничек кичкән дә, янә өч йөз чакрым юл узарлык көч каян иңгән – коры сөяк – шәүлә булып кайтып егыла. Язмыш йөртәдер адәм баласын. Раббыбыз рөхсәтеннән башка агачтан яфрак та өзелеп төшмәс, дип гоманлавыбыз хактыр.

Ревматизм буыннарны ялый, йөрәкне ашый, диләр. Ревматизм идеме бу, артритмы, без белә-белгәннән бирле чир белән көрәште. Кул-аяк бармаклары кәкрәеп каткан иде. Берничә ел рәттән Барҗы-Ятчә шифаханәсендә ләм белән дәваланды. «Тагын ике-өч җәй грязелечение алсагыз, аякка басарсыз, апа», – дип юатуларына куануы! Әмма икенче язда да, өченчесендә дә бара алмады әнкәй санаторийга. Йөрәге начар, андый дәваны күтәрерлек түгел, диделәр.

Сызланса да сер бирми, сырхауларга бирешми, дөнья гамен кайгыртып яшәрлек көч каян иңгәндер: йөзе һәрчак ачык-елмаюлы булды. Киңәш сорап, хәл-әхвәл белешергә килүчеләр бусагага тузан кундырмый. Кем керсә дә яктырыперәп сөйләшә, күңел күтәрерлек ягымлы сүз таба. Кешенең хәл-халәтен нечкә тоемлый, тыңлый белә, берәүне дә гаепләми, гайбәтләрдән ерак. Бүтәннәр сөйләгәнне дә өнәми: «Адәм – фәрештә, әрекмән кәбестә булмас», – дип кенә куя. Зирәк акыллы, читятларга да хәерхаһлы, тормышны, кешеләрне өзелеп ярата торган олы йөрәкле чын Кеше иде шул Сара ханым.

«Бүген дә таң атканын күрдем, кояшны каршыладым, мең шөкер, рәхмәтле мин Ходама!» – дип, һәр иртәне сөенеп каршылый. Гомер итү – кыр кичү түгел. Сугыш тапаган, имгәткән ир белән хатынга бигрәк тә... Әткәй кулын куеп (үзе шулай дия торган иде) кайткан, песи төчкереге кадәр пенсиясенә тормыш алып барырлык түгел, көтү дә көтте, идарәдә төнге каравылчы, йомышюлга йөгерүче дә булды, мал да асрады, биш балалы гаиләне ачка үтермәс өчен көн-төн чапты. Әнкәйнең хезмәт фронтында имгәнүен искә-санга алучы, пенсия хакында авыз ачучы да юк. Берсендә, идарә утырышы барганда кемнедер җәһәт кенә чакырып китерергә кирәк

Рәхимсез сугыш изгән-имгәткән ачы язмышлы миллионнарның берсе иде бит ул да.

була. Әткәй – көтүдә, балалар – укуда, аксый-туксый әнкәй Югары башка менеп төшкәнче байтак гомер уза. Җитмәсә, чакырткан кеше килми: әллә өйдә булмый, әллә качып кала. Рәис (ул чакта перси диләр) – чит авылдан килгән адәм, йомышчыны, ягъни әнкәйне, озак йөрисең, дип, нык кына оялтмакчы була. Шулчак фронтовик, туры сүзле идарә әгъзасы Габделхак абый тупас сүзләрен аның үзенә каршы юнәлтә: «Чамалап, энем, әгәр каһәр төшкән сугыш чыкмаса, син утырган йомшак урындыкта, ә бәлки югарырак та менә бу тыйнак, синнән күпкә акыллырак апаң утырган булыр иде. Министр булырга лаек иде ул!» – ди дә торып чыгып китә.

Министр ук булмаса да, горурлыгы, олылыгы, тугрылыгы, зирәклеге белән йорт тотучы, учак җылысын сүндерми саклаучы иде әнкәй. Әтәгез, балалар, дип, куаныч, якты нур өләшеп яшәде. Биш бала тудырды – бер йодрык! Күкрәк сөтен имезеп үстерде. Атага хөрмәт, кадер дигәнне үз мисалы белән әнкәй булдырды. Ул кайтмыйча табынга утыру юк, казанда ни генә пешсә дә, үлән ашымы, налог түлисе сарыкның баш-аягы, үпкә-бавырымы – чүмеч тутырып башта аңа бүлә: «Әтәгезгә, ул сау булса, без яшәрбез!» «Ватан – ата, бер тамырдан, атаны хөрмәт итмәгән ватанның эше хөрти». Әнкәй мәкальләр, тапкыр сүзләр, табышмаклар белән сөйләргә хирыс. «Җир астыннан юллар булмас, ешрак кайтыгыз!» – дип озата безне дә. Күз күгәртеп көтә, ә без... көттерәбез. Эш кешеләре, янәсе.

«Шыңгырдаган агач озак яши», – дия торган иде әткәй. Чынга ашмады өмете. Картаерга, әнҗе кебек тезелгән тешләре какшарга да өлгермәгән килеш, февраль бураннары алып китте аны. Кап-кара толымында көмеш җепләр күренгәли генә башлаган иде. «Син әткәңә охшагансың, алар нәселе яшьли агара», – дип юата иде минем иртә чаларган чәчемә ымлап.

«Ипигә туйгач бит... Тамак туярлык ризык булгач кына китеп барды...» – дип, үпкәләгән сыман, чарасызлыктан аптырап утырганын хәтерлим әле әткәйнең. Әнкәйдән калып, тол ир булып ялгыз башы егерме ел яшәде. Сагынып, әнкәйне искә төшермәгән берәр көне булдымы икән? Үкенүләр гомер буе җанны бимазалар. Әнкәләренең җитмеш, туксан, хәтта йөз яшен бәйрәм итә алган бәхетлеләр бар бит дөньяда, дип уйлыйм да көрсенәм. Тик без түгел... Үзе үлгәч архивтан соратып алган таныклыкка карасаң, әнкәйгә быел унынчы августта йөз дә бер яшь туласы булган. Иркәләнеп, әнигә сыенып, үзеңне бала итеп тоеп озаграк яшәү бәхете тәтемәде. Ходай җыяр ризыгын аз, гомерен кыска итеп яраткан. Ул юк, күптән юк инде. Ни үкенеч, өзелеп яратуыбызны белдерергә дә өлгермәдек. Тау башындагы мәңгелек йортын зиярәт итәргә кайткач, шөкер, әти-әни

Телендә дә, күңелендә дә рухыңны баетырлык дөрес сүзләр генә булыр иде.



Уң ягымда – кызым Миләүшә, сулда – әнием, сеңлем Рамилә кызы Ләйсән белән.

йөзенә кызыллык китермәдек моңарчы дип юангандай буласың да...

«Кодрәте зур һәрчак аналарның», ди шагыйрь. «Әни! Мине күптән җиңгән булыр иде каршы җилләр, каты яралар, / Син тормасаң әгәр калкан булып, хәвеф белән минем арада». Әнкәйләргә багышланган һәр сүз йөрәккә үтеп керә...

Һәркемнең әнкәсе берәү генә, ул – бердәнбер. Ун-унике яшьтәме син, утыз-кырыктамы, ихлас күңелдән сине яратучы, «балам» дип эндәшүче, сагынып көтүче бердәнберең – Әниең исән чакта син әле бала. Әмма моның олы бәхет икәнен аңлар өчен вакыт кирәк. Әниләр безгә һәрчак нәрсәдер тиеш кебек: тәмле ашатырга, матур киендерергә, иркәләп, назлап йомшак урында йоклатырга, хата-кимчелегеңне, хәтта гаебеңне дә берсүзсез кичерергә! Ялгышларны төзәтергә әзер хәерхаһлы киңәшчең барында моның олы куаныч икәнен дә, аналарның фидакарьлеген дә бәяләп өлгермисең. Әниләрен иртә югалтканнар гынамы, иртәме-соңмы, һәммәбез аңлый моны. Тик соң булуы үкенечле.

Истәлекләр...

Берзаман бәләкәй Миләүшә «Сара ханым» дигәнне ишеткән дә, әйтә белмәгәнме, теле ятып җитмәгәнме: «Дәү әнием – Сарафаным» дип эндәшкән. Шуннан китте, уенын-чынын бергә кушып без дә: «Сара ханым – Сарафаным» дип шаяртып сөйли башладык. Үпкәләмиme, хәер, кемгә дә булса үпкәләү-рәнҗү дигәнне белми дә иде бугай ул. Хәтер калу, күңел кителүләр, бәлки, бик ерак та йөрмәгәндер, әмма ямьсезләнеп усаллану холкына хас түгел. Хөсетлек, вак хисләрдән өстен иде ул. Төче сүз, ялагайлык та калебенә ятмас, килешмәс тә иде.

...Тамыр-үсентесен кем, кайчан биргәндер, нәзберек хризантемаларны үз итә иде әнкәй. Чын күңелдән гашыйк иде ул аларга. «Әрем тәме килә», – дия иде! Тәме түгел, бәлки, исе дигәндер. Балачак хәтере «тәме» дип истә калдырган.

Алтындай сары чәчәк ата торган хризантемалары ул елны көздән үк, иртә сулды. Бүтән елларны кырауларга бирешми балкып утыра иде, ни килешмәде, дип аптыраштык. Белмәдек, әнкәйнең соңгы кышы булган бу. Корыган гөл тәрәзә төбен ямьсезләп тора, дип, Венера гөл чүлмәген базга төшереп куйган.

Әнкәйнең кырыгына кайткач, рухына багышлап Коръән укытып аш уздыргач, бераз тынычлангач, киленебез баздан гөл чүлмәкләре алып менде. Туфрагына җылы су сипте. Чүлмәкләре таза, гөл утыртырга ярар...

«Эш-мәшәкать белән атна-ун көн узды. Карасам, әсәренеп киттем, әнкәй гөле исән икән бит, яфрак ярып ята», – дип сөйләде Венера.

...Көннәр язга авышып, түр тәрәзәгә шифалы нур көлтәләре сирпелүгә әнкәйнең яраннары да чәчкәгә бөреләнә иде. Күңелгә ашерен шатлык, әйтеп биреп булмый торган сөенеч тула: чәчәкле-гөлле яз җитүгә шулай куана җан.

Кем җиләкле җәйләрне сагынып яши, ә мин озын кыштан соң яраннарның бөреләре бүртә башлаган чагын яратарак төшәм. Талымсыз, ашлау-сугарудан да битәр яратуга мохтаҗ сыман алар. Талыккан җылымса су белән чамалап кына сугарсаң, агы, алы, куе кызыл, алсу-шәмәхә, ахак, мәрҗән төсендәгеләре иртә яздан башлап озын көзләрдә дә шау чәчкәдә утыра. Нигәдер татар гөле булып тоела ул миңа, сокланып караганны сизә. Ә гөлсез өй ятим сыман. Табиблар йокы бүлмәсендә яран үстерүне хуплый, яфрагы тынычландыру, микробларны юк итү сәләтенә ия матдә, эфир майлары бүлеп чыгара дип исәпли, имеш.

Авылдан килгән гөл тамырыннан үрчегән яшь үсентеләр чәчкәгә бөреләнә. Газиз әнкәмне һәрдаим искә төшереп тора алар да. Ни аяныч, тормышны, кешеләрне үлеп ярата торган нечкә күңелле әнкәйнең гомер йомгагы иртәрәк сүтелде. Шунысы гаҗәп, бу дөньяда сагыш белән шатлык янәшә йөри. Ходаның хикмәте, оныгым Хәйдәрнең дә туган көне 10 августта. Аңа 10 яшь! Бәхете, тәүфыйгы белән үссен, дип телибез.

Сагынганда кайтып керергә туган нигез исән. Энем Чаллыда, фатирларында кыш чыгуга, ашкынып гаиләсе белән җәйгә авылга кайта. Йорт-җирне карап, тәртиптә тоталар. Өлгер-җитез, уңган киленебез эшсез утыруны белми. Тәртип, чисталык сөя. Бакчадагы җиләк, чия-карлыганнар гынамы, тиз өлгерә, мул уңыш бирә торган кыяр, помидор, борыч та аның кул җылысын тоеп, иртә яздан кара көзгәчә күкрәп үсә, җимешләре мул була. Миһербанлы, туганлыклы якыннарың булганга шөкер итәсең. Юаныч бу. Мәрхүмнәр рухына Коръән багышлатып, аш уздырырга ниятләүләренә җир-күк сөенү ләззәте тагын! Туганнар җыелып, бәхетле балачак узган йорттан күңелләргә нур алып килү яшәешнең кадерле мизгелләре ич. Тормыш дәвам итә. Рәхмәт дими, ни дисең!

Роза МУЛЛАНУРОВА

40 нчы биттәге фотода: әткәй, әнкәй, сеңлем Рамилә.

Фирдәвес
ИСМӘГЫЙЛЕВА

Дәү әнигә минем белән җиңел булмагандыр... «Бик җәфаладың син мине...» – дип әйтә иде ул. Шуларның әҗерен кайтарып бетерә алдыммы? Белмим. Һәрхәлдә, күңелен күрергә тырыштым...

САГЫНМАГАН ЧАК ЮК...

Кулына «кара» кәгазь алганда дәү әнием Камәрия Шәрәфулла кызы Ибраһимова 36 яшьтә генә була. Биш бала белән тол кала ул. Аңа тигез тормышлы булып яшәргә каһәр суккан сугыш комачаулый.

Авылдан берничә гаилә, бергә җыелышып, анда тормыш җиңелрәк дип, Сталинград өлкәсенең кавын-карбыз үстерүче Никольское совхозына килеп урнашалар гына, сугыш башлана. Ирләрен сугышка озатып, хатыннар кире туган якларына кузгала. Бик күп михнәтләр күреп, пароход белән Кама Тамагына кайталар. Инде чит кешеләр кереп урнашкан өенә кайтып кергәндә ничек сабырлыклары җитте икән дәү әнинең? 3 яшьлек сабые юлда салкын тидереп гүр иясе булгач, ничек түзгәндер? Хатларында ире: «Балаларны сакла», – дисә дә, тагын бер улы авырып дөнья куйганда ничек чыдады икән? Колхоз эшеннән бер көн дә калмыйча ачлы-туклы килеш хезмәт куйганда кайдан көчләр алды икән? Ире турында кайгылы хәбәр алгач, яшәү ямен югалтмаслык сабырлыгы ничек җитте икән?

Ниһаять, сугыш беткәч, исән калганнар илгә кайта башлагач, дәү әниниләр кичергәндер? Бәлки, кайтыр әле, дип өмет иткәндер? Ә бабам Хәсәнҗан Хәйрулла улы кайтмый... Ленинград блокадасын өзү өчен барган сугышта башын салган бабамның исеме генә кайта... Аның өч газизе дә ятим булып үсә... Алар арасында – әнием Әлфия дә...

Балаларын аякка бастырып, аларны кеше иткәндә кайлардан көч-куәт тапты икән сыңар канатлы хатын? Инде үстеләр дигәндә генә, берсен – ФЗОга, икенчесен вербовка белән Казанга җибәргәч, йөрәге парә-парә килде микән? Башкалардан ким-хур булмыйча ялгыз тормыш алып барулары җиңел булмагандыр, беләм, ләкин аның зарланганын, сукранганын беркайчан да ишетмәдем. Язмышына буйсынып, тормыш мәшәкатен ялгызы гына тарткан, балаларын йөзенә кызыллык китермәслек тәүфыйклы итеп үстергән. Ачы толлык әҗеренә тап төшерми яшәгән – үзәге нык булган. Хәсәнен дә көтә белеп көтте ул... Ә без – оныкларына аны исән кебек, бабагыз, дип искә ала иде гел.

Җәйләрен мине дәү әни янына авылга кайтаралар иде. Тәрәзә төбендәге хуш ис тараткан исле гөл чәчәкләре, өй алдындагы бакчасында сирень куагы, куе кызыл төстәге купшы дәлия чәчәкләре күзне ир-



кәләп шаулап үскәне хәтердә... Әни игезәк энем белән сеңлемне тапкач, дәү әни янында кышладым да әле. Минем өчен ул әни кебек бик кадерле, якын кеше булды. Авылдан киткәндә елашып аерылышабыз... «Син киткәч, бакча ягына чыгып, исемең белән дәшеп елап йөрим», – дип сөйләр иде.

Дәү әни яшьли ятим калып, үз көнен үзе күрергә өйрәнгән, бервакытта да кешегә салынып яшәмәде, тырыш, тәвәккәл, җитез – эшләгән эшен яратып, җиренә җиткереп башкарды. Мине дә кул арасына керергә өйрәтте, төрле йомышларга йөртте. Үзе бер дә тик тормаган кебек, эшләгәнне бик яратты. Әле бер эшне эшләп бетермисең, ул инде икенчесен әзерләп куйган була... Ә кичләрен мин кызыккан күзлек тартмасыннан күзлеген чыгара да гарәп хәрефләре белән язылган, битләре инде таралган китабын алып ярым пышылдап кына укый...

Тагын мин кызыккан кечерәк кенә сандыгыннан бала вакытларында вафат булган ике улының ясаган төсле рәсемнәрен алып күрсәтә... Үзе уйлап чыгарган гыйбрәтле әкиятләр, төрле хатирәләрен сөйли...

Олы тормыш юлына чыгарып җибәргән балаларын, кияү-киленнәрен, оныкларын сагынып яшәде дәү әни. Озаграк кайтмый торсалар: «Сөйләүләренә кадәр сагындым», – дип, олы киленен юксынды. Кияү-киленнәренә кадер-хөрмәт күрсәтә белде.

Шушы көннәрдә дәү әнинең бакыйлыкка күчкәненә утыз ел булды... Аны искә төшермәгән, сагынмаган чагыбыз юк... Зирәк, үзенчәлекле холыклы дәү әнине авылда әле минем яшьтәшләрем дә, әбиәңкә (кендек әби) дип искә алалар...



Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА

«СИН БӘХЕТКӘ ЛАЕК!»

1985 елның җәе. Аяк астында кинәт җир убылгандай булып истә калган җәй... Көтмәгәндә ире бакыйлыкка күчә. Ыңгырашып, зарланып йөрмәгән, бер мәртәбә дә йөрәген тотып үзенә аерым игътибар таләп итмәгән өрлектәй ир инфаркт кичерә. Мөслим музыка мәктәбен җитәкләгән Марсель Нәҗмиевкә кырык та тулмаган әле. Тол калган Линага да...

Ирем янында калам...

Олысы башлангыч класска, икенчесе балалар бакчасына йөрүче улларын кочаклап, җиде юл чатында кала ул. Нишләргә? Матур итеп тормыш башлап җибәргән Мөслимдә төпләнергәме, әллә иренең әтиәнисе янына Чалманаратка күчәргәме? Марселенә булган кайнар мәхәббәте, иренең әти-әнисенә булган тирән ихтирамы «Чалманарат» дип пышылдый аңа. Биредә ул үзен ире янында тояр, көн саен барып каберен яд итәр, газиз улларын югалтудан сыгылып төшкән кайнана белән кайнатасына терәк булыр... Тик дистә еллар эшләү дәвамында Мөслим мәктәпләре тормышын биш бармагы кебек үзләштергән, һәрнәрсәне иҗади башкаручы хезмәткәренең уй-фикерен укыгандай, район мәгариф бүлеге мөдире үзе килеп җитә Чалманаратка. Билгеле инде, авыр югалту хәсрәтен уртаклашырга һәм... тизрәк эшенә чыгуын үтенергә. Чөнки тиздән яңа уку елы, укытучыларның август конференциясе...

Әмма, әмма... Балачактан кешелеклелек дигән олы гамь салынган Нәүәп кызының яралы йөрәгендә, беренче чиратта, үзен түгел, һаман да иренең кадерлеләрен кайгырту хисе өстенлек итә. Документларын алып Чалманаратка кайту нияте белән барган Лина Нәҗмиеваны, ахыр чиктә, Мөслим райкомының беренче секретаре үзе чакырып сөйләшә. Үгетләүләр, ышаныч-өметләр, вәгъдәләр... Шулай итеп, Мөслим районының август конференциясе санаулы көннәр эчендә җиренә җиткереп әзерләнә. Тамаша залында меңләгән укытучы, президиумда төрле дәрәҗәдәге түрәләр, башкала кунаклары. Президиум уртасында – методик кабинет мөдире Лина Нәҗмиева. Конференцияне ике телдә дә камил әзерлек белән алып баруына, югалып калмыйча һәр сорауга зирәк акыл белән җавап бирүенә, парын югалткан җәйранныкыдай нәфис моңсулыгына теләктәшлек күрсәтүдән дә тыңлап утыручы мөгаллимәләрнең күзләренә яшь тула. Җитәкчелек исә бу көчле рухлы ханымда киләчәктә район мәгарифен җитәкләрлек куәт, өлгергән шәхес күрә.

Аллаһтан бирелгән һөнәр

Минзәлә педагогика училищесын тәмамлагач, юлламаны Актаныш районына бирәләр Лина Фәттаховага. Туган ягына. Ә анда Чалманарат мәктәбенә билгеләнә. Һәм уку елы башланып күпмедер вакыт үткәч, мәгариф бүлеге җитәкчесе үзе килеп, дәресләренә дә керә. Ахырдан, анализ ясап: «Классны тотасың... Материалны да балага барып җитәрлек итеп аңлатасың... Тик завроно мактады дип кәпрәймә!» – ди.

Борын күтәрү нәселләрендә юк аларның. Дәресләренең һәр минутын файдалы итеп уздыру, һәр укучысына төпле белем бирү уе белән яна ул. Төннәр буе дәрес программаларын төзи. Яңа теманы аңлатканнан соң, укучыларының нинди сораулар бирү ихтималын күз алдына китерә-китерә җаваплар әзерли, конспектлар яза. Ә балалар ихлас күңелле апаларын тиз таныйлар, үз итәләр.

– Әле менә шул укучыларымның мәктәп тәмамлавына кырык ел бүген, очрашуга чакырдылар. Алар бит минем беренче карлыгачларым! Беренче чыгарылыш классларым! Ике параллель бишенчедә илледән артык бала иде, – ди Лина Нәүәповна, «беренче» сүзенә басым ясап. Хәзер исә барыбыз да бер тирә яшьтә кебек. Аларны укыта башлаганда үзем дә бала гына идем ләбаса. Кыскасы, күрешүдән алган тәэсирләрне сөйләп кенә бетерерлек түгел, шигырь итеп ак кәгазьгә бушатсаң гына... – ди шигъри күңелле, үзем өчен генә дия-дия, җырлап торган шигырьләр иҗат итүче мөгаллимә.

«Мөгаллим, табиб, судья – Аллаһы Тәгаләнең үзеннән бирелгән һөнәрләр», – дигән бөек акыл иясе Сократ. Чынлап та, күңелеңдә ихлас ярату, гадел һәм чиста уй-омтылыш булмаса, кылган гамәлләреңнең бала күз яше, кеше рәнҗеше белән тәмамлануы да бик ихтимал бит. Бу өч һөнәрнең һәркайсы кеше язмышы, аның киләчәге белән бәйләнгән. Ә Лина Фәттахова һөнәрен вакытлы яки яшәү өчен акча табу шөгыле итеп түгел, бәлки, гомере буена тез чүгеп хезмәт итәргә тиешле вазыйфа буларак сайлаган. Әтисе Нәүәп Фәттаховтан, ерак әбисе Бибиданәдән,

нәсел-ыруындагы гыйлемдарлардан килгән әманәткә тап төшермәслек әзерлек белән. Шуңа күрә дә юлы гел үсештә аның: башлангыч класслар укытучысы; рус теле һәм әдәбияты укытучысы; уку-укыту, тәрбия эшләре мөдире; директор урынбасары; мәктәп директоры; район мәгариф бүлегенең методик кабинет җитәкчесе; район мәгариф бүлеге җитәкчесе. Ярты гасыр дәвамында Актаныш, Мөслим төбәкләрендә мәгариф өлкәсендәге бөтен баскычларны үтә ул. Нәтиҗә: Татарстанның атказанган укытучысы, РСФСРның халык мәгарифе отличнигы, мәгарифтәге казанышлары өчен күкрәк билгесе бүләкләре, күпсанлы Мактау кәгазьләре, Рәхмәт хатлары... Әмма арада иң зур бүләк – халык мәхәббәте! Лаеклы ялга чыгып, башка җирдә яшәсә дә, мөслимлеләрнең бүген дә үзенең коллегаларын онытмавы.

Мәгариф юлы шулай бит ул, мөгаллимлек итү изге эш саналса да, иң авыр хезмәтләрнең берсе исәпләнә. Ил, халык өчен башкарган эшләре өстенә, хатын-кызның дөньялыкта ул гына үти алган шәхси миссияләре дә бар бит әле: ак биләүгә төргән бала; гореф-гадәт, милли йола-кануннар сеңдерелгән гаилә учагы; ир хакы; кайнана-кайната хакы; килен булып төшкән нигез дәвамчысы...

Иң элек – тәрбия

Әтисе Нәүәп Фәттахов димәктән, Актанышта гына түгел, бөтен тирәюньдә беләләр бу педагогны. Сугышка кадәр үк Минзәлә педучилищесында гыйлем ала Нәүәп Фәттах улы Фәттахов. Киләчәктәге озын гомер юлында исә, үз сукмагыннан китеп, әлеге данлыклы уку йортында өч кызы укып, алга таба шушы юнәлештәге югары уку йортларын да тәмамлап, дәрәҗәле, тирән белемле мөгаллимнәр булуын күреп шатланачак ул. Хатыны Рәйсә Мирзасалих кызы белән, бер-берсенә кадер-хөрмәт илә сугарылган тату тормыш юлы үтеп, тырыш та, талантлы да биш бала үстерәчәк алар. Бер оядан өч: Татарстанның атказанган укытучысы, РСФСРның халык мәгарифе отличнигы, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министры үсеп чыгу – бу инде гаиләдәге тәрбиянең халык педагогикасына Каюм Насыйри, Риза Фәхретдиннәр тәгълиматына тиң булуын исбатлый торган күренеш. Халык педагогикасының, шәригать кушканнарның язылган да, язылмаган да кануннарына буйсынып яшәгәндә генә шулай буладыр, мөгаен: кешеләрне, тормышны ярату; мәгънә-мән белү; соклангыч дәрәҗәдәге туганлык хисләре, Ана кешегә игелекле мөнәсәбәт... Әнә бит, 100 яшенә якынлашып килүенә карамастан, бакча тутырып чәчәкләр, тәрәзә төпләрен тутырып гөлләр үстерүче, туып-үскән нигезләренең нуры булып яшәүче әниләрен бер көнгә дә ялгыз калдырмый алар. Ана исәнлеген күз карасыдай кайгыртып, нинди ераклыкта яшәүләренә карамастан, өзеклек тудырмыйча, һич авырыксынмыйча кайтып, әниләре янында яшәп китүләре – бу инде чишмәлеләр өчен генә түгел, бөтен татар дөньясына өлге итеп күрсәтерлек югары әхлак үрнәге. Ана мәхәббәте – баланы, бала мәхәббәте ананы яшәтә диюләре хактыр.

Бөтен җанын биреп эшләгәннәргә генә бала күңелендә һәйкәл куела.

«Киявемә килсәң, үкенмәссәң»

Ире үлгәннән соң, егерме ел ялгыз яшәп ике улын үстерә Лина. Һәр икесенә югары белем алу мөмкинлеге тудыра. Шул ук вакытта кайнана белән кайнатасын да ташламый, гел хәлләрен белешеп яши.

Еллар узып, чәчләренә чал керә башлаган бер көндә, тол, хатыны үлеп ялгыз калган ир-ат кулын сораганнан соң да озак уйлана ул. Кызларының ияле булуын теләгән ата-ана, якташлары Рафаил Хөсәеновны хуп күрәләр. Ә Линаның зирәк акылы, Чалманаратка кайтып, кайнанасы белән дә киңәшләшүне таләп итә. Киленен «кызым» гына дип йөрткән Нәҗибә ханым: «Син олы бәхеткә лаек. Фатихамны чын күңелемнән бирәм!» – ди, елый-елый Линаны кочагына алып. Никах укытасы гына калган кебек тә...

Тик күңел тынычлыгы өчен тагын нидер җитми кебек... Кулына Коръән алып дин гыйлеменә чумгач, әлеге фатихаларның нинди зур әһәмияткә ия булуын соңрак тагын да тирәнрәк аңлаячак Лина. Әлегә ул, эчке бер тоем белән, булачак иренең әбисе янына баруны да кирәк таба.

– Киявемә килсәң, үкенмәссең. Рафаил бик булдыклы кеше, – ди, үзеннән алда җиләктәй кызын җирләгән, кызының вафатына бер ел үтсә дә, һаман кияве янында оныкларына күз-колак булып яшәгән ана.

– Син дә китмә, монда кал, бергә яшик! – ди Лина, карт ананы юатып.

– Киң күңелеңә рәхмәт! Минем бит башка балаларым да бар, – ди ул, оныкларының язмышы өчен тынычланып.

Менә шулай, фатиха өстенә фатиха алып башлый алар тормышларын.

Һәр икесендә – икешәр егет: яшьләре буенча да барысы бер тирә. Хәзер исә аларга дүрт килен, ун оник өстәлгән. Иң куанычлысы – һәркайсы үз тиңен табып, гаиләләре белән аралашып, ярдәмләшеп, бер бөтен булып яшиләр.

– Яңа тормыш яңа сулыш таләп итте шикелле, – ди Лина, нурлы күзләреннән якты бөркеп. Бер яшьлек чагында ук Бибидановы әбисенең күңеленә таслап сала башлаган догалары, биш вакыт намазын калдырмаган әнисенең шәхси үрнәге – Коръән-Кәрим серләрен тирәнрәк өйрәнергә өнди аны. Калын дәфтәр ачып, мәрҗән белән чигү чиккән кебек, һәр хәрефен, һәр аятен хасиятләп язып, гарәп имлясын өйрәнә. Гыйлемле остазбикәләрдән белем ала. Һәм... Әтисе ягыннан да, әнисе ягыннан да тирән тамырлардан агып килгән мөгаллимлек дәрте тагын кабына. Башкаларның да күңелен иман нуры белән балкыту ниятеннән дәресләр бирә башлый. Бүген исә үзләре кулларына Коръән алып, гөрләтеп укый алырлык берничә дистә шәкерте бар аның!

Илгә ябырылган олы кайгы – миллионнарча корбаннар биргән сугыш афәте без – балалар өчен дә зур сынау, балачагыбызны урлаган, бик күпләребезне ятим иткән кара көннәр булып йөрәккә уелып калган. Безнең чор баласы авыр физик хезмәт белән иза чигүләрдән тыш, сәяси яктан кыерсытылу газапларын да башыннан уздырды шул. Искә төшереп, күз алдына китерсәң, җаннар телгәләнә. Ләкин без барысына түздек...



Фәһимә ГЫЙЛЬМАНОВА

Әтиләрен сугышка озатканда, Рәзинә апага – 14, Расих абыйга 11 яшь булса, әнием Суфия әле 2 яшен генә тутырган кечкенә кыз булып кала. Аларның истәлекләрен күп тапкырлар тыңлагангадыр, сугыш чоры балаларының башыннан кичкәннәре, әтиләре, ягъни Мирзасалих бабабызның сугышта күргәннәре кинодагы кебек күз алдымда җанлана. Бабам истәлеге булган пиджак әле һаман кием шкафында эленеп тора. Ул әле дә бабам җылысын саклыйдыр кебек. Орден-медальләр һәм значоклар пөхтә итеп тагылган. Һәрберсенең үз тарихы. Бабамның күргәннәре дә, мәрхүм әбекәй әйтмешли, үзе «бер китап язарлык».



ҮЗЕ БЕР КИТАП ЯЗАРЛЫК

Рәзинә апа аеруча зиһенле. «Әткәйне, башка авылдашлар белән бергә, сугышка озатыбыз... 1941 елның кояшлы 25 август иртәсе аермачык күз алдымда. Әнкәй кечкенә Суфияны күтәргән, без энем Расих белән әле әткәйгә сырпаланабыз, әле атын сыйпыйбыз. Расих ни уйлагандыр, мин эчемнән генә күк атка ялварам, әткәйне исән-сау алып кайт берүк, дим. Башта Бөгелмәгә җибәрәләр, аннан поездда – фронтка, диделәр. Әткәй атында Мәлләтамактан Мөслимгә таба кузгалып киткәндә елый башладым. Күздән югалганчы карап калдык аны», – дип искә төшерә ул. Мирзасалих Фәррах улы Мостафин 1901 елның 27 июлендә Мөслим районы Мәлләтамак авылында дөньяга килгән. Хәдичә әби белән Фәррах бабайның 18 балалары туган, 9 ы кечкенә чакта ук вафат булган, калганнарының да бары өчесенә генә балалар үстереп, оныклар сөеп яшәргә насыйп булган.

Әтисе үлгәндә, бабай 9 яшьтә кала. Шуңа үсмер чактан ук җигелеп

эшләргә туры килә аңа. Басудан кайтырлык хәле калмагач, шунда гына кунып кала торган була. «Аякка ат дилбегәсен урап ята идем. Төнлә бүреләр килсә, ат пошкыра, һәм мин уянам», – дип сөйли иде ул.

Бабам 1919 елны Кызыл Армиягә алына, һәм туган авылына 1926 елда гына өйләнеп кайта. Гражданнар сугышында катнаша ул, бу сугышта аның ике ир туганы үлеп кала. Вәҗетдин исемлесенең аклар тарафыннан кылыч белән туракланып үтерелгәнен сөйләгәч, Хәдичә әбекәй: «Ярый әле үзе шәһит киткән, ә шулай кеше җанын кыеп йөрсә,ниләр эшләр иде?» – дип юанган.

1926 елда бабай Мөслим кызы Бибизәйнәп белән тормыш корып җибәрә. Кызы, улы туа. Эшләгән кеше ачка интекми. Тик XX гасыр кешеләренә бик нык үзгәрешләр кичерергә туры килә шул.

Колхозлашу еллары... Бабам беренче көннән үк коллектив хуҗалыкка керә. Тик нахак гаеп ягылып, репрессияләнә, тормышы таркатыла, үзен төрмәгә җибәрәләр. Күкрәк баласы булган Расих абыйның баш астындагы мендәренә хәтле алып чыгып китәләр. «Шап итеп башының сәкегә төшкәне гел күз алдымда тора», – дип искә ала бу вакытларны Рәзинә апа. Ул да сабый гына була югыйсә. «Төн уртасында да сорау алырга чакыралар иде әнкәй белән әбекәйне. Безне дә уятып алып баралар, кайда калдырсыннар инде. Сорау алучы ачуланып кычкырганда, без мич артында калтырап тора идек. Безне куылган мулланың аскы өенә кертеп тутырдылар. Бала киемнәренә кадәр талап, сатарга алып чыгып киттеләр. Әткәй төрмәдән чыккач, үз ихатабызда яшәргә рөхсәт булды. Бозау бирделәр. Землянка казып, куыш ясады әткәй, түбәсен камыштан көлтә үреп япты. Идән таштан иде. Иске авыл тавыннан ак таш алып кайтып яндырып, төеп, шуны идән итеп җәйде. И-и башкаларның агач идәненә кызыга идем инде!» – дип сөйли Рәзинә апа. (Бары 2002 елда гына, бик күп тапкыр тиешле органнарга мөрәҗәгать иткәннән соң, бабайның акланувы турында хат килә балаларына.)

Рәзинә белән Расих иртәдән кичке караңгыга кадәр колхоз эшенә йөриләр, басу-кырдан кайтып кермиләр.


Кызлары Суфия – минем әнкәй туа. Тик тыныч кына яшәргә язмаган шул. Сугыш башлана. Мостафин Мирзасалих Мәскәү яны сугышларына эләгә. Беренче тапкыр дошман белән күзгә-күз алар шунда очраша... Рәзинә апа сугыш елларында үсмер кыз була инде. Ул сугыш чоры хатирәләрен барлавын дәвам итә. «Өйдә әниең – кечкенә Суфия да бар бит әле. Берсендә ул землянкада йоклап ятканда, төнлә ырылдашкан песиләрдән куркып уянып, елый башлады. Без энем белән аны уртабызга алып, кочаклап, тынычландырып йокладык. Әткәйдән хат килү бәйрәмгә әйләнә иде. Туган илебездән фашистларны куа-куа, ул Украинага килеп җитә, Белоруссия, Польшаны азат итүдә катнаша. Ә Бөек Җиңү көнен Берлинны узып китеп каршылый. Бер хатында ул:

Күк аткаем бар бит әле
Висла суын кичәргә.
Ходай насыйп иткән микән
Мәллә суын эчәргә, – дип язып җибәргән. Мәллә елгасы безнең аяк очында гына анысы. Ә Висла... Географиядән беләм инде, Польша җирләре буйлап ага. Безнең әткәй айгыры белән бик ерак җирләрдә фашистларны куа, дип аңлатам энем белән сеңлемә. Расихның да әткәй кебек буласы килә. Колхоз атларын карый. Ләкин аны, кулак баласы дип, гел кагалар иде. Урылган җирдә колыннар уйнап, көлтәләрне чуалдырып бетергәч, урак уручы апалар: «Атлар янына кертчәле шуларны», – диләр икән Расихка. Ә бригадир һаман куып чыгарырга куша икән. «Сүзне тыңламыйсың, малай!» – дип, ат дугасын Расих өстенә атып бәргән. Елап кайтып керде бала... Шундый кансыз кешеләр дә бар иде. Сыер, сарыклар, казлар булгач, ачка интекмәдек. Тал кайрысын кырып бәрәннәргә ашаттык, болында печән әзерләдек. Әткәйгә хат язганда менә шуларны да әйтә идек. Суфия да үсте әкренләп. Мин дә хат язам әткәйгә дип, безнең тирәдә кайнашты. «Песи балалады, казлар ун күкәй салды, сарык бәтиләре ап-ак, мин алар белән уйныйм, дип язам», – ди. Сарык йонын язып, егерләп, җылы кофталар, гамашлар, җылы шәлләр бәйли идек. Челтәрләп бәйләгән шәлләремне дус кызларым да матур дип мактады. Чыра яндырып йә ай яктысында тәрәзә төбенә утырып, фронт өчен оекбаш, бияләйләр бәйләдек.

«Ярый әле сез тынычта, шуңа сөенәм. Немецлар чигенгәндә авыл кешеләрен яндырып киткән, сөякләре таралып ята. Балаларны коега салып киткәннәр, дип яза әткәй хатларында...»

Бабам дүрт тапкыр каты яралана. Госпитальдә дәвалангач, тагын ут эченә – сугыш кырына китә. «Фашист тимере» күп иде аның тәнендә. Снаряд кыйпылчыкларын кечкенә чакта без тотып-тотып карый идек.

Бабай хатирәләре безгә бәләкәй чактан ук таныш булса да, еллар узгач, Рәзинә апа, әнкәй сөйләгәннәр буенча алар тагын да тәэсирлерәк кабул ителә. «Әткәй каты сугышлар



■ Мирзасалих бабам колхозда ат караучы булган. Сугышка да күк атына атланып киткән. 1945 ел.

Сугыш чоры балалары булган әнкәйгә, Рәзинә апага, Расих абыйга тиешле игътибар нигә вакытында күрсәтелмәде?..



Рәзинә белән Суфия. 1954 ел.

вакытында чолганышта калгач, яралы капитанны күреп ала. «Документларны ал да ат мине», – дип ялвара икән, бер җепкә тезелгәндәй тигез рәтләр белән килүче фашистларга ымлап. Әткәй плащ-палаткасына аңын югалткан капитанны салып, агачлар арасына сөйрәп китә. Сазлы урынга кереп, камыш арасында да качып яталар. Шактый сөйрәп баргач, үзебезнең солдатлар очрый. Яралы сугышчыны санчастька илтәләр. Аңына килгәч, капитан үзен коткаручыны кочаклап елый. Бу батырлыгы өчен әткәй Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Немец белән бергә-бер очрашырга да туры килә аңа. Германия җирендә була бу хәл. Сугыш беткән, тик һаман да атышлар дәвам итә әле. Гамьсез булырга ярамый. Тирәюньне күзәтеп кенә торырга кирәк. Әткәй агач башында бер немецны күреп ала. Янына бара, шулчак немец ишарәләр белән нидер аңлата башлый. Күптән күреп торуын, тик аңа атмавын, инде үзенең дә исән каласы килүен, өйдә кечкенә балалары булуын сөйли ул. Кулын җирдән өч төрле зурлыкта күтәреп, үлсәм, берсеннән-берсе кечкенә өч балам ятим кала, дип аңлатмакчы була икән. «Атмадым, кулым бармады, сугышка ул үзе теләп килмәгән бит инде. Без немецлар белән түгел, ә фашистларга каршы сугыштык», – дип сөйләгән иде әткәй. Әткәй дә, каршысында басып торган немец та икесе дә гап-гади солдат булган...»

Рәзинә апа шулай сөйли. Ул әле 1944 елда Мөслим районының «Күмәк хуҗалык» газетасында әтиләре, минем бабам Мостафин Мирзасалих турында подразделение политругы Булатов язган мәкаләне дә искә төшерә. Безнең өчен зур вакыйга булды, горурландык әткәй белән, ди.

Бабамның орден-медальләрен кулларыма алам. Җиңүнең күпме кан коюлар хисабына булганын дәлилләүче алар: «I дәрәҗә Ватан сугышы», «II дәрәҗә Ватан сугышы», Кызыл Йолдыз орденнары, ике «Батырлык өчен», «Мәскәүне саклаган өчен», «Варшаваны азат иткән өчен», «Берлинны алган өчен», «1941–1945 елларда Бөек Ватан сугышында Германияне җиңү өчен» һәм юбилей медальләре, командованиенең 12 Рәхмәт хаты, «Отличный артиллерист», «Гвардия» билгеләре... Сугыш чоры документларын актарам һәм андагы төгәллеккә таң калам. Бабамның һәр баскан эзе «Красноармейская книжка»да исәпкә алып барылган. Кораллары, кием-салымы, бүләкләре – барысы да язылган, имзасы, печате куелган. Төсләре дә уңмаган диярлек. Документлар арасында дүрткә бөкләнгән һәм бераз таушалганрак бер кәгазь сакланган. 1944 елның 16 декабрендә язылган 366 нчы номерлы белешмә Мостафина Зәйнәп исеменә килгән. Гвардия ефрейторы Мостафин Мирзасалих Фәрраховичның шушы чорга кадәр алган орден-медальләре саналган һәм льготалардан файдалану мөмкинлеге булуын аңлаткан бу хатка Сәмигулин һәм Стрелоговлар имза куйган. Бу кәгазь кисәге күңелемне нечкәртте. Ай-һай, кирәкле урыннарга күрсәтелде микән соң ул?! Исәнме-юкмы диеп, ирен сугыштан көтүче, фронт өчен көнтөн хезмәт куючы Зәйнәп әбием берәр генә тапкыр булса да файдаланды микән аннан? Инде тормышлар арулангач та, сугышта катнашучыларга тиешле 5 кубометр утынны да алып кайта алмыйча тилмергәндә, ни өчен бу кәгазьләрнең ярдәме булмады соң?..

Бик күпләрнең язмышы охшаш булган ул елларда. Алар барысы да Туган ил өчен көрәшкән, Җиңүне якынайткан: ирләр – яу кырында, хатын-кызлар, сугыш чоры балалары – тылда, алны-ялны белми эшләү бәрабәренә. Бүген әнкәйгә – 81, Рәзинә апага 93 яшь. Сугыш елларында чабата үреп, атлар карап, колхоз эшендә зурлар кебек эшләп йөргән Расих абыебыз инде арабызда күптән юк... Ә алар минем өчен һаман шул үсмер балалар сыман. Әткәләренең тизрәк сугыштан кайтуын тилмереп көтүче, әнкәләренә һәрдаим ярдәм итәргә атлыгып торучы эшчән, тырыш, тыңлаучан беркатлы авыл балалары булган алар.

Мөслим районы,
Югары Табын авылы.

46 нчы биттәге фотода: Рәзинә Закирова.



ХЫЯНӘТМЕ, ФЛИРТМЫ?


Гаилә корганыбызга 15 еллап. Моңарчы тату гына гомер иттек. Ләкин соңгы araларда ирем нык үзгәрде. Элек телефонны сөйләшер өчен генә тоткан кеше, хәзер аны кулыннан да төшерми. Мөнәсәбәтләрдә дә ниндидер салкынлык барын тоям. Балаларга да игътибары кимеде. Беркөнне үзе сизмәгәндә генә телефонын караган идем, бер хатын-кыз белән язышкан «смс»ларына юлыктым. Ул хатынны ир-ат исеме белән язып куйган. Яшь егет белән кыз кебек, шаярышып, тегесен-монысын язышканнар, мәхәббәткә дә ишарә бар кебек. Моны белгәч, миңа шок булды. Бу хакта әлегә иремә белдермәдем, чөнки гаиләне таркатудан бик куркам. Хәзер миңа нишләргә? Аның үзе белән сөйләшергәме, әллә, белмәгәнгә сабышып, иремнең мәхәббәтен кабат яулар өчен тырышыргамы? Нинди киңәш бирер идегез?

Исемем редакция өчен генә.
Сарман районы.



Гүзәл СӘГЫЙТОВА,
Г. Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры директоры:

– Мин – үзем максималист. Миңа йә бар, йә юк, ниндидер урталык була алмый кебек. Шуңа да иң башта яхшылап сөйләшер идем. Аннары нәрсә булса, шул була инде. Болай билгесезлектә дә яшәве кыен бит. Бәлки, бу гап-гади бер флирт кынадыр. Әгәр чынлап та ул ир башка хатын-кызга гашыйк булган, аны ярата икән, бу очракта үзеңне дә, иреңне дә алдап яшәүдән мәгънә юк. Әлегә фикерем шундый, чөнки гаилә тәҗрибәм нибары 4 кенә еллык, бәлки, 15 ел бергә яшәгәч, башкача күзаллау булыр. Чөнки балалар бар, уртак милек бар... Әмма хәзерге акылым белән мондый хәлне кабул итә алмас идем кебек. Хыянәтне хәтта уйларымда гына да күзаллаудан куркам. Арага хыянәт керсә, элеккеге хисләрне, җылылыкны ничек саклап калырга? Бу мөмкинме? Мөмкин түгелдер...



Рөстәм ГАЙЗУЛЛИН,
Татарстанның атказанган артисты:

– Бу бик четерекле, актуаль проблема. Әлеге хатны укыганда хәтта үземне таныдым дип әйтергә була. Хыянәт ягыннан әйтмим, өйгә кайткач та телефоннан чыга алмауны күздә тотуым. Бер якны да аклыйсым килми, ләкин сорау туа: ул ир-ат ни өчен читтән флирт, шаяру эзли соң? Бәлки, аңа өйдә нәкъ менә шаяру, җылы сүз җитмидер. Бәлки, балалар тугач, хатын-кызның аңа игътибары кимеп, ул икенче планга күчкәндер... Ир-ат – бала кебек, дип юкка гына әйтмиләр, аңа да гел игътибар кирәк, хатынының янында балкып торуын тели ул. Ә менә бер әйбер мине нык сагайтты: ир-ат сизмәгәндә телефонын карау бик куркыныч әйбер. Ир-атның кесәсен актару, хатын-кызның сумкасында казыну – иң начар күренеш. Минемчә, ниндидер шик-шөбһәләр белән яшәгәнче, уртага салып сөйләшеп, мөнәсәбәтләргә ачыклык кертергә кирәк. Бу ханымга да киңәшем шул: шикне эчтә саклап йөртергә кирәкми. Араларның тагын да суынуына гына китерә ул. Гаиләдә мөнәсәбәтләрне мондый дәрәҗәгә китереп җиткермәскә, ә бер-береңә игътибарлырак булырга тырышырга кирәктер. Гаилә учагы да гел утын өстәп торганны сорый. Мин бу гаиләгә уңыш һәм бәхет телим.

Белгеч фикере



Ләлә
БӘҺРАМШИНА,
психолог

– Гаилә өч нигезгә: социаль, эмоциональ һәм интим нигезгә корыла. Хаттан аңлашылганча, бу гаиләдә эмоцияләр кытлыгы бар. Ир кеше ул кытлыкны чит хатын-кыз хисабына тутырмакчы. Бу әле хыянәт түгел, бәлки, шул дефицитны тулыландыруга омтылыш кына. Нигә килеп чыга соң ул кытлык? Күрәсең, хатын-кыз үзен балаларына, хуҗалык мәшәкатьләренә ныграк багышлагандыр. Кайчандыр шат күңелле, дәртле ханымнан сүлпән, чәүчәләк хатын-кызга әверелгәндер. Хатын-кыз иң элек үзенең хатын-кыз булуын беркайчан да онытырга тиеш түгел. Үзенә багышлаган вакыт һәм чыгымнар аңа һәрчак яхшы кәеф булып әйләнеп кайта. Без гаилә учагы дип сөйлибез. Ул учакның җылысы хатын-кызның рухи халәтенә бәйле. Бәхетле хатын-кыз янында башкалар да үзен бәхетле хис итә.



Аның «әни» дип дәшә алыр кешесе берәү генә түгел, ә җидәү! Әйе, «Татарстан–Яңа гасыр» телевидениесе журналисты Алсу БИЛДАНОВАның язмышы үзгә. Яшь кенә булса да, сынауларны байтак кичергән. «Тапкан анамы, баккан анамы?» дигән сорауның җавабын да Алсу инде күптән белә. Ана назын, аның яратуын, җылысын, сиңа булган мөнәсәбәтен беркем кабатлый алмый. Беркем! Тормыш катлаулы: кайчак аның урынын алыштыручылар була, әлбәттә. Әмма йөрәктәге урынын түгел... Ачыктан-ачык сөйләшәбез.

Гөлнур САФИУЛЛИНА

«МИНЕМ КЕБЕК СИНЕ БЕРКЕМ ЯРАТМАС...»

– Әтисез калганда миңа 4 яшь иде. Әти белән әнинең бик иркә, бик кадерле бердәнбер кызчыклары булып үстем. Икәү генә яши башлагач та ятимлегемне сиздермәс өчен әни бик тырышты: аның мине яратуы диңгез генә түгел, океаннар кадәр иде... Ул гел киләчәгем турында уйлады: зуррак киемнәр алып куя, яңа савыт-саба җыя. «Сиңа... Үскәч... Кияүгә киткәндә бирнәңә булыр», – ди. 10 яшем тулгач мин әнине дә югалттым. Нибары 56 яшь иде аңа... Ул кичне, авырып киткәч, әни итәгенә утыртты да: «Кызым, сине миннән дә артык яратучы булмас... Әни бер генә ул!» – диде. Бүген йоклама әле, янымда тор, дип сорады. «Ашыгыч ярдәм» чакырттык, тик ул алар белән китүдән баш тартты. «Әтиең дә шулай китте дә, кире кайтмады. Сине калдырырга куркам», – диде. Иртән әнинең апасының кызы Халидә апа килде һәм без өчәү больницага киттек. Аны шунда ук реанимациягә салдылар. «Әни, йөрәгең авыртмыймы инде?» – дим. «Үтте, кызым, үтте», – дисә дә, авырта иде, билгеле... Көндезге сәгать икеләрдә кабат әни янына җыендык. Апаны реанимация бүлегенә керттеләр, мине юк. Көтәм һәм ишек аша аның үзәк өзгеч итеп елаганын ишетәм... Барысын да аңладым... Ярамый дисәләр дә, бәреп эчкә узам. Әнине эзләп табам. Тәрәзә буенда яткан икән. «Көзге куеп карадыгызмы, бәлки, ул сулыйдыр?» – дим. «Куйдык», – диләр. «Аның эчәсе килгән иде, су бирдегезме?» – дим...

Минем өчен ул көнне дөнья беткән кебек тоелды. Бөтен Галәмдә берүзем басып калдым кебек. Ялгызым... Апага елыйм: «Әни нигә мине үзе белән алмады? Аның белән китәргә телим. Яшисем килми... – дим. – Хәзер нишләрмен?» – дим. Әнине җирләгәч, барысы да безнең өйгә җыелды: әнинең туганнары, әтинекеләр, опека бүлеге хезмәткәрләре. Хәл итәргә тотындылар: ике бүлмәле фатирыбыз кемгә кала да, мин кая китәм... Басып торам. Үземне бәрәңге капчыгы кебек хис итеп. «Өебездән беркая да китәргә теләмим, монда калам», – дидем. Халидә апаларның Нурлатка килгән генә чаклары иде, әле торыр урыннары юк – ире, кызы белән безгә күчен деләр. Алар минем опекуннарым булды.

Бәхетле балачагым тәмамланды. Әнинең яратуын бернәрсә дә, беркем дә алыштыра алмавын бик тиз аңладым. Ә аннан... Әни үлгәнгә әле бер ай тирәсе генә иде. Бик авыр... Урамга уйнарга чыксам да, аз гына онытылып торам да, аннан тагын кинәт елый башлыйм. Беркөнне кызлар: «Нигә син һаман елыйсың? Ул бит синең әниең дә түгел иде», – диделәр. «Ничек инде түгел?» – дим аптырап. «Түгел! Алар сине детдомнан алганнар!» Ышанмадым... Апа белән абыйларга мунчага бардык ул көнне, шунда әкрен генә аңардан сорадым. «Әйе, дөрес, – диде апа. – Шәһит җизни белән Әлфия апа сине Чаллыдан барып алдылар. Тапкан әниең сине ташлап калдырган, аңа кирәкмәгәнсең». Абыйларда сер бирмәдем, сиздермәдем, аларның балалары белән уйнаган булдым. Ә икенче көнне, өйдә үзем генә калгач, башымны стенага бәрә-бәрә еладым. Ике кайгы шулай миңа берьюлы килде... Әнинең инде ничә көн төшемә кереп: «Кызым, елама, синең бит әниең үлмәде», – диюе һәм мине бер апа янына алып баруы юкка түгел икән. Барысы да исемә төште... Телевизордан Балалар йортлары күрсәтсәләр, әни гел: «Кызым, сине шулай ташлап калдырсалар, кемдер сине тәрбиягә алса, аннан үз әниең эзләп тапса, аларның кайсы якынрак булыр иде икән: тапканымы, үстергәнеме?» – дип сорый иде. «Нигә андый сораулар бирәсең, син бит мине беркайчан ташлап калдырмаячаксың?!» – дия идем. Балалар ниндидер бер конвейер буйлап киләләр, әти-әниләр аларны шуннан сайлап ала дип күз алдыма китерә идем кечкенә чакта. «Мин ул конвейердан сикереп төшеп калдым да, тәрәзә төбенә утырып сезне көттем. Бик озак көттем!» – дип сөйли идем аларга. Шулай дигәч, әни гел елый иде. Аның нигә елаганын аңламый гына идем.

Әни урынына калса да, апа миңа карата шактый кырыс булды. Үпкәм юк. Аның каравы, мин пешерергә өйрәндем, бала карарга, өйне җыештырырга... Урамда азып-тузып йөрмәдем. Безнең өйгә күчеп килгәндә Гөлинә кечкенә иде әле, 3-4 яшьтә генә. Аны бакчага илтәм, алып кайтам. Аннан дәресләр әзерләтә башладым. Ул минем өчен бүген дә сеңлем кебек якын... Берсендә, апа катырак сүз әйткән булгандыр инде, үз-үземә кул салырга уйладым. Төн иде. Кинәт каршыма бер күләгә килеп басты... Юрганны башымнан томалап яттым да, инде үпкәдән түгел, куркудан елыйм. Елый-елый йоклап киткәнмен. Төшемдә әнине күрәм: җитәкләп алды да: «Әйдә, үзем белән алып китәм», – ди. «Тукта әле, әни», – дип, дус кызларым янына йөгердем... Иртән апа, мәетләргә ияреп китәргә ярамый, дип аңлатты.

Биш елдан соң Фәрит абыйларга яшәргә күчендем. Сәбәпләре булды инде... Абыйның хатыны кешеләр янында: «Бу – безнең кыз!» – дия иде. Әни урынына калучыларның икенчесе шушы Әлфия апа... Нәфис

Кемгә охшаганмынмы? Әнигә! Миңа карыйлар да: «Әлфия апаның яшь чагы син!» – диләр...

сүз сөйләп, мәктәп сәхнәсеннән төшеп тормыйм – театр училищесына укырга керергә җыенам. Юрист булырга, үз хокукларымны якларга да телим. Аннан абый кинәт вафат булды... Мин Нурлаттан Чирмешән районы Яңа Кади авылына – әбиләргә торырга кайтып киттем. Әнинең Разия апасын кечкенәдән шулай «әби» дип йөрттем. Әнине алыштырган өченче кешем – әби. Ул миңа әле дә әни кебек... Иң рәхәт вакыт булды ул! Иртән торуыма чәй кайнаган, ботка пешкән. Мәктәптән кайтуыма аш өлгергән. Өйдә обойларын яңарттым – андый эшне яратам. «Кирәкми, мәшәкатьләнмә», – дисәләр дә, әби белән бабай бик сөенделәр.

Берьюлы ике югары белем алдым: мин журналист та, икътисадчы да. Үземә биргән сүзем бар иде... Ике группада да староста булдым.

Мәктәптә укыганда Илүсә исемле дус кызым бар иде. Минем әни үлгәч, ул гел: «Алсуны үзебезгә алыйк», – дия торган булган. Икебез дә Казанда укый башлагач, аның әнисе Гөлүсә апа: «Әйдә, ялларда безгә кайтып йөр», – дип чакырды. Алар мине бик якын итте – үз кызлары кебек күрде. Гөлүсә апа: «Минем кызларым!» – дип яратып эндәшә иде. Илүсәгә алган киемне миңа да алып кидерттеләр. Бер табыннан ашадык. Аңа фатир сатып алгач, миңа: «Син дә башка тулай торакта яшәмәячәксең, күчен», – диделәр. Фатир өчен бер тиен акча алмадылар. Илүсә минем өчен бертуганым кебек. Ә Гөлүсә апа – әнине алыштыручыларның берсе. «Сагындык үзеңне, хәлләрең ничек, балам?!» – дип гел шалтыратып тора ул миңа.

Инде күңелемдә 10 яшемнән бирле йөргән теләкне чынга ашырырга – мине дөньяга тудырган әнине табарга вакыт җиткән иде. Халидә апа теге чакта бу яңалыкны әйтүгә: «Бөтен документлар сандыкта, теләсәң карый аласың», – диде. Әни миңа серне 15–20 яшьләремдә генә ачарга җыенган. Юк, мин ул документларга кагыла алмадым, йөрәгем җитмәде... Беренче курста укыганда Нурлатка кайткач, тәвәккәлләп, фатирыбызга кердем. Инде анда беркем дә яшәми иде. Сандыкка карап берәр сәгать утырганмындыр... Менә ул кәгазь. «Мухаметханова Алсу Маратовна. Проспект Чулмана, «Дом малютки».

Чаллыга автобус белән барып төштем. Таксистлар кулымдагы адресны карадылар да: «Бу – шәһәрнең икенче башы», – диләр. Көз иде, яңгыр ява. Ят кешегә ачылып була бит ул – таксистка нигә килгәнемне сөйлим. Олы гына яшьтәге абзый иде: үзе тыңлый, үзе елый... Килеп туктагач: «Китмәгез, зинһар, бәлки, кермәм дә. Ишекне ачсам гына кузгалырсыз», – дим. «Борчылма, сеңлем, көтәм», – диде ул. Урамда яңгыр коя. Шакыргамы, юкмы? Бу ишекне ачсам, икенче тормыш башланачагын беләм. Таксига борылып карадым – кешене көттерәм бит... Ниһаять, шакыдым. «Мин – Алсу... Мине сездә калдырып киткән булганнар...» – дим. Ишекне ачучы ханым, документларга күз салуга: «1993 ел! Сине мин кабул иткән булганмын! Кер, башта чәй эчәбез!» – диде. Ә анда... балалар елаган тавыш. «Кермим, рәхмәт», – дим. Документлар Балалар йортында саклана икән, икенче бер хезмәткәрләре машина белән шунда алып китте. Төш вакытына туры килдек. Берәүләр бала алырга килгән, «Үзебез алып кайта алмыйбыз», – диләр. Әни белән әти искә төште... Гариза язганнан соң мине калдырган хатынның исем-фамилиясен әйттеләр. Галия исемле икән. Татар дип сөендем... «Юл аша гына опека бүлеге – адресын табарга алар ярдәм итәр», – диделәр. Кердем. Мин мөрәҗәгать иткән хезмәткәр: «Юк, сине турыдан-туры бу адрес буенча җибәрә алмыйм, куркам. Бәлки, алар наркомандыр, эчкечедер... Башта милициягә барыйк әле, ачыклыйк», – дип, эшен ташлап, мине милиция бүлегенә озата китте. Дөньяда яхшы кешеләр бар ул! Ике милиционер ханым минем белән бергә Галия апаны эзләп бардылар. Безгә ишекне яшь кенә бер хатын ачты. «Ул монда тормый. Без аның фатирын «снимать» итәбез», – диде. Юлдашларым: «Ниндирәк хатын ул?» – дип сорагач, өч баласы барлыгын әйтте. Өч баласы! Кинәт кәефем төште... Кире борылып кайтып та киткән булыр идем, янымдагы милиционер апалар туктатты. «Хәзер ул барыбер эштә, кич барырбыз», – диләр. Яңгыр астында йөреп, юешләнеп беткән идем – базарга кереп, миңа җылы носкилар сатып алдылар, чәй эчерттеләр, ашаттылар... Ниндидер документлар табып карадылар: «Сине тапканда әниеңә инде 26 яшь булган», – диләр.

Мин машинада утырып калдым, Галия апаларга алар икәү генә кереп китте. Өчәү әйләнеп чыктылар... «Алсу, бу – әниең», – диләр. «Исәнмесез...» – дим. «Исәнме, кызым...» – диде ул. Күзенә, йөзенә бер карыйм дип кенә килгән идем – карый алмадым, оялдым. Кешенең гаиләсе, балалары бар, ә мин аның тынычлыгын бозып, борчып йөрим... «Әйдә, өйгә керәбез. Мин сине бер калдырдым инде, башка калдырмыйм», – ди. Кердек... Бер ир-ат каршы алды, бер егет һәм бер кыз.

– Камил, таныш бул, бу – Маратның кызы, – диде Галия апа. – Динар белән алар бертуганнар. Алсу – минем кызым...

Ире белән язылышмыйча гына торган алар. Динар тугач, аралары бозылып, Марат башка хатынга чыгып киткән. Аннан кабат Галия апа янына кайткан.

– Мин икенчегә авырлы идем. Абортка акча сорадым. Ул: «Акчам юк, теләсәң нишлә», – дип, кабат теге хатыны янына китеп барды. Азартлы уеннар белән мавыкты. Әни шуңа яратмады да аны. Шәһәр малае, булдыксыз, диде. Тагын бала алып кайтсаң,

өчегезне дә куып чыгарам, диде. Әнидән куркып калдырдым сине... Торыр җирем дә, акчам да, эшем дә юк иде. Соңыннан барып эзләп карадым, «инде алдылар», диделәр... – дип сөйләде Галия апа. Без сүзсез генә тыңладык. Аннан Динар торды да, килеп мине кочаклап алды. Шунда кычкырып елый башладым. Бөтенебез елаштык. Камил абый да, Динар да, Алия дә... Камил абый, хатыны үлеп, ике бала белән калган – Галия апа шул балаларны үстерешкән.

Без хәзер аралашып, кунакка барышып яшибез. Бер ел буе алар мине Камил абыйның туганнарыннан яшерде – Алиянең дус кызы, диделәр. Камил абый шулай теләде: апалары алдында Галия апаны рәнҗетәсе килмәде. Мин каршы булмадым. Динар гына түгел, Камил абыйның улы белән кызы да миңа туган итеп карыйлар.

Галия апа белән атнага бер сөйләшеп торабыз. Берсендә ул миңа шалтыратты да: «Абыеңның хәбәре юкмы? Инде бер сәгать трубканы алмый», – диде. Шунда аңладым: ул мине ничек якын итсен инде, аның бит үз улы бар, алар көн саен сөйләшеп торалар. Бер сәгать кенә җавап бирмәгән, ә ул аны әнә инде эзли дә... Шуңа күрә үз урынымны беләм, зурракка өметләнмим. Көнләшмим дә. Мине дә әти-әнием шулай яратты – мин алар баласы.

Галия апага ничек эндәшергә дә белмим. «Апа» дияр идем, күңелен рәнҗетермен кебек. «Әни» дә дия алмыйм – үз әнием бар. Ә ул миңа «кызым» ди, сөйләшкән саен һаман гафу үтенә. Миңа хәтта уңайсыз да...

Бик күпләр: «Син аны ничек гафу итә алдың?» – дип сорыйлар. Хәтта туганнар арасында да аны кабул итеп бетерә алмаучылар, мине аңламаучылар бар. Ничек инде кичермим ди? Ул бит мине тугыз ай буе күтәргән, тудырган – гомер бүләк иткән. Бер көнлек дөньяда нигә үпкәләп яшим?! Тормышта кем ялгышмый?! Аңа карата күңелемдә беркайчан ачу булмады.

Әнине алыштырган кешеләремнең тагын берсе – кайнанам. Аны Аллаһы Тәгаләнең миңа бүләге дип саныйм.

Дус кызым Илүсә белән ирем Рәзил – туганнан туганнар. Илүсәнең әниләре – Гөлүсә апаларның мине ничек якын иткәнне сөйләдем инде. Без Рәзил белән бергә үстек дисәм дә була. Гөлүсә апаның әнисе Роза әбигә без дә Илүсә белән барабыз, Рәзил дә килә. Студент елларында да юлда гел бергә кайтыпкитеп йөрдек. Аның әти-әниләре дә мине үз кызлары кебек күрде. Нурлаттагы фатиремны сатып, Казанда яңаны алырга да Рәзилнең әтисе тәкъдим итте. Без әле ул чакта Рәзил белән очрашмый да идек. «Кияүгә чыкканчы үз фатирың булсын әле, алай ышанычлырак», – диделәр. Фатир эзләшергә Рәзилгә куштылар. Шулай без якынайдык та бугай... Фатирны алгач, булачак кайнанам: «Ә хәзер, Алсу, үзең генә яшәп кара әле. Гомер буе кеше өстендә булдың бит, азрак рәхәт күр», – диде.

Кыз сораган җиргә Камил абый белән Галия апаны да чакырдым. Мине әбидән сорадылар... Никах вакытында Галия апаны кая утыртыйк икән дип озак баш ваттым. Кияү белән кәләш янына әти-әниләре утыра бит. Тик әни урынын башкага бирәсем килмәде... Түрдә Рәзил белән без икәү һәм мулла гына утырды. Кайнанам балалар бакчасында минем тәрбиячем иде, ул әнине дә, әтине дә яхшы хәтерли. Туйда аларны искә төшерде. «Әлфия апа кызын миңа тапшырып калдырган», – диде. Кунакларның күзләре яшьләнде. Аннан Галия апа котлады. «Кызым, сиңа тиешле яратуымны, мәхәббәтемне бирә алмадым, кичер», – диде. Тагын елаштык...

Мәктәптә укыганда да, студент булгач та дус кызларымның, танышларның телефоны шалтыраганда анда «әни», «әнием», «мама», «мамочка» дигән язуларны күреп, ак көнләшү белән көнләшә идем. Их, минем дә телефонымда шундый язу чыксын иде дип тели идем. Бу инде мөмкин түгел кебек тоела иде. Әтиәниләре шалтыратканда дус кызларым җавап бирмәсә, аптырый идем. Үз бәхетләрен үзләре аңламыйлар. Менә мин күпме генә теләсәм дә, әни инде миңа шалтыратмаячак... Галия апа белән танышкач, бераз аралашкач, мин аның номерын телефоныма «мама Галия» дип язып куйдым. Сәер яңгырый, әмма беренче сүзе «мама» бит! Әни дип яза алмадым. Әни сүзе әни өчен генә инде ул...


Еллар үткәч, миңа да телефон номерлары арасында «әтием», «әнием» сүзләрен күрергә насыйп булды бит! Иремнең әти-әнисен кадерләп шулай яздым. Алар инде минекеләр дә... Без өйләнешкәч, кайнатам: «Алсу, син чит-ят түгел, үзебезнең кызыбыз. Менә – әниең, ул синең өчен әни дә булыр, дус кыз да. Тәүлекнең теләсә кайсы сәгатендә шалтырата аласың», – диде. Әнием кебек кайнана юктыр. Әле бу атнада Нурлатка аларга кайттык та, ул мине, машинасына утыртып кибеткә алып барып, тагын киендерде. Әни кебек үк... Ул да мине киендерергә ярата иде. Рәхмәтләремне ничек әйтергә белмичә, утырып еладым... Сәйдә тугач, алар башта атна саен безгә килеп йөрделәр. Баланы юындырып китәләр иде. «Барыгыз, икәү ял итеп кайтыгыз», – дип, безне берәр җиргә җибәрәләр... Оныкларын алар бик яраталар! Ә мин... мин Сәйдәне артык иркәләргә дә куркам. Яратуга, назга күмелеп үсәр дә, берәр нәрсә булса, аннары авырга туры килер дип уйлыйм. Кызымны беренче тапкыр кулыма алуга: «Минем белән нидер булса, аны кемнәр яратыр?» – дип уйладым. Бу куркуның урынсыз икәнен дә беләм, әмма әлегә үземне җиңә алмыйм...

Әти дигән кеше... Әйе, аның турында әле әйтмәдем. Ул Камил абый белән бергә эшли икән. «Алып барыйммы сине аның янына, таныштырыйммы?» – дип сорады Камил абый. Тик Галия апа аның хатыны көнче дигәч, баш тарттым. Кеше гаиләсен бозармын тагын... Бер кыз үстерәләр икән. Тагын бер кызы – мин дә барлыгын ул һаман да белми...

Редакциядән: мәгълүм сәбәпләр аркасында, кайбер исемнәр үзгәртелде.

PRESSA

«МӘХӘББӘТ АҢЛАШУ ЯШЬЛЕКТӘ ГЕНӘ КИЛЕШӘ...»



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

Илфат КАМАЛИЕВ,
Г. Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачылар театры актеры, режиссер,
Татарстанның халык артисты;
гаилә стажы – 17 ел;
балалары – Илүсә, Зөбәрҗәт.

1 – Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

Зифа, озын буйлы, чибәр хатын-кызга кайсы ир игътибар итми калыр икән?! Тормыш тәҗрибәсе туплагач, эчке матурлыгын да күрә башлыйсың. Хатын-кыз юморны аңласын иде ул. Үзем тиз гашыйк булучан. Романтик кешемен. Дүртенче сыйныфта ук беренче тапкыр мәхәббәт утында яна башладым. Баштарак кызларның портретларын ясап, сумкаларына сала идем. Аннан шигырьләр яздым. Армиядән соң гыйшкым төшкән кызларга җыр багышлап, гитарада уйнап җырлый идем. Егермеләп шундый җырым бар иде. Хатыныма да яздым, истә генә калмаган инде...

2 – Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

Аңлап бетермәүләрен, артык ышанучанлыкларын, кызып китүләрен... Кемгәдер гашыйк булуларына да күз йомам.

3 – Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

Режиссер буларак, бер нәрсәгә үпкәм бар: кайбер хатын-кызны кинода төшертәсең, спектакльдә уйнатасың, ә алар бераз гына популярлашып китүгә, боларны инде оныта. Интервью биргәндә дә сине түгел, башка режиссерны мактый. Нечкә күңелле кеше буларак, хөрмәт сүзләре көтәм бит инде. Болай кылануларына күңелем кайта. Бу – үзенә күрә бер хыянәт. Ә мин хыянәтне кичермим.

4 – Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

Бик кызык сорау бу! Аның икесен бергә кушсаң булмыймы икән?! Хатыным Энҗе – комфорт тудыручы. Илһамландыручылар – тирә-ягымдагы хатын-кызлар, спектакльдәге партнерлар. Дөрес, Энҗе белән дә партнерлар булып уйнаганыбыз бар. Димәк, ул да рухландыра. Үз рольләрен югары дәрәҗәдә башкарган артисткалар белән сәхнәдә дөньямны онытып уйныйм. Минем «хыянәтемә» Энҗе тыныч карый. Иҗат кешесе, бераз тилерәк булуымны белә. Алиһәләр – сәхнәдә уйнар өчен, яшәр өчен хуҗабикәләр кирәк.

5 – Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

Ничә еллар буе янәшәңдә булган, бер ятакны бүлешкән кеше ничек дус булмасын инде?! Мин Энҗегә бөтен нәрсәне сөйлим. Безне хәтта бер-берегезгә охшагансыз, диләр.

6 – Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

Мин бит бик иртә өйләндем. 32 яшьтә үк! *(Көлә.)* Энҗене театр училищесында беренче тапкыр күргәч үк гашыйк булдым, әмма ул мине яратмады. Армиягә барып кайттым. Укуны тәмамлап, театрга эшкә килдек. Өйләнәм дип костюмнар тектергән идем, яраткан кешем бар, дип риза булмады. «Син миңа үзең килеп ялыначаксың», – дидем. Аны онытам дип, Чаллы театрына киттем, әмма оныта алмадым. Хатлар яздым. Юк, башка кызлар белән йөрмәдем түгел, йөрдем. Инде монысына өйләнәм, дип, әти белән әнигә кызлар да алып кайтканым булды. Әмма Энҗе күңелдән китмәгәндер, берсе белән дә никахка кадәр барып җитә алмадык. Кире Яшьләр театрына кайттым. Әти белән әнине җирләгән чак, күңелем төшенкелектә. Яңа ел алдыннан үзе килде дә: «Җитте болай йөрергә, өйләнешик», – диде. «Бу сүзеңне күптән көттем», – дидем.

Озак та үтми өйләнештек. Хәзерге акылым белән Энҗенең миңа кияүгә чыкмавын аңлыйм. Яшь чакта бәйрәмнәр яраттым, йөремсәк идем. Ирек яраттым. Төпле түгелдер бу дип уйлагандыр... Аннары сәхнәдәге рольләрем аша тормыштагы Илфатны яраткандыр дип уйлыйм. Энҗе Энҗе инде ул!

7 – Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

Энҗене сеңлем кебек яраттым. Без гаиләдә малайлар гына идек. Әнидән гел сеңел сорадым. Бертуган сеңлемә охшатам мин аны. Элек мине әни караса, хәзер хатын карый. Энҗе әнинең вазыйфаларын алды.

8 – Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

Кайтып керүенә чәй, каһвә ясап бирергә. Ашарына пешереп торырга. Ваннага кертеп аркасын юарга. Ир хатынга әйләнергә тиеш. Башка юл юк... *(Көлә.)*

9 – Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

Гадәти хәл дип саныйм. Без бит роботлар түгел. Хис чыкмый калмый ул. Миңа гыйшкын белдерсәләр, үрә сикерер идем, уянып китәр идем. Бу бит иҗат итәргә үзенә күрә бер стимул.

10 – Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

Ир-ат никадәр әдәпсезрәк булса, хатын-кызлар аңа шулкадәр ныграк тартыла. Бу – минем күзәтүләрем һәм моңа аңлатма бирә алмыйм. Әлбәттә, тырыш ир-атлар җәлеп итәдер. Ир кешедә бу сыйфат бар икән, аның янында курыкмый яшәргә була дип уйлыйм.

11 – Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

Үземә түгел, рольләремә игътибар итсеннәр иде. Уйнавыгыз ошады, дип язган хатын-кызлар бик нык рухландыра иҗатта. Чынлап!

12 – Ир-ат белән хатын-кызның икесе ике Галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

Хатын-кыз белән аңлашып яшәмәсәң, дөнья алга бармый инде ул. Бер-беребезне аңламау кайчак ачуны китерә. Машина йөрткәндә хатын-кызларның уң белән сул якны, газ белән тормозны бутаулары гына ни тора. Соң бу алгоритм, икене икегә тапкырлагач, дүрт булган кебек, гап-гади югыйсә. Ни өчен бутауларын ир-ат акылым белән аңлап җиткермим? Энҗе: «Син ачуланасың да, мин каушыйм», – дип, мине сәбәпче итә. Гомумән, хатын-кызның башында үзе генә белгән дөньясы бар. Аны башкаларга күрсәтергә теләми, аңлашылмаучанлыклар шуннан килеп чыга да инде.

13 – Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез? Үзегезнең хаклы булуыгызны исбатларга тырышып карыйсызмы, әллә инде юл куясызмы?

Хаклы икәнемне расларга тырышам да, булмый икән, юл бирәм. Хатын-кыз белән сүз көрәштерүдән дә мәгънәсез эш юк. Хатын хаклы булса да, ачу килә бит кайчак. *(Көлә.)*

14 – Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым дип, диванда кырын ятып тора. Сез нишлисез инде? Кафега чыгып китәсез яки пиццага заказ бирәсез? Тиз генә үзегез берәр нәрсә пешерәсез?

Күпчелек вакытта эштән бергә кайтып керәбез дә, икәүләп пешерә башлыйбыз. Минем эш – бәрәңге әрчү. Энҗе бик арса, үзем пешерәм. Аннан соң хатын-кыз хәйләкәр дә бит әле ул. «Син тәмле пешерәсең», – дип юмалый башласа, ничек каршы киләсең?! Мин пешергән ашны бик ярата хатыным. Безнең белән бергә Энҗенең әнисе дә яши, әбиле өйдә ашарга булмый калмый инде ул.

15 – Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан. Бу сезнең ачуны китерәме? Китерә икән, бу хәл белән ничек көрәшәсез?

Ачу чыга инде. Машинага чыгып утырып, көтеп алҗып, чыгырымнан чыгар дәрәҗәгә җиткәнне сизгән Энҗе кайчак барган җиреннән борыла да башка тарафка китә. Артыннан барып утыртам. *(Көлә.)* Яратмыйм мин соңга калырга. Хатын-кызда сиземләү сәләте көчле бугай ул. Барасы җиргә Энҗе, ничек кенә булса да, вакытында килеп җитә. Гел аныңча була!

16 – Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?

Бүләкләр бирешеп яшибез дип әйтә алмыйм. Энҗедән миңа иң кадерле бүләге – ике кызыбыз. Быел авылда мунча салдык. Хатыным: «Бу миңа иң зур бүләгең», – диде. Нинди бүләк бирешү, мәхәббәт аңлаткан да бик сирәк. Яшь чакта килешә әле ул, хәзер инде мәхәббәт дуслыкка әйләнде. Бер-береңне тоеп, сиземләп, кайгыртып яшәү – өлгергән мәхәббәттер инде ул безнең. Шулай да хатын-кыз мәхәббәттә наз да көтә. Шуны да онытмасак иде.



Баллы тәм-томны бик яраткан балаларны «шикәр чире була, баллыны күп ашарга ярамый», дип куркыталар. Ләкин бу чирнең килеп чыгуында баллы ризык кына гаепле түгел, төп сәбәп эндокрин системасының дөрес эшләмәвендә. Республика балалар клиник хастаханәсенең Сәламәтлек үзәге мөдире, югары категорияле балалар табибы Гүзәл ЯРУЛЛИНА белән балаларда шикәр диабеты, аның сәбәпләре һәм профилактика чаралары турында сөйләшәбез.

ДИАБЕТ ХӨКЕМ ТҮГЕЛ

Шикәр диабеты балаларда сирәк очрый дисәк тә, кызганыч, элек уйланылганча сирәк күренеш түгел ул хәзер. Әлеге чир балаларда туганнан соң ук та башланырга мөмкин, ләкин күбрәк 6–13 яшьлекләрдә очрый. Бу исә аларның шушы яшьтә тиз үсүе белән аңлатыла. Шикәр чире инсулин җитмәү аркасында килеп чыга. Инсулин исә ашказаны асты бизендә эшләнүче махсус гормон. Аның төп вазыйфасы – кандагы төп энергия чыганагы булган глюкозаны – организмның күзәнәкләренә илтеп җиткерү. Инсулиннан башка глюкоза күзәнәккә үтеп керә алмый, кирәксез элемент булып канда саклана.

Шикәр диабеты ике төрле була. Беренче төр – инсулин җитәрлек булмаган очрак. Икенче төр булганда – шикәр диабеты вакытында организмда инсулин күләме җитәрлек, ләкин теге яки бу сәбәпләр аркасында аны организмдагы күзәнәкләр танымый.

Шикәр чире үзеннән-үзе юкка чыга торган авыру түгел. Аның беренчу төре күзәтелгәндә, организмга даими рәвештә инсулин кертеп тору сорала. Күләме һәр пациент өчен аерым билгеләнә. Тиешле контроль һәм дәва булганда, шикәр диабеты белән авыручы балалар сәламәт яшьтәшләре кебек үк, актив тормыш рәвеше алып бара алалар.

Билгеләре:

- сусау;
- авыз кибү;
- кече йомышка еш кысталу;
- бәвелнең күп бүленүе;
- баланың төнлә бәвел тотмавы;
- аппетиты яхшы булса да, баланың ябыгуы;
- баладан ацетон исе килү;
- гомуми хәлсезлек;
- тиз йончу;
- ярсучанлык;
- хәтернең начараюы;
- баш авырту һәм баш әйләнү.



Дәвалауның төп нигезләре:

- инсулинны үз вакытында һәм тиешле күләмдә кабул итү;
- кандагы шикәр күләмен гел тикшереп тору;
- даими табиб күзәтүендә булу;
- баланың туклануын контрольгә алу;
- ак он, шикәр кебек тиз үзләштерелүче углеводларны рационнан алу;
- күбрәк клетчаткага бай һәм аксымлы ризыклар белән туклану.





Куркыныч тудыручы факторлар:

- нәселдәнлек;
- баланың 4,5 килодан артыграк авырлык белән тууы һәм үсә төшкәч тә артык авырлык проблемасының дәвам итүе;
- ашказаны асты бизенең көйсезлеге;
- баланың йогышлы чирләр белән еш авыруы;
- көчле стресс.



Табиб киңәш итә:

- баланы йогышлы авырулардан мөмкин булганча саклау;
- туклану һәм физик активлык буенча табиб киңәшләрен төгәл үтәү;
- бала үзен начаррак хис итсә, табибка мөрәҗәгать итү;
- углевод алмашының лаборатор күрсәткечләрен контрольдә тоту.

БУ МӨҺИМ:

- шикәр чире белән авыручы бала олыларның даими күзәтүендә булырга тиеш;
- укучы балаларның класс җитәкчеләреннән баланың шикәр чире белән авыруын һәм аның ашау-эчүдәге үзенчәлекләрен, үз вакытында инсулин кабул итү мөһимлеген яшермәгез.
- шикәр диабеты булган балага физик активлык таләп ителгәнен онытмагыз.
- тыелган ризыкларны баланың күз алдында тотмагыз.

ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



Яшь чактагы кебек, йөгереп кенә китәрдәй буласың – буыннар ирек бирми, баскычтан төшеп-менүләре бер газап... Өлкән яшьтәгеләрдән иң еш ишетелүче зар болар. Нилектән буыннар үз вазыйфаларын тиешенчә үтәми, борыңгы ишек күгәне кебек шыгырдый? Республика клиник хастаханәсенең 1 нче травматология бүлеге мөдире, медицина фәннәре кандидаты Рамил САЛИХОВ белән шул хакта сөйләшәбез.

ХӘРӘКӘТ УЛ – ЯШӘҮ

Безнең бүлеккә мөрәҗәгать итүче пациентларның күпчелеге нәкъ менә буыннар авыртудан зарлана. 65 яшьтән өлкәнрәкләрнең 70–80 процентында артроз күзәтелә. 40–64 яшьлекләр арасында исә бу күрсәткеч 30–50 процент. Артроз белән Җир шарындагы бар халыкның 2 процент чамасы авырый.

Нәрсә соң ул артроз дигән сорауга җавап бирсәк, ул – буыннардагы кимерчәкнең зәгыйфьләнүе, ашалуы. Болар бер көндә генә барлыкка килми, моның өчен еллар кирәк. Артроз, гадәттә, тез һәм бот буыннарын зарарлый. Кайчак иңбашы һәм бармак буыннарында да күзәтелергә мөмкин.

Артроз – хроник авыру, аны тулысынча дәвалау мөмкин түгел. Ләкин дәва чараларын күрергә кирәк, чөнки соңгы стадиягә күчсә, зарарланган буын бөтенләй хәрәкәтсез калырга мөмкин. Беренче һәм икенче стадиядәге артроз вакытында консерватив дәвалау методлары, мазьлар, физио-дәва чаралары һәм дәвалау гимнастикасы билгеләнә. Кайчак табиб гормональ препаратлар да билгеләргә мөмкин, ләкин монысы иң соң очракта гына кулланыла. Өченче стадиядәге артроз булганда зарарланган буынны фәкать протезга гына алыштырырга мөмкин.

Артроз вакытында дәва гимнастикасының шифасы зур. Әмма гимнастиканы даими ясаганда гына нәтиҗәсе уңай булачак.

Артрозның сәбәпләре:
- буыннарга артык көч килү;
- төрле имгәнүләр;
- артрит;
- сөяк-буын системасы чирләре: бот сөяге дисплазиясе, сколиоз, яссытабанлылык;
- буыннарның артык хәрәкәтчәнлеге;
- метаболик чирләр;
- организмда гормональ үзгәрешләр булу;
- иммунитетның какшавы.

Артроз кемнәргә яный:
- көнозын аяк өсте эшләүчеләргә;
- гәүдәнең артык авырлыгыннан интегүчеләргә;
- эндокрин системасы дөрес эшләмәгәндә;
- нәселләрендә артроз белән авыручылар булганнарга.

Билгеләре:
- буыннарның хәрәкәтчәнлеге киму;
- физик нагрузкадан соң буыннарның сызлавы;
- иртән буыннарның оешуы;
- буыннарның шыгырдавы;
- торып киткәндә авырту тоюу;
- авырткан буын тиресенең кызаруы;
- буыннарның шешенкелеге.



Табиб киңәш итә:
- артроз билгеләре күзәтелгән очракта, 5 килограммнан артык күтәрмәскә;
- лифт була торып та, баскычлардан җәяү йөрмәскә;
- гәүдәнең артык авырлыгыннан котылырга;
- чүгәләп утырулардан тыелырга;
- авыртуга түзеп йөрмәскә, вакытында табибка күренергә.



Республика клиник хастаханәсенең җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча әйдәп баручы белгече Валерия Белова ярдәмендә әзерләнде.



Аш бүлмәсе – өйнең аерым бер җылы, рәхәт урыны. Бу бүлмәгә тулысы белән хатын-кыз хуҗа! Эштән, мәктәптән ашкынып кайтучылар да иң элек шунда ашыга. Монда аш, бәлеш, яңа пешкән каһвә исе борынны кытыклый, тәрәз төбендә гөлләр елмая... Аш бүлмәсенең гаиләне берләштерә, туплый торган, җанлы почмак икәнен дә онытмыйк! Без бүген Казанның Миләшле урамында яшәүче Алсу ГАФНЕР өендә кунакта. Ул безгә шәһәрдәге таш йортның аш бүлмәсен табигатькә якын итеп – авыл төсмерләре кертеп, бизәү, җайлаштыру турында сөйләде.

Аш бүлмәсе

Өебезнең аш бүлмәсен Европа авылы стилендә дип атарга буладыр. Бездә винтаж әйберләр бик күп. Үлчәү, каһвә савыты, кувшиннар... Авыл темасы икән, табигый элементлар күп булырга тиеш – диварларны агач вагонка белән тышладык, декор өчен түбәгә өрлек ясаттык, ишек өстенә агач аркалар куйдык. Агач киштәләр, үрелгән кәрзиннәр бүлмәне җанландырып җибәрде. Буфетның пыяла ишегенә үзем челтәр үреп элдем. Матур бит, ниндидер җылылык өсти! Биредә үземнең кул эшләремне дә урнаштырдым. Кипкән чәчәк-үләннәрдән ясалган төрле кул эшләнмәләре дә күп бездә.

Төсләр

Аш бүлмәсе артык чуар булмасын! Аксыл төсләрне сайларга киңәш итәм. Җиһаз, тәрәзә пәрдәләре, плиткалар бер үк төсләр гаммасында отышлы күренә. Бездә менә ак төс фонында күрән һәм зәңгәр төс аралашкан. Якты төсләрне башка төсләр белән дә уйнатып була.

Яктылык

Аш бүлмәсенең мөмкин кадәр якты булуы әйбәт. Тәрәзә пәрдәләре авыр булмасын, югыйсә кат-катланып җыелып торган челтәр аша яктылык, бүлмәгә кермичә, тоткарланып кала. Бүлмәне тулысынча яктыртып торучы һәм өстәл өстен яктырта торган ут чыганагы булса әйбәт. Әгәр коридор белән аш-су бүлмәсе арасында ишек юк икән, бу ике бүлмәдә дә люстралар бер үк типта булырга тиеш, дип киңәш итә дизайнерлар.

Җиһазлар

Кемдер ишекле киштәләрне хуп күрә, миңа ачыклары ошый. Әйе, беләм, ачык өлекләрне ешрак җыештырып, тузаннарын сөртеп торырга кирәк. (Әмма мин бөтен вакытны тузан сөртүгә багышлаучылар исәбеннән түгел!) Минимализм стилен үз итүче хуҗабикәләр дә бар, әмма аш бүлмәсендә шкафларның мөмкин кадәр күп булуын яратам. Иттарткыч, вафельница, ипи пешерү өчен электр миче... Аш бүлмәсендә нинди генә техника кулланылмый

бит! Ә аларны каядыр урнаштырырга, сакларга кирәк. Шунысын да әйтим, аш бүлмәсендә детальләр күп булган саен, плиткалар, диварларның бер төстә булуы әйбәт.

Зоналар

Плитә, ризык әзерли торган өлеш һәм раковина янәшә урнашкан. Шунда ук юасың, чистартасың, пешерергә куясың. Бу зонага «утраучык өстәл» дә ясамакчы идек, урынны күп ала дип туктальп калдык. Ризык әзерли торган зонада пычаклар, такталар, төрле кирәк-ярак куелган.

Ашау зонасы бераз читтәрәк урнашкан. Агач өстәлне махсус ясаттык. Өстәл өстенә эскәтер җәяргә яратмыйм. Аш бүлмәсендә бертөсле урындыклар гына булырга тиеш дигән сүз юк. Бездә эскәмия дә, үреп эшләнгән кәнәфи дә, урындыклар да бар. Уңайлылык өчен эскәмияләргә кечкенә мендәрләр тезәргә була. Бездәге һәр әйбер төрле-төрле кебек тоелса да, аларда уртак элемент бар. Мондый стиль – эклектика дип атала. Бездә ул – ак төс.

Идән

Үз тәҗрибәмнән чыгып, аш бүлмәсенә лакланмаган паркет такталар куярга киңәш итмим. Ә паласлар артык зур булмасын, чөнки аларны бик еш чистартып, юып торырга туры килә. Бигрәк тә өйдә кечкенә балалар булса.

Кечкенә киңәшләр

Аш бүлмәсен мин күзләрне иркәли торган урын дип кабул итәм. Әнә шкаф өстендә әбиемнән калган самавыр саклана, почмакларда чигү әйберләре, илһамландыра торган рецепт китаплары... Үрмәле гөлләр өйдән ир кешене качыра диләр, ышанмыйм. Аллага шөкер, гаиләбездә өч ир-ат бар. Ә үрмәле гөлләр диварларны бизәп, өебезгә җанлылык өстәп тора.

Аш бүлмәсендә табигый чималдан ясалган табак-савыт куллану сәламәтлеккә файдалы икәнен онытмыйк. Мисал өчен, бакыр савытларда әзерләү бик файдалы санала, әмма анда әзерли белү дә мөһим. Бакыр савытны сыеклык салмыйча утка куярга ярамый! Әгәр каһвә әзерли торган бакыр савытта төнәтеп, гади су гына эчсәгез дә, организм сезгә рәхмәтле булыр, мондый су табигый антисептик булып санала.

Аш бүлмәсенең күрке ул – чисталык. Нәрсә генә эшләсәгез дә артыгыздан җыештырып калдырырга онытмагыз. Кайвакыт шкаф өстенә, ипи саклый торган савыт читенә дару каплары, пакетлар, язулы кәгазь кисәкләре, тагы әллә нинди вак-төяк чүп-чар кыстырып куела. Андый вак-төякне күзгә ташлана торган урыннан алып куегыз әле! Алар өчен шкафка махсус тартма куеп, шунда саклагыз.

Табынга утыргач, ризык безгә көч бирсен, шифалы булсын, дип теләк теләү гадәте бар бездә. Ашык-пошык ашарга ярамый. Тыныч кына – сөйләшә-сөйләшә бергә чәй эчәргә яратабыз.

Өстәл артыннан да туяр-туймас кына китәргә кирәк дигән кагыйдәне тотарга тырышабыз. Сезгә дә шулай эшләргә киңәш итәм!

Раилә ХӘЯЛИЕВА әзерләде.



Фото: Анна Арахамия

Борай бәлеше

«Борай – Татарстанның бренд ризыгына әйләнеп бара», – дигән иде кайчандыр Марат Әхмәтов. Борайдан токмач, берничә төрле ярма әзерлиләр, икмәк пешерәләр. Ул культура күп еллар буена Кукмара районында үстерелә, шуңа да борай бәлеше бу якларның йөзек кашына әйләнгән, бирелә генә аның бөтен тәмен-мәлен белеп пешерәләр, иң кадерле кунаклар өчен затлы сый итеп әзерлиләр. «Сөембикә» журналы, борай бәлешен асылына төшенеп, электән сакланып калган рецепт белән әзерләүче осталарны күптән эзли иде. Көзге муллык җыелып беткән, игеннәр урнашкан мәлдә Кукмара якларына чыгып киттек. Менә шул сәяхәтебездә Зур Сәрдек авылында яшәүче Нурфия ханым ФӘТТАХОВА белән Альмира ханым ШӘЙМӘРДАНОВА безгә авылның элеккеге камыр осталарыннан өйрәнеп калганча, борай бәлеше пешереп күрсәттеләр. Һай, уңган да соң алар! Бәлешләре чыжлап, хуш исләр чыгарып, тел йотарлык булып пешеп өлгерде. «Борай бәлешенең сере – аңа майны кызганмыйча салу, – ди хуҗабикәләр. – Гадәттә, май ботканы гына түгел, борай бәлешен дә бозмый!» Әйдәгез, бу тәмле, үзенчәлекле һәм файдалы борай бәлешен бергәләп пешереп карыйк инде!



Кирәк

Камыр өчен:
- 2 аш кашыгы ат мае;
- 1 аш чүмече кайнар су һәм сөт;
- 2 аш кашыгы кибет каймагы;
- 1 аш кашыгы өй каймагы;
- 2 аш кашыгы үсемлек мае;
- ярты пачка маргарин;
- тоз, шикәр комы;
- 1 йомырка.

Эчлек өчен:
- 4 стакан борай ярмасы;
- майлы тавык, каз, үрдәк ите;
- 3–4 данә эрерәк башлы суган;
- 300 г атланмай;
- тоз, борыч.





Эш барышы

- Бәлеш пешерүне ярма бүрттерүдән башлыйбыз. Башта борай ярмасын берничә кат юабыз, аннары тозлы суга салып, утта 40 минут чамасы тотабыз.
- Ваклап итне турыйбыз.
- Әрчеп, бик вак итеп суган турыйбыз. Тәменчә тоз, борыч сибәбез.
- Барысын бергә кушып, әйбәтләп болгатабыз. Булса, ат мае кушабыз.
- Камыр әзерләүне кайнар суга сөт кушып туглаудан башлыйбыз. Аннары камырга диган барлык ингредиентларны кушып, йомшак итеп камыр басабыз.
- Камырны ике өлешкә бүләбез. Зуррак өлешен җәем итеп табага салабыз.
- Эчлекнең бер өлешен җәем өстенә бушатып, кисәкләп май куеп чыгабыз. Аннан эчлекнең калган өлешен салабыз.
- Камырның кечерәк өлешен җәеп, бәлешнең йөзен томалыйбыз. Уртага тишек тишеп, камырдан түгәрәк ясап куябыз. Матур итеп бөреп, 2–2,5 сәгатькә 180 градуска кадәр җылытылган мичкә тыгабыз.
- Бәлешне мичтән алгач, өстен тастымал белән каплап куябыз. Кискәндә, башта өске өлешен бүләбез, аннары «бәлеш бармагын» (бөргән өлеше) кисәбез.

Белмәсәң бел…

Борай радиациягә, әйләнә-тирә мохитнең тискәре тәэсиренә каршы торучы буларак билгеле. Борай бөртекләре экологик яктан чиста, чөнки аларның дүрт катлы тышчасы бернинди зарарлы матдәне дә үткәрми. Борайда аксым күләме башка культуралардан күпкә артык. Аңарда кеше организмы өчен алыштыргысыз саналган 18 аминокислота бар. Борай составындагы тимер, протеин кебек матдәләр, витаминнар гадәти бодайга караганда күбрәк. Составында җилемсә түбән булу сәбәпле, глютенга аллергиядән интегүчеләр, ябыгырга теләүчеләр аны үз диеталарына курыкмыйча кертә алалар. Табиблар йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан җәфаланучыларга, ашкайнату системасы начар эшләгәннәргә дә борай ашарга куша. Иммунитетны ныгытыр өчен дә ашарга кирәк аны. Клетчатка күп булу сәбәпле, борай шикәр һәм холестерин күләмен көйләп тору сәләтенә дә ия.

Фото: Анна Арахамия



Көзге кичләрдә чынаякка кайнар чәй агызып, йомшак кәнәфигә чумарга кайсыбыз яратмас! Сусауны басу, кәефне күтәрүдән тыш, чәй файдалы да булырга тиеш. Дөрес туклану рубрикасының даими авторы Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА безне бик файдалы үлән чәе белән таныштырмакчы.



Саган чәе белән танышмы сез?

Саган-дайля – Алтай, Тибет, Саян тауларында гына үсүче дару үләне. Күп халыклар аны чәй буларак яратып куллана. Тибет монахлары әлеге үсемлекнең файдалы үзлекләрен инде күптәннән белгән. Тиккә генә аны «гомерне озайтучы үсемлек» дип атамаганнардыр.

Саган-дайляның кыйммәте аның иң элек эфир майларына, кислоталарга, бөрештерүче матдәләргә, сумала, B, C, E, төркеме витаминнарына бай булуында. Боларга тагын флавоноидлар, гликозидлар, тимер, магний, кремний, йод кебек минералларны да өстәргә кирәк.

- Саган-дайля барыннан да битәр, хәл кертеп җибәрү чарасы буларак кулланыла. Ул хәтта кофены да алыштыра ала. Нәкъ менә шушы үзлеген искә алып, аны авыр хасталарга һәм өлкән яшьтәгеләргә тәкъдим итәләр. Әлеге эчемлек организмның тернәкләнү процессын тизләтә, чирләргә каршы торучанлыгын арттыра, матдәләр алмашын яхшырта.
- Саган-дайля чәе салкын тигәннән, тын юллары ялкынсынганнан файдалы. Аны дәва чарасы итеп кенә түгел, профилактика максатыннан да кулланалар.
- Бу чәй – бик көчле бәвел кудыргыч. Ул организмдагы артык сыеклыктан арынырга, шешенкелекне киметергә булыша. Аны цистит, бөер ялкынсынуы, бөерләрдә ком һәм ташлар булганда эчәләр.
- Саган-дайля чәе кан тамырларын ныгыта, кан басымын көйләргә ярдәм итә.
- Ул организмны һәм канны агулы матдәләрдән чистарта.
- Әлеге үләннең ялкынсынуны басу, бактерияләрне юк итү кебек сыйфатлары да билгеле. Бик көчле антиоксидант буларак, яман шешне кисәтә. Химиотерапия алганнан соң, саган-дайля чәен эчү организмга тизрәк тернәкләнергә булыша.

Саган-дайляның дару үләне булуын һәм куллану нормасын арттырмаска кирәген дә истән чыгарырга ярамый. Аны иртән бер чынаяк эчеп кую җитә.
Кич кулланган очракта исә йокыны качырырга мөмкин.

Саган-дайляны берничә төрле кулланырга була. Иң оптималь юлы – берничә тармагын кара яки яшел чәйгә кушып төнәтү (бер-ике тармак җитә). Шуннан да арттырып җибәрсәң, кан басымын уйнатуы ихтимал. Әгәр дә гөлҗимеш яки Иван-чәй төнәтмәсе белән кушып эчсәң, файдасы тагын да арта. Үсемлек тармакларын берничә тапкыр да төнәтергә була, бу очракта чәйнең куелыгы кими һәм аны көнгә бер-ике чынаяк та эчә аласыз.

Организмның күнегүен булдырмас өчен, бер ай эчкәннән соң, 2-3 атна тәнәфес ясап алырга кирәк.

Саган-дайля чәенең тәме үзенчәлекле. Җиләк тәме дә бар анда, чак кына ылыс тәме дә...

Саган-дайля – дөрес кулланган очракта бик көчле үзлекләргә ия үсемлек.

Фото: Камилә Димөхәммәтова

Кучкар. Нәрсәдер сез уйлаган вакытта килеп чыкмаса, борчылмагыз, җиһан нәрсәнең кайчан кирәк булуын һәрчак әйбәтрәк белә! Һәр яңа адымны хыялга якынайта торган тәҗрибә дип кабул итегез.

Үгезбозау. Мөһим булмаган әйберләр, мөнәсәбәтләр урынына яңалыклар, көтелмәгән шатлыклар килер. Зирәк киңәшләре белән ярдәм итеп торучы тормыш укытучыгызны табу мөмкинлеге зур.

Игезәкләр. Хыялыгызга ышаныгыз! Кайвакыт кирәкле тукталышка килеп җитәр өчен шактый урау юллар узарга кирәк. Сабыр булыгыз! Киләсе елга максатлар билгеләп куярга да онытмагыз.

Кысла. Уңышсызлык килеп чыкса, артык борчылмагыз. Кирәкле вакытта тиешле урында булырга тырышыгыз. Ай ахырында бәхет юлы ачыласына ышаныгыз. Яңа ел могҗизаларсыз булмый ул!

Арыслан. Хыял белән бергә аны чынга ашырырлык көч тә килә, диләр! Бу – тормыштагы миссиягезне, ихлас күңел халәтегезне аңларга тырыша торган чор. Финанс юлыгыз ачылыр.

Кыз. Карьера баскычында күтәрелеш көтелә. Димәк, финанс ягыннан да уңыш киләчәк. Нәрсәнедер үзгәртер өчен, иң элек баштагы уйларыгызны үзгәртергә кирәклеген истән чыгармагыз!

Үлчәү. Конкрет эшләр белән шөгыльләнә торган вакыт. Һәр эшнең нәтиҗәсе сез көткәннән дә әйбәт буласына ышаныгыз! Гаиләгез белән бергә булырга тырышыгыз. Сезгә һәрвакыт хәрәкәт кирәк: спортка, бию дәресләренә язылыгыз.

Чаян. Начарлык көткәндә яхшылык килер. Моны тормыш дәресе дип кабул итегез! Кешеләргә елмаю, якты йөз бүләк итүдән курыкмагыз. Бу гамәлегезне көчсезлек дип түгел, зирәклек дип кабул итәрләр. Үзегезгә ял бирергә дә онытмагыз!

Укчы. Бу чорда сезнең өчен гаилә тормышы беренче урында булачак. Димәк, ялгызларның үз парларын очрату мөмкинлеге зур дигән сүз. Яңа ел алдыннан була торган мәшәкатьләр көчегезне алмасын, уза торган эшләр ул! Яңалыкларга әзерләнегез!

Кәҗәмөгез. Башлаган эшләрегезне вакытында тәмамлап куйсагыз, тыныч күңел белән ял итәрсез. Бар әйберне дә үзегезнең җаваплылыкка алмагыз. Тормышка җиңелрәк карарга тырышыгыз, могҗизаларга да урын калдырыгыз!

Сукояр. Рухи дөньягызның үсеш чоры. Барысы да үз җае белән бер эзгә төшәчәк. Бернәрсәне дә ашыктырмагыз, борчылмагыз. Ихлас теләкләрегезне аңларга тырышыгыз, хыялларыгызны кәгазьгә язып куегыз, яхшыга ышаныгыз!

Балык. Кешеләр белән азрак аралашырга тырышыгыз. Билгесезлек каршындагы куркуларыгыз сезгә ның комачаулый. Алардан арыну өчен башкаларның уңыш тарихларын уку, кинолар карау әйбәт булачак. Тиздән барысы да уңай якка үзгәрер!

тест

СТРЕССКА КАРШЫ ТОРА АЛАСЫЗМЫ?

Сорауларга «әйе», «юк», «белмим» дип җавап бирегез:

1. Сезнең эшегез бик авыр һәм киеренкеме?

2. Ял көннәрендә һәм кичләрен эш турында еш искә төшерәсезме?

3. Эштә тоткарланырга яки эшләрне өйгә алып кайтырга туры килгән вакытлар еш буламы?

4. Вакыт җитмәүдән интегәсезме?

5. Эшләрегезне вакытында тапшырыр өчен ашыгырга, каударланырга туры килгән чаклар еш буламы?

6. Башкаларның акрынрак кыймылдавын күреп, ашыктыра башлыйсызмы?

7. Үз фикерен әйтеп бетергәнче әңгәмәдәшегезне еш бүлдерәсезме?

8. Кемне дә булса озаклап көтеп торырга туры килгәндә түземсезләнүегез йөзегезгә чыгамы?

9. Күңелегездәге канәгатьсезлекне, киеренкелекне башкаларга белгертми кала аласызмы?

10. Чиратта басып тору сезне чыгырдан чыгарамы?

11. Вакыт бигрәк тиз уза дигән уй соңгы вакытта күңелегезгә еш киләме?

Тест нәтиҗәләре:

«Әйе» җавабына – 2 балл, «юк» – 0 балл, «белмим» – 1 балл куеп санагыз һәм нәтиҗәләргә күз салыгыз:

0–10 балл. Тынычлык, бары тынычлык! Мондый тип кешеләр максатларын төгәл билгели һәм аларга ирешү юлларын да әйбәт белә. Алар үҗәт, чыдам һәм вакытны рациональ итеп бүлә белә. Көтелмәгән ситуацияләрдә беркайчан да уңайсыз хәлләргә калмыйлар.

10–30 балл. Кайвакыт хисләргә ирек биреп алсагыз да, күп вакытта стресска каршы тора беләсез. Кимчелекле якларыгызга юл куймасагыз, эмоцияләрне контрольгә алу авыр түгел. Теләгәндә, уңай якка үзгәрә аласыз әле!

30 баллдан югарырак. Сез – дары савыты кебек! Конкуренциягә омтыласыз, үзегезне аямыйча һәрвакыт каядыр ашыгасыз. Мондый халәт үз-үзеңнән яки тормыштан канәгать булмаганда килеп чыга. Агрессия, түземсезлек, гиперактивлык сыйфатлары күзәтелә, бит мускуллары киеренке халәткә килә. Стресс эчтән яндыра, тирә-юньдәге матурлыкны, тыныч тормыш агымын тоеп яшәргә комачаулый. Әгәр дә бу өлештә үзегезнең портретны танығансыз икән, психологик халәтегез хакында җитди уйланырга, тынычлану өчен белгечләргә барырга яки табиб киңәше белән дәва алырга вакыт дигән сүз.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Раилә ХӘЯЛИЕВА, Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.





СЕР ЯШЕРЕЛГӘН СЫННАР

Альфиз Сабиров белән танышуыбыз интернет аша, бик гадәти килеп чыкты. Кайбер сәбәпләр аркасында үзе белән баштан ук күрешү насыйп булмады, рәссамның «Хәзинә»дә ачылган күргәзмәсенә барырга өлгерә алмадым. Аның каравы, күпмедер вакыттан Альфиз редакциягә үзе килде. Заманча сәнгать, тарих һәм традицияләр, мәдәният һәм һөнәрнең бергә үрелеп китүе турында иркенләп сөйләшеп утырдык.

Элитар һәм нәфис сәнгать әсәре булган бронза скульптуралар бүген бик тә популяр. Аеруча Альфиз эшли торган стильдәгеләре. Зәңгәр патина йөгертелгән фигураларының гаҗәеп колористикасы таләпчән тамашачыны да таң калдыра.

Альфиз Сабиров эшләре хаостан арынып, сүзсез – тын калып карауны сорый. Алар берникадәр Даши Намдаков, Дали, Роден иҗатын хәтерләтә, ләкин үзенә генә хас кабатланмас почеркы бар, һәм ул нәкъ менә аныкы булып танылa да.

Бар да балачактан килә. Балалар бакчасында йоклыйсы килмәгән Альфиз, култык астына китабын кыстырып, тәрбияче апасы янына килә, һәм алар шулай бер-берсенә сыенып, башкаларны уятмас өчен шыпырт кына дөнья халыклары әкиятләрен укыйлар. Бай балачак күзаллавы аша кечкенә малай күңелендә берсеннән-берсе кызыклы образлар туа. Альфиз иҗатында өстенлек алган тема – авторның шәхси мифологиясе. Татар этносы аша килеп кереп, күңелен илһамландыра, хыял дөньясында йөртә. Төштә күргәннәр, балачак хатирәләре һәм үз уйлары аша күңелгә кереп калганнар – структуралары буенча гаҗәеп катлаулы, ә үзләре күптән таныш образлар. Һәркайсында бик күп таныш элементлар күрәбез. Серле принцессалар, мифик албастылар һәм төрле әкияти җанварлар әйтерсең узган меңьеллыклардан мәдәни мирас булып бүгенгегә калыккан. Һәркайсы үзенчәлекле, кабатланмас һәм камил дәрәҗәдә ясалган.

Скульптураларны җентекләп күздән кичергәч, аларда ниндидер сер яшерелгәнен тоясың. Үзләре һаман трансформация һәм яңару процессында кебек: әйтерсең лә башка дөньядан. Сызыклар һәм формалар ирекле ритм тудыра, эшләрнең чикләре сизелер-сизелмәс, шул ритм сине еракkaрак алып китә, карашың бер скульптурадан икенчесенә талгын гына күчә бара... Альфиз сыннары үзләренә яшерелгән серне ачу юлларына әйди.

Аның иҗаты, күргәзмәләре Россия тамашачысын гына түгел, Европаныкыларны да тәмам әсир итә.

Бүгенге көндә Альфиз Сабиров – билгеле скульпторларның берсе. Авторның берникадәр сыннары Париж, Нью-Йорк, Лондон, Берлин, Рига, Токио, Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Пермь, Төмән галереяларында һәм шәхси тупланмаларда саклана.


Төрле стильләрнең үзара яраклашуы, үзенә генә хас сәнгати зәвыгы, скульптураның заманча яссылыкта чагылышы, «Кичә–Бүген–Иртәгә»нең берлеге – Альфиз Сабиров скульптурасы шул була инде. Ул үзе аны «яңа артефакт» дип йөртә. Барлык образлары да пластикада төрлечә гәүдәләнә. Бер ишләрендә – омтылышлы хәрәкәтне, икенчеләрендә туктап калган «архаик» тынлыкны тоябыз.


Эпоска мөрәҗәгать итеп, ул үзен бик тә заманча рәссам итеп таныта, форма, фактура, материалларны уйнатып, борынгы образларны үзенчә тасвирлый, кабатланмас әсәрләр тудыра.

Бу саныбыз әзерләнеп ятканда, Альфиз бронзадан яңа эшен – «Сөембикә» сынын эшләп төгәлләде/

Рәмзия КАШАПОВА

АЛЬФИЗ САБИРОВ











■ Хыял. 11 см
■ Йокысызлык. 11 см

■ Сююмбике. 33 см
■ Утырып торучы. 11 см

■ Җиденче бит. 7 см.
■ Сау алиһәсенең башы. 17 см.





Кышкы язылу өчен кар көри торган машина, кухня техникасы һәм гаджетлар от!

Бүләкләр 2021 елның 12 февралендә уйнатылачак



1 ЯЗЫЛ — 2020 елның 25 декабренә кадәр ТАТМЕДИА АҖнең бер газета һәм бер журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 ҖИБӘР — «Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 ОТ — Язылган өчен тостер, чәйнек, смартфон яки планшет от. Төп бүләк — кар көри торган машина!



Тулырак мәгълүматны, акциянең узу вакытын, бүләкләр, аларны алу тәртибе турында tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 19.10.20 — 20.03.21 кадәр үткәрелә. Гаризалар 30.01.2021 кадәр кабул ителә. Оештыручы — ТАТМЕДИА АҖ. Реклама 16+ Товарлар рәсемдә күрсәтелгәннән үзгә булырга мөмкин.